3328

# РУСЧА-ТАТАРЧА ФРАЗЕОЛОГИК СҮЗЛЕК

АХМЕТ БАЙТҰРСЫНҰЛЫ атындағы
ТІЛ БІЛІМІ
ИНСТИТУТЫ

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1959

Н. Б. БОРҺАНОВА, Л. Т. МӘХМУТОВА

# РУСЧА-ТАТАРЧА ФРАЗЕОЛОГИК СҮЗЛЕК

ТІЛ БІЛІМІ
ИНСТИТУТЫ

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1959

## СҮЗ БАШЫ

Фразеология — грек сүзе, ф р а з а (frasis — тәгъбир) һәм л о г о с (logos — тәгълимат, фән) сүзләреннән ясалган.

Хәзерге тел белемендә ф р а з е о л о г и я ике төрле мәгънәне эченә ала. Беренчедән, аерым телләрнең үзләренә генә хас булган тотрыклы сүзләр тезмәсе, образлы тәгъбирләре, идиомнары, мәкаль һәм әйтемнәре фразеология дип йөртелә. Икенчедән, бу термин тел белеменең бер тармагын — телнең фразеологиясен өйрәнә торган фәнне белдерә.

Фразеология фән буларак тел белеменең иң аз эшләнгән бүлекләреннән берсе санала. Бүгенге көндә дә фразеологиянең составы, төзелеше, аңа керә торган берәмлекләрнең типлары һ. б. турында төрлечәрәк фикерләр булуы, шулай ук төрле телләрнең фразеологиясен үзара чагыштырган сүзлекләрнең аз булуы, ә кайбер телләрдә аңлатмалы фразеологик сүзлекләрнең бөтенләй булмавы шуны ачык күрсәтәләр.

Дөрес, соңгы елларда бу өлкәдә эш беркадәр җанланып китте. Моны аерым телләрнең фразеологик байлыкларын теге яки бу күләмдә үзенә туплаган җыентыкларның чыгуы, фразеологик берәмлекләрне анализлауга багышланган мәкаләләр басылуы һәм диссертацияләр язылуы, ике телнең фразеологик байлыгына нигезләнеп чагыштырма сүзлекләр төзелүе һәм, ниһаять, В. Дальнең „Пословицы русского народа“ дигән җыентыгының 1957 елда янадан басылып чыгуы кебек фактларга күз салганда ачык күрергә мөмкин. Ләкин бу эшләрнең күпчелеге рус теленә карый, ягъни рус теле материаллары нигезендә башкарылган хезмәтләр булып тора.

Конкрет алганда татар теле фразеологиясе өлкәсендәге эшләр бармак белән генә санарлык. Бигрәк тә татар теле фразеологиясен башка телләр фразеологиясе белән чагыштыру эше бөтенләй кул-аяк кермәгән өлкә булып тора. Ә бит илебез халыкларының культура бәйләнешләре моңа таләпне күптәннән куеп килә. Чөнки күп милләтле совет культурасын үстерүдә һәрбер халыкның иң гүзәл әдәбият һәм сәнгать үрнәкләрен үзара алмашу кирәкле чара булып исәпләнә. Халыкларның культура байлыгын үзара алмашу эшендә уңышлы һәм дөрес тәрҗемә итү әһәмиятле роль уйный. Моның өчен зур күләмле тәрҗемә сүзлекләр белән беррәттән аерым телләрнең фразеологик материалларына нигезләнеп төзелгән чагыштырма җыентыклар, сүзлекләр дә бик кирәк. Чөнки әдәби әсәрләрне, фәнни-популяр очеркларны һәм публицистик мәкаләләрне бер телдән икенче бер телгә тәрҗемә ясаганда, һәрбер телнең үзенә генә хас фразеологик берәмлекләре күпләп очрыйлар.

Бу сүзлекнең әһәмияте моның белән генә чикләнми, әлбәттә. Ул рус һәм татар телләрен чагыштырма планда өйрәнүчеләр өчен кечерәк бер кулланма булуны да күз алдында тота.

Телнең фразеологик берәмлекләре өчен, нигездә, түбәндәге төп үзенчәлекләр хас: а) форманың кыскалыгы һәм җыйнаклыгы; б) берәмлек эченә кергән компонентларның тотрыклылыгы, ягъни аларны төшереп калдырырга яки синоним сүзләр белән дә алмаштырырга мөмкин булмавы; в) фикернең тыгыз концентрацияләнгән (береккән) булуы; г) образлылык һәм читләтеп әйтү; д) сөйләмдә әзер формада үзгәрешсез кулланылуы һ. б. Шушы үзенчәлекләр аларны бер телдән икенче телгә күчерүне кыенлаштыра, хәтта кайбер очракларда турыдан-туры күчерергә мөмкин дә булмый. Мәсәлән, рус теленең „елак“ мәгънәсендәге *„глаза на мокром месте“* фразеологик берәмлеген татарчага сүзен-сүзгә тәрҗемә итеп бирү һич тә мөмкин түгел. Мондый очракларда, һичшиксез, мәгънәгә туры килә торган эквивалентны табарга кирәк. Шулай иткәндә генә тәрҗемә әсәрнең әдәби һәм фәнни кыйммәте югары була. Менә шушы факт үзе генә дә чагыштырма фразеологик сүзлекләрнең кирәклеге һәм аларның әһәмияте ни дәрәҗәдә булуы турында ачык күрсәтә.

Тәкъдим ителә торган „Русча-татарча фразеологик сүзлек“ шушы ихтыяҗны үтәү юлында беренче тәҗрибә булып тора. Билгеле булганча, моңа кадәр татар теле фразеологиясе өстендә

эш, нигездә, аны туплау, аерым җыентыклар итеп чыгару[1] һәм аларга фәнни анализ ясау[2] тармагы буенча алып барылды. Рус һәм татар телләре фразеологиясен чагыштырмача өйрәнү кул тимәгән бер өлкә булып кала килде. „Русча-татарча фразеологик сүзлек“нең беренче тәҗрибәсе шушы тармак буенча башкарылган кечкенә күләмле хезмәт булса да, бу юлда беренче тәҗрибә, башлангыч адым буларак, һичшиксез, әһәмиятле.

Сүзлекне хәзерләгәндә төзүчеләр мона кадәр матбугатта рус һәм татар телләрендә чыккан фразеологик сүзлекләрдән, мәкаль һәм әйтемнәр җыентыкларыннан файдаландылар. Бу әсәрләрнең исемлеге сүзлекнең ахырында бирелде.

Сүзлеккә рус теленең өч меңгә якын фразеологик берәмлеге алынып[3], шуларга татар теленнән төгәл эквивалентлар табарга тырышылды. Моның өчен төзүчеләр, татар әдәби теленең фразеологик байлыгы эчендә эзләнү белән беррәттән, халыкның җанлы теленә (ягъни диалектларга да) мөрәҗәгать иттеләр. Бу үз чиратында татар теленең бай хәзинәсеннән киңрәк файдаланырга мөмкинчелек бирде. Моны ачыклау өчен бер генә мисал китерик: рус телендәге *„Назвался груздем, полезай в кузов“* фразеологик берәмлегенә татар әдәби телендә төгәл эквивалент була торган берәмлек хәзергә билгеле түгел. Ләкин аерым сөйләшләрдә моның нәкъ калькасы *„Паңгы[4] булдыңмы, кызауга кер“* берәмлеге актив кулланыла. Мондый фразеологик берәмлекләр сүзлеккә берникадәр кертелделәр, һәм төзүчеләр аларны әдәби телгә кереп китәргә тиешле гәүһәрләр дип карыйлар.

---

[1] Х. Бәдигый. Халык әдәбияты. 1 том, 1 бүлек. Казан, 1912.

Татар халык иҗаты, Казан, 1947.

Татар теленең фразеология, мәкаль һәм әйтемнәре, Таткнигоиздат, 1956.

[2] Ш. Рамазанов. Татар теле буенча очерклар, Казан, Таткнигоиздат, 1954. 129—132 битләр.

Г. Әхәтов. Татар телендә фразеологик әйтелмәләр (канд. диссерт. авторефераты), Казан, 1954.

[3] Шулар арасында искергән берәмлекләр дә бирелде, ләкин аларның кайберләренә махсус искәрмә ясалмады.

[4] Паңгы — гөмбә.

Фактларга караганда рус һәм татар телендәге күп кенә фразеологик берәмлекләр мәгънәләре белән генә түгел, бәлки формалары белән дә бер-берсенә туры киләләр. Мәсәлән, *яблоко от яблони далеко не падает=алма агачыннан ерак төшми; и на нашей улице будет праздник=безнең урамда да бәйрәм булыр; куй железо, пока горячо=тимерне кызуында сук; старого воробья на мякине не проведёшь=карт чыпчык кибәккә алданмас* һ. б. һ. б.

Бу фактны рус һәм татар халкының гасырлар буе бергә аралашып яшәүләренең нәтиҗәсе итеп аңлатырга мөмкин. Телләрне чагыштырма өйрәнүчеләр мондый фактны башка телләрдә дә күзәткәннәр, һәм бер үк фразеологик берәмлекнең төрле телләрдә таралуына халыкларның үзара аралашулары, политик һәм культура бәйләнешләре сәбәпче булган дип карыйлар[1].

Бер үк фразеологик берәмлекнең төрле телләрдә очравын халыкларның тирә-юньдәге бер үк әйберләрне һәм күренешләрне күзәтүдән ясаган уртак нәтиҗәләре, тәңгәл килә торган тормыш-көнкүреш тәҗрибәләре белән дә аңлатырга мөмкин.

Мәсәлән, русның *„по одёжке протягивай ножки“* дигән мәкале татарча *„юрганыңа күрә аягыңны суз“*, казахча — *„төсегине карап айагынды узат“*, үзбәкчә — *„корпеңе карап айак узат“*, фарсыча — *„бе — андäза — е гéлим — е ход дераз кон“* (келәменә карап озан), мари халкында — *„тередын ончен, йоледым чумалте“* (чанаңа карап аягыңны суз) формаларында яңгырый.

Татарның *„аем туры бакканда, йолдызларга йодрык“* дигән мәкаленә грузиннарның *„ай минем яклы булганда, йолдызларның нигә кирәге бар миңа?!“* дигән мәкале туры килә. Русның *„яблоко от яблони недалеко падает“* дигән мәкаленә туры китереп, татарлар *„алмагачның алмасы ерак төшми“* дисә, негрлар *„җимеш агачыннан ерак төшми“* ди.

Моны бигрәк тә табигать күренешләренә һәм авыл хуҗалыгындагы эш чорларына караган фразеологик берәмлекләрдән ачык сизәргә мөмкин. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| Сей рожь в золу, а пшеницу — в пору. | Арыш чәчсәң, көлгә чәч; сабан чәчсәң, суга чәч. |

---

[1] Аникин В. П. Русские народные пословицы, поговорки, загадки и детский фольклор. Учпедгиз, М., 1957, 36—37 битләр.

| | |
|---|---|
| В марте курица из лужицы напьётся. | Мартта тавык (чыпчык эчәрлек су була. |
| Март у коров рог сшибает. | Февральдә сыер мөгезен сындырырлык бураннар була. |

## СҮЗЛЕКНЕҢ ПРИНЦИПЛАРЫ

1) Рус теле фразеологик берәмлекләре алфавит тәртибендә бирелделәр һәм номерлар белән күрсәтелделәр.

2) Рус теле берәмлекләренең вариантлары, әгәр алар әйтелешләрендә сизелерлек бер-берсеннән аерылсалар, һәркайсы алфавит тәртибе буенча үз урыннарында бирелде. Ә инде фразеологик берәмлекнең вариантлары бер-берсеннән тик бер сүз белән генә аерылсалар, мондый очракларда ул сүз төп берәмлектә (һәм русча, һәм татарча өлешендә) җәя эчендә генә күрсәтелде. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| Без мыла (масла, оглобель) в душу влезет (въедет). | Эчеңә-бавырыңа керер. |
| Добро пожаловать! — А сам за шапку. | ≅ Үзе кунак чакырган, үзе баланга (урманга) киткән. |

3) Рус теле фразеологик берәмлеге турысына куела торган татар теле эквивалентлары, вариантлары һәм синонимнары белән, барысы бер урында җыйналып бирелделәр. Мондый очракта мәгънә һәм форма ягыннан тәңгәл килә торган эквивалентны беренче урынга куярга тырышылды, ә вариантлар яки синонимнар беркадәр эчкәрәк кертелеп, үз эчләрендә алфавит тәртибендә язылдылар. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| Было да быльём поросло. | Үткәндәге сүткән, өстенә үлән үскән.<br>Буласы булган, буявы сеңгән.<br>Үпкән-кочкан җилгә очкан, өстенә үлән үскән. |

4) Ике яки берничә рус теле фразеологик берәмлекләре татарча бер үк эквивалент белән бирелсәләр, мондый очракларда татарча берәмлекләр кабатланып язылмадылар, бәлки **к. 121** дип, тулы аңлатмасы булган номерга җибәрелделәр. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| 4. Авось и к нам во двор солнышко взойдёт. | к. 121. |
| 121. Будет и на нашей улице праздник. | Безнең урамда да бәйрәм булыр әле. |

5) Рус телендәге синоним фразеологик берәмлекләргә татар телендә һәркайсына туры килә торган эквивалентлар булырга мөмкин. Мондый очракларда, синонимнарны бер-берсеннән югалтмас өчен, татар теле берәмлекләреннән соң җәя эчләрендә номерлары күрсәтелде. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| 156. Быть на седьмом небе. | Түбәсе (башы) күккә тию. Түбәсе түшәмгә тию (к. 1621). |
| 1621. Не чувствовать (не слышать) под собой ног. | (Шатлыктан) кая басканын белмәү. |

6) Рус теле фразеологик берәмлегенә татар телендә тәңгәл килә торган эквивалент булмаганда, мәгънәсе белән якын берәмлек табарга тырышылды, һәм мондый очракларда ике тел берәмлекләре арасына якынчалык (≌) билгесе куелды.

| | |
|---|---|
| Поповское брюхо из семи овчин сшито. | ≌ Мулла корсагы тугыз бозау тиресеннән тегелгән. |

7) Фразеологик берәмлекләрнең мәгънәләре ачык булмаганда, яки татар теле эквиваленты диалектлардан алынган очракларда, җәя эчләрендә аңлатмалар ясалды. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| Без ножа зарезать. | Пычаксыз сую (уңайсыз хәлдә калдыру мәгънәсендә). |
| Блином масляным в рот лезет. | Авызыңа бал да май булып керә (ялагайлану турында). |

# А

| | |
|---|---|
| 1. А ему и горя мало. | Аның исе дә китми.<br>Аның ике ятып бер төшенә дә керми. |
| 2. А ларчик просто открывался. | Аның сере бик гади икән. |
| 3. А там хоть трава не расти. | Анда теләсә ни эшләсен.<br>Анда теләсә дөньяны су бассын.<br>Мина дисә (кирәгем исә) дөньясы асты-өскә килсен.<br>Төкереп тә куймыйм. |
| 4. Авось и к нам во двор солнышко взойдет. | к. 121. |
| 5. Аза в глаза не смыслит (не знает). | Әлифне таяк дип тә белми. |
| 6. Алмаз алмазом гранится, плут плутом губится. | Дус башына дус җитә, кыз башына кыз җитә.<br>Кар башына кар җитә, дус башына дус җитә. |
| 7. Америку открыть. | Америка ачу. |
| 8. Аппетит приходит во время еды. | ≌ Аш ашка урын бирә.<br>Аш ашка, урыны башка. |
| 9. Артельная кашица гуще живет. | Бергә чакта өйрә куе була. |
| 10. Аршин проглотил. | Уклау йоткан (иелергә-бөгелергә яратмый торган, авыр хәрәкәтле кешегә карата әйтелә). |

# Б

| | |
|---|---|
| 11. Баба нехотя целого поросёнка съела. | Ашамыйм, ашамыйм дип, алтмыш белен (коймак) ашаган.<br>Ашамыйм дигән килен ашады житмеш (алтмыш) белен. |
| 12. Бабье лето. | Әбиләр көне.<br>Әбиләр атнасы.<br>Карчыклар чуагы. |
| 13. Баклуши бить. | Корыны бушка аудару.<br>Юкны бушка бушату (тутыру). |
| 14. Баснями сыт не будешь. | Сүз сөйләп тамак туймас.<br>Жыр тамак туйдырмый (к. 2427). |
| 15. Бащ-на-бащ. | Башма баш.<br>Акча беләи башма баш. |
| 16. Башмаки износить. | Чабата туздыру (юкка вакыт уздыру мәгънәсендә). |
| 17. Беда беду накликает. | Бәла ялгыз йөрми.<br>Бәла анасы буаз. |
| 18. Беда вереницами ходит. | к. 17. |
| 19. Беда висит над головой. | Бәла аяк астында гына йөри. |
| 20. Беда не за горами. | к. 19. |
| 21. Беда не по лесу ходит, а по людям. | Бәла агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри. |
| 22. Беда скоро ходит. | Бәла аяк астыннан чыга. |
| 23. Беден как Иов. | Шәйтаннан да ярлы. |
| 24. Беден как Лазарь. | к. 23. |
| 25. Беден как церковная мышь. | Эттән ач, беттән ялангач (к. 23). |
| 26. Бедному жениться и ночь коротка. | к. 999. |
| 27. Бедный как может, а богатый как хочет. | к. 83. |
| 28. Бежать как от огня. | Уттан качкан кебек качу. |
| 29. Бежит как угорелый. | Ут алган кебек чаба.<br>Итәгенә ут капкандай йөгерә.<br>Артына ут капканмыни! |

| | |
|---|---|
| 30. Без ветра и дерево не шатается. | к. 1644. |
| 31. Без вины виноват. | Гаепсездән гаепле. |
| 32. Без всяких задних мыслей. | Аны-моны уйламыйча.<br>Исәп-хисап тотмыйча.<br>Тегене-моны уйлап тормыйча. |
| 33. Без году неделя. | Аягы кереп житмәгән әле (күптән түгел генә мәгънәсендә).<br>Аягы керсә, таягы кермәгән.<br>Башы керсә, аягы кермәгән, аягы керсә, таягы кермәгән. |
| 34. Без масла каша не вкусна. | Майсыз ботка тыгыла (шумый). |
| 35. Без матки рой не держится. | к. 45. |
| 36. Без меры и лаптя не сплетёшь. | Үлчәүсез кием кисмиләр.<br>Үлчәүсез чабата да үрмиләр. |
| 37. Без мыла (масла, оглобель) в душу влезет (въедет). | Эчеңә-бавырыңа керер (к. 80). |
| 38. Без начала, без конца. | Башы-ахыры күренми.<br>Очы-кырые (очы-башы) күренми. |
| 39. Без ножа зарезать. | Пычаксыз сую (уңайсыз хәлдә калдыру мәгънәсендә). |
| 40. Без пастуха овцы не стадо. | к. 45. |
| 41. Без порток, а в шляпе. | Штансызга каеш буган.<br>Штансызга каеш бау. |
| 42. Без поры, безо время солнышко не всходит. | Мәлсез чәчәк ярылмас. |
| 43. Без спотычки и конь не пробежит. | к. 1099. |

44. Без труда не вынешь и рыбки из пруда. — Аусыз куян тотылмый.

Корт чакмыйча бал булмый.

Кулың эшләсә, авызың тешләр.

Көл булмый, гөл булмассың.

44 а. Без труда нет добра. — к. 44.

45. Без хозяина и дом сирота. — Үзем юкта — күзем юк.

Хуҗасыз йортта бәрәкәт юк.

46. Без числа. — Чиксез күп.

Исәпсез-хисапсыз (күп).

47. Бездонная бочка. — Төпсез мичкә.

Аракы мичкәсе.

48. Бездонной кадки водой не наполнишь. — Төпсез чиләк тулмас.

49. Белый свет не клином сошёлся. — Дөнья аңа гына терәлмәгән.

50. Береги платье с нова, а честь смолоду. — Киемне яңа чакта, намусны яшьтән сакла.

51. Бережена копейка рубль бережёт. — ≅ Бер тиен кергән баеган, бер тиен чыккан бөлгән.

Бер тиен—бер акча, ике тиен ике акча.

Мал колыннан үсә, акча тиеннән җыела.

52. Бережёного и бог бережёт. — Сакланганны алла саклар.

Сакланганны саклармын дигән.

53. Бережёного коня и зверь в поле не берёт. — к. 52.

54. Берёзовой кашей накормить. — Тал чыбыгы ашату (кыйнау, суктыру мәгънәсендә).

Таяк ашату.

55. Беречь как зеницу ока. — Күз карасы кебек саклау.

56. Бесстыжих глаз и дым неймёт. — Этнең күзе төтен белмәс.

АХМЕТ БАЙТҰРСЫНҰЛЫ атындағы ТІЛ БІЛІМ ИНСТИТУТЫ

57. Бесчестье хуже смерти. — Яман атың чыкканчы җаның чыксын.

Оят үлемнән яман.

58. Бешеная собака и хозяина кусает. — Эт симерсә (котырса) иясен тешли.

Эт симерсә иясенә ябыша.

59. Бешеные деньги. — Котырган акчалар.

60. Бил дед жабу, грозясь на бабу. — к. 245.

61. Били Фому за Ерёмину вину. — Ак эт бәласе кара эткә.

62. Бирюка бояться — в лес не ходить. — к. 100, 324.

63. Битая посуда два века живёт. — к. 2339.

64. Битком-набито. — Шыгрым тулы.

65. Битого, пролитого да прожитого не воротишь. — Түгелгән тулы булмас, үткән кире кайтмас.

Үткән көннең билгесе юк, киткән көннең кайтуы юк.

Үткән эшкә үкенмә, үкенсәң дә җиткезмәс.

Аккан су кире кайтмас.

Үткән гомер кире кайтмый.

66. Бить челом. — Баш ию.

Баш ору.

67. Бить некому. — Кыйнар кешесе юк.

68. Биться как муха в паутине. — Пәрәвезгә эләккән чебен кебек талпыну.

69. Бия себя в грудь. — Күкрәккә суга-суга.

Күкрәген (түшен) сугып.

70. Бледный (белый) как полотно. — (Йөзе) кәгазь кебек ак (төсе киткән, чырае агарган мәгънәсендә).

Чырае көл кебек.

71. Ближний счёт — дальняя дружба. — к. 688, 2519.

| | |
|---|---|
| 72. Ближняя родня: на одном солнышке онучи сушили. | Бер кояшта чабата киптергәннәр.<br>Күпер башында тәртәләре очрашкан.<br>Күпер башында күчәр башы эләккән.<br>Кодам кодасы — куян шулпасы. |
| 73. Ближняя соломка лучше дальнего сенца. | Ерактагы туганнан якындагы дустың яхшы.<br>Ерактагы туганың — якындагы дустың. |
| 74. Близ норы лиса на промысел не ходит. | Карак авылны саклый.<br>Карак үз авылын таламый. |
| 75. Близкий сосед лучше дальней родни. | Якындагы күршең — ерактагы туганың. |
| 76. Близко принимать к сердцу. | Йөрәккә (күңелгә) якын алу. |
| 77. Близок локоток, да язык короток. | к. 78. |
| 78. Близок локоть, да не укусишь. | Терсәк якын да — тешләп булмый.<br>Терсәкне тешләр идең дә авыз житми (буй житми).<br>Терсәкне тешләр идең дә—ерак. |
| 79. Блин — не клин, брюха не расколет. | Ашап (ашаганнан) үлмиләр.<br>Ашап үлмиләр, чирләп үләләр. |
| 80. Блином масляным в рот лезет. | Авызына бал да май булып керә (ялагайлану турында. к. 37). |
| 81. Бог дал день, даст и пищу. | Жан биргәнгә жүн бирер. |
| 82. Бог не выдаст, свинья не съест. | Алла ташламаса, бүре ашамас. |
| 83. Богатому — как хочется, а бедному — как можется. | Хәлле — хәленчә, юк — дәрманынча. |

Ярлы — тапканда, бай — сагынганда (ала).

84. Богатство — вода: пришла и ушла.

Байлык — бер айлык: керә дә чыга (бетә).

85. Богатый врёт, никто не уймёт.

Авызы кыек булса да, бай сөйләсен.

Авызы-борыны кыек булсын, байның улы сөйләсен.

Байның авызы кыек булса да, сүзе төз.

Бай кешенең авызы кыек булса да, төтене туры йөри.

Байның морҗасы кыек булса да, төтене туры чыгар.

86. Богатый рожу бережёт, а бедный — одежду.

Берәүгә баш кайгысы, берәүгә мал кайгысы.

87. Богатый сахар зоблет, убогий же камень гложет.

Байлар бал эчкәндә, ярлы кеше су эчә.

88. Богатыря узнаешь на поле брани.

Батыр яуда беленер.

86. Бодливой корове бог рог не даёт.

Сөзгәк сыерга (алла) мөгез бирмәгән.

90. Боек на словах.

Телгә оста.

91. Бойся, не бойся, без року смерти не будет.

Әҗәл җитми үлмиләр.

Тәкъдирсез үлмиләр.

92. Бока ввалились.

Эче эчкә ябышкан.

Эченнән энә үтәрлек.

93. Бока запали.

к. 92.

94. Болезнь входит пудами, а выходит золотниками.

Авыру потлап керә, мыскаллап чыга.

95. Болезнь скачет в дом на перекладных, а выбирается на долгих.

к. 94.

96. Болтать языком.

Юк-барны сөйләү.

Чүбек чәйнәү.

| | |
|---|---|
| 97. Больная жена мужу не мила. | к. 1339. |
| 98. Больше знай, да меньше болтай. | Күп бел, аз сөйлә. |
| 99. Борода росла — разума не принесла. | Сакалы үскән, акылы үсмәгән. |
| 100. Бояться воров — не держать и коров. | Тычканнан курыккан иген икмәс, бүредән курыккан көтү көтмәс.<br>Чикерткәдән курыккан иген икмәс (к. 324). |
| 101. Бояться как огня (пуще огня). | Уттан курыккандай курку. |
| 102. Бояться как чёрт ладана. | Иманнан качкан шайтандай качу.<br>Яшеннән курыккан шайтандай курку. |
| 103. Бранись, а на мир слово оставляй. | Ачуланышсаң да соңгысын әйтмә.<br>Капчык төбен селекмә. |
| 104. Бранит, на чём свет стоит. | Дөньядагын әйтеп тиргәү.<br>Тетеп тиргәү (салу). |
| 105. Браниться-бранись, а на мир слово береги. | к. 103. |
| 106. Брат ли, сват ли, а денежка не родня. | Мал кардәш түгел, җан кардәш. |
| 107. Брат мой, а ум у него свой. | к. 2582. |
| 108. Брать голыми руками. | Коры кул белән алу. |
| 109. Брать к сердцу. | к. 76. |
| 110. Брать (взять) себя в руки. | к. 1729. |
| 111. Бросать в пасть смерти. | Үлем кочагына ташлау. |
| 112. Бросать камень в (*чейнибудь*) огород. | Кеше бакчасына таш ату. |
| 113. Бросать палки под колёса. | к. 367. |
| 114. Бросать слова на ветер. | Сүзне җилгә ташлау.<br>Сүзне әрәм итү. |

115. Бросать тень (*на кого*).
Йөзгә кара ягу.
Биткә тап төшерү.

116. Бросаться в глаза.
Күзгә бәрелеп тору.
Күзгә ташлану.

117. Бросаться словами.
≅ Авызы ни әйткәнне колагы ишетмәү (уйламый сөйләү турында).

118. Бросаться со всех ног.
Җан-фәрманга йөгерә башлау.

119. Брось хлеб-соль за лес — после найдёшь.
Алтын җирдә ятмас, яхшылык юлда калмас.
Изгелек (яхшылык) җирдә ятмас.
Яхшылык онытылмас, изгелек җиргә күмелмәс.

120. Брюхо сыто, да глаза голодны.
Үзе туйган, күзе туймаган (к. 264).

121. Будет и на нашей улице праздник.
Безнең урамда да бәйрәм булыр әле.

122. Будет первый и последний раз.
Башы-ахыры шул булыр.

123. Будешь жив, будешь и сыт.
Илдә чыпчык улмәс.
Ачык авыз ач калмас.
Җан биргәнгә җүн бирер.
Тере кеше ач булмас.

124. Будешь сладок—живым проглотят, будешь горек — проклянут.
Юаш булсаң — басарлар, усал булсаң — асарлар.
Усал булсаң — асарлар,
юаш булсаң — басарлар,
урта булсаң — ил атасы (агасы) ясарлар.

125. Будешь сладок — разлижут, будешь горек — расплюют.
к. 124.

126. Будто корова языком слизнула.
Юып алгандай булды.
Мәче ялап алгандай булды.

| | |
|---|---|
| 127. Будь проклят! | Нәләт яусын!<br>Ләгънәт (нәләт) төшсен! |
| 128. Будь хоть пёс, лишь бы яйца нёс. | Үгез булмаса чурт булсын, савып алырга (эчәргә) сөт булсын. |
| 129. Будь, что будет. | Ни булса, шул булыр. |
| 130. Буря в стакане воды. | Юкка чәпчү (ачулану).<br>Чыпчык дулап киртә жимерә алмый. |
| 131. Бывает и после горечи бывает сладость. | ≅ Утыз көн уразаның да бер бәйрәме була. |
| 132. Был бы хлеб, а зубы сыщутся. | Аты булса, йөгәне табылыр.<br>Арыш булсын, ужым табылыр.<br>Арышы булсын, үлчәве табылыр.<br>Баш сау булса, башка бүрек табылыр.<br>Чиләге булса, капкачы табылыр. |
| 133. Был бы хлеб, а мыши будут. | к. 132. |
| 134. Была бы голова, будет и борода. | к. 132. |
| 135. Была бы голова, будет и булава. | к. 132. |
| 136. Была бы голова, будет и петля. | к. 132. |
| 137. Была бы шея, а петля найдётся. | к. 132. |
| 138. Была бы шея, а хомут найдётся. | Муены булса, камыты табылыр (к. 132). |
| 139. Была не была. | Беткән баш беткән (тәвәккәллек турында). |
| 140. Были бы крошки, а мышки будут. | Балы булса, чебене дә (табылыр) булыр (к. 132). |
| 141. Были бы побрякунчики, будут и поплясунчики. | к. 132. |
| 142. Были бы трупы, а черви найдутся. | к. 132. |

АХМЕТ БАЙТҰРСЫНҰЛЫ АТЫНДАҒЫ ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

143. Было бы болото, черти заведутся. — к. 132.

144. Было бы корыто, а свинья-то будет. — к. 132.

145. Было да быльём поросло. — Үткәндәге сүткән, өстенә үлән үскән.
Узып тузган.
Буласы булган, буявы сеңгән.
Үпкән-кочкан җилгә очкан, өстенә үлән үскән.

146. Быть без задних ног. — Табаннар таш булу (бик нык ару мәгънәсендә).

147. Быть в состоянии. — Хәлдән (кулдан) килү.

148. Быть готовым сквозь землю провалиться. — Җир тишегенә керерлек булу.
Казыган җир булса, мәңге чыкмаска кереп ятарлык булу.
Җир үтә китәрлек булу.

149. Быть душою беседы. — Әңгәмәнең үзәгендә булу.

150. Быть занятым по горло. — Эш муеннан (булу).

151. Быть злопамятным. — Эчкерле булу,
Кара эчле булу.

152. Быть, как громом поражённый. — Яшен суккандай булу (бик нык гаҗәплләнү мәгънәсендә.)
Аяз көнне яшен суккандай булу.

153. Быть на волоске. — Кыл өстендә генә тору.

154. Быть на краю могилы. — Кабер якасында булу (тору).
Бүген танда үләргә тору (к. 1762).

155. Быть на ножах. — Пычакка пычак килеп тору.

156. Быть на седьмом небе. — Түбәсе (башы) күккә тию.
Түбәсе түшәмгә тию (к. 1621).

157. Быть на хорошем (плохом) счету. — Яхшылар (яки начарлар) исәбенә кертелү.

158. Быть под башмаком (под каблуком) жены. — Хатынның типкәсендә булу.
Хатынын җилкәсенә атландыру.

# В

| | |
|---|---|
| 159. В брюхе солома, а шапка с заломом. | Тыштан ялтырый, эчтән калтырый.<br>Тыштан ал да гөл, эчендәген үзең бел.<br>Тышы ялтырый, эче калтырый.<br>Эче елый, тышы көлә.<br>Эче умач уа, тышы җәймә җәя. |
| 160. В воду бросить (деньги). | Суга салу.<br>Суга салгандай итү (акчаны). |
| 161. В глаза ласкает, а за глаза лает. | Алдымда болай, артымда тегеләй.<br>Алдымда мактый, артымда чәйни.<br>Кереп ашым ашый, чыгып башым ашый. |
| 162. В глаза не показываться. | Күзгә күренмәү. |
| 163. В глаза обманывать (лгать). | Күзгә карап алдау (ялганлау).<br>Күзгә карап җан ашау (сату). |
| 164. В голову ударило (о вине). | Башка китте.<br>Башка йөгерде.<br>Башка менде. |
| 165. В гости ходить — надо и к себе водить. | к. 1262, 1883. |
| 166. В грош не ставить. | Санга санамау.<br>Сукыр бер тиенгә куймау. |
| 167. В два счёта. | Күз ачып йомганчы. |
| 168. В добрый час! | Изге сәгатьтә!<br>Хәерле сәгатьләрдә (булсын)! |

ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

| | |
|---|---|
| 169. В долгу, как в шелку. | к. 1913. |
| 170. В единстве сила. | Берлектә — тереклек.<br>Берлек барда тереклек бар.<br>Кайда берлек, шунда көч.<br>Бердә түгел, илдә көч (к. 215). |
| 171. В игре и дороге узнаются люди. | ≅Кешенең кем икәнен беләсең килсә, юлдаш бул.<br>Ир сәфәрдә беленер. |
| 172. В ком есть стыд, в том есть и совесть. | Оят барда хәя бар. |
| 173. В конечном счете. | Ахыр чиктә. |
| 174. В конце концов. | Ахыр чиктә (ниһаять). |
| 175. В копеечку станет. | к. 669. |
| 176. В лес дров не возят, в колодезь воды не льют. | Урманга утын төяп бармыйлар. |
| 177. В лицо говорить. | Йөзенә бәреп әйтү. |
| 178. В людях — Ананья, а дома — каналья. | Илгә барса — илгәзәк, өенә барсаң — бик мәзәк. |
| 179. В людях — Илья, а дома — свинья. | Кеше өендә — Илья, үз өендә — свинья (к. 178). |
| 180. В люди вывести. | Кеше итү. |
| 181. В марте курица из лужицы напьётся. | Мартта тавык (чыпчык) эчәрлек су була. |
| 182. В мгновенье ока. | к. 167. |
| 183. В меду и подмётку съешь. | Бал (май) белән иске чабата да үтә. |
| 184. В милом нет постылого, а в постылом нет милого. | к. 1563. |
| 185. В мире жить — миру служить. | к. 186. |
| 186. В мире жить — с миром жить. | Илдә яшәү—ил белән яшәү. |
| 187. В мутной воде рыбу ловить. | Болганчык судан балык тоту. |
| 188. В нем смерть уже гнездо свила. | Аңа инде гүр (кабер) төсе кергән. |
| 189. В ногах (постели, кровати). | Аяк очында. |

| | |
|---|---|
| 190. В нужде и кулик соловьём свищет. | Башыңа төшкәч, башмакчы буласың.<br>Койрыгыннан ыграк кыссаң, куян да шырпы сызарга өйрәнер. |
| 191. В облака уноситься. | Хыял дингезендә йөзү. |
| 192. В огне не сгорит, в воде не утонет. | Утта янмас, суга батмас кеше (үткен мәгънәсендә).<br>Утка салсаң, утта янмас; суга салсаң, суга батмас. |
| 193. В один голос. | Бер тавыштан.<br>Бер авыздан. |
| 194. В один день по две радости не живёт. | Ике рәхәт бергә килми. |
| 195. В один прекрасный день. | Көннәрнең берендә. |
| 196. В одно перо и птица не родится. | Аттан ала да туа, кола да туа. |
| 197. В одно ухо вошло, из другого вышло. | Бер колактан керде, икенче колактан (икенчесеннән) чыкты. |
| 198. В одном кармане — вошь на аркане, в другом — блоха на цепи (пусто). | Кесә төбе тап-такыр. |
| 199. В осень и у воробья пиво. | Сентябрьдә син дә бер, мин дә бер (күзге туклыкта һәркем дә бертигез бай мәгънәсендә). |
| 200. В осень и у вороны копна, не только у тетерева. | к. 199. |
| 201. В подмётки не годится. | Олтырагына да яраксыз.<br>Ул аның итек табанына да торырлык түгел. |
| 202. В поле и жук—мясо. | Булмаганда арыш икмәге дә күмәч.<br>Ит күрмәгәнгә үпкә тансык. |
| 203. В поле серпом да вилой, так дома ножом да вилкой. | Кулың эшләсә, авызың тешләр. |
| 204. В полном (строгом, настоящем) смысле слова. | Чын мәгънәсе белән.<br>Чын мәгънәсендә. |

| | |
|---|---|
| 205. В полном соку (быть). | Яшьнәп (янып) торган чагы. |
| 206. В поте лица (трудиться). | Маңгай тирен түгеп (чыгарып, агызып эшләү). |
| 207. В решете воду не носят. | Иләк (кашык) белән су ташымыйлар. |
| 208. В рот воду набрал. | Авызына су капкан.<br>Авызына йөзек яшергән.<br>Авызына каз мае капкан.<br>Авызына сары май капкан.<br>Авызына сумала чапкан.<br>Авызына төймә капкан.<br>Төймә йоткан. |
| 209. В рукавице кукиш кажет. | Бияләй аша бармак күрсәтә.<br>Кесәдән йодрык күрсәтү. |
| 210. В руках было, да сквозь пальцы сплыло. | Күз күрде, кулга тимәде.<br>Күзгә күренде, кулга эләкмәде. |
| 211. В своём гнезде и ворона коршуну глаза выклюет. | к. 1392. |
| 212. В семье и каша гуще. | к. 9. |
| 213. В семье не без урода. | Семья гарипсез булмый. |
| 214. В скобках будь сказано. | Сүз арасында (уңаенда) әйткәндә (к. 962). |
| 215. В согласном стаде волк не страшен. | Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.<br>Аерылган каз — тупланган каргага җим (к. 170). |
| 216. В среду съедим, так в четверг не глядим. | к. 2277. |
| 217. В стене многие сучки есть. | к. 2604. |
| 218. В такую погоду добрый хозяин и собаку не выгонит за ворота. | Мондый көндә юньле кеше (хуҗа) этен дә чыгармый.<br>Мондый көндә яхшы кешенең эте дә йөрмәс. |

219. В тесноте, да не в обиде.
Күнелең киң булса, тар җиргә дә сыясың.

220. В тихом озере (омуте) больше чертей водится.
Тонык суның төбе корт.
Сазлы күлдә корт уйный.
Тымызык күлне корт басар.
Шартта-мартта ни дә юк, тымызык күлдә корт уйный.

221. В точку попасть.
Өстенә (эзенә басу).
Сыер икәнсең, өстенә үк бастың.

222. В трёх соснах заблудиться.
Ике агач арасында адашу.

223. В три ручья (слёзы) лить.
Яшьләрне чишмәдәй агызу.
Дәрья-дәрья яшь кою.

224. В уборе и пень хорош.
Киендерсәң, бүкән төбе дә чибәрләнә.
Агач күрке—яфрак, адәм күрке — чүпрәк.
Каралты — түбә белән, адәм—кием белән.

225. В упор сказать (говорить).
Йөзенә бәреп әйтү.
Туп-туры әйтү.

226. В упор смотреть (глядеть).
Туп-туры карау.

227. В упор стать.
Аяк терәү (киреләнү).

228. В хвалёной капусте много гнилых кочанов.
Мактаулы кыз туйда хур булыр (сынатыр).

229. В чём мать родила.
Анадан тума (шыр ялангач).

230. В чём только душа держится.
Авызын ачса, үпкәсе күренә (бик ябык мәгънәсендә).
Чыкмаган җаны гына бар.

231. В чернолесье не без зверя, в людях не без лиха.
Урман киексез булмас, адәм житешсез булмас.

232. В четырёх стенах (сидеть, жить).
Дүрт стена эчендә (арасында) (утыру, яшәү).

233. В чужих руках всегда ломоть велик.

Күрше тавыгы күршегә күркә булып күренә.

Күрше тавыгы каз кебек, йомыркасы баш кебек.

Кеше тавыгы күрекле.

234. В чужих руках пирог больше, да и ломоть кажется толще.

к. 233.

235. В чужих руках ломоть велик, а как нам достанется — мал покажется.

к. 233.

236. В чужом глазу сучок видим, а в своем бревна не замечаем.

Борын астын күрми, урман артын актара.

Аяк астын тикшермичә, урман астын тикшерә.

Борын астындагы бүрәнәне күрми, урман артында очкан кошны күрә.

Урман артындагын күрә, бүрек астындагын күрми.

Үз борын астын күрмәгән урман артын тикшерер.

Үзенең төядәй эшен белми, кешенең төймәдәй эшен тикшерә.

237. В чужом пиру похмелье.

к. 61.

238. В чужую душу не влезешь.

к. 2714, 2770.

239. В чьи сани садишься, того и песню поёшь.

Кем арбасына (чанасына) утырсаң, шуның җырын җырларсың.

Кем көймәсендә, шуның көендә.

240. В шутку сказано, да всерьёз задумано.

Уйнап булса да, уйлап әйтелгән.

241. В этом и вся соль.

Бөтен тәме дә (кызыгы да) шунда.

| | |
|---|---|
| 242. Валять дурака. | Башны тилегә (юләргә) салу. |
| 243. Валять на авось. | к. 2732. |
| 244. Валяться в ногах. | Аягына (аяк астына) егылу. |
| 245. Вам поют, а нам наветки дают. | Кызым (улым), сиңа әйтәм, киленем, син тыңла. |
| 246. Вариться в собственном соку. | Үз маенда үзе куырылу.<br>Үз казанында үзенчә кайнау. |
| 247. Ваши пьют, а у нас с похмелья голова болит. | к. 61. |
| 248. Ввести в соблазн. | Күңелне аздыру.<br>Юлдан яздыру. |
| 249. Вдохнуть всем миром — ветер подымется. | Ил төкерсә, күл була, бер төкерсә, юк була.<br>Ил күмәкләшсә, яу кайтара. |
| 249 а. Век пережить — не поле переехать. | к. 760 а. |
| 250. Велик осел, да воду возят; мал сокол, да на руках носят. | Бакыр зур да казан ямыйлар, алтын кечкенә дә түшкә кадыйлар. |
| 251. Велик телом, да мал умом. | Тушы булса да ушы юк.<br>Ушы юк, тик тушы гына. |
| 252. Велика кобыла, да воду возят; мал соболёк, да на голове носят. | к. 250. |
| 253. Велика Федора, да дура, Иван мал, да удал. | Асыл сөяк зур булмас, кайда барса да хур булмас (к. 1270). |
| 254. Велико дело спасибо. | Бер рәхмәт мең бәладән коткара ди. |
| 255. Веника не сломишь, а по пруточку весь переломаешь. | к. 170, 215. |
| 256. Верёвки вить (*из кого*). | Кырыкка бөгү. |
| 257. Вернуться, не солоно хлебавши. | Буш (коры) кул белән кайту. |
| 258. Вертеть хвостом. | Койрык болгау (хәйләләү) |

259. Вертится, как белка в колесе. — к. 427.

260. Вертится, словно на ежа сел. — к. 2306.

261. Верь чужим речам, а ещё больше—своим очам. — Ышан сүзенә, бигрәк тә — үз күзеңә (к. 1481).

262. Весенний лёд толст, да прост, осенний тонок, да цепок. — Язгы бозның ястык калынлыгына да ышанма, көзге бозның көзге калынлыгына да ышан.

263. Весна красна цветами, а осень — пирогами (плодами, снопами). — Яз чәчәге белән, көз җимеше (ашлыгы) белән.

264. Весь сыт, а глаза голодны. — Убырның үзе туйса да, күзе туймый (к. 120).

265. Вечная история. — Һаман бер үк нәрсә.

266. Вешаться на шею. — Муенына тагылу (асылыну).

267. Вешний день целый год кормит. — Язгы бер көн ел туйдыра.

268. Взвыла собака на свою голову. — Эт үз башына улый.

269. Взглянет глазком, станет праздничком (дарит рублем). — Күзен сирпеп бер караса, йөрәкләргә ял була.

270. Вздохнуть свободно. — Иркен сулыш алу.

271. Вздулся, как тесто на опаре. — Апара кебек кабару.
Ачы катык кебек кабару
Күркә кебек кабарыну.

272. Взлететь на воздух. — Күле күккә очу.

273. Взойдет солнце и к нам на двор. — Безнең түбәгә дә кояш чыгар әле (к. 121).

274. Взойдёт солнце и перед нашими воротами. — к. 121.

275. Взорваться, как порох. — Күкерт кебек кабыну.

276. Взял у чёрта рогожу, отдашь бубен и кожу. — к. 316.

277. Взялся за гуж, не говори, что не дюж. — Тәртә арасына кергәч, тарта алмыйм дип торма.

278. Взят из грязи, да посажен в князи. — Сәнәктән көрәк булган.
Кара куйдан ак туган, башын әллә кая куйган.
Күлмәксездән күлмәкле булган, башын әллә кая куйган.
Чыбыктан чыбыркы булган.
Үзен-үзе белмәгән үзен мәмәт санаган.

279. Взять в руки. — Кулга алу.

280. Взять в свои руки бразды правления. — Дилбегәне үз кулыңа алу

281. Взять верх. — Өстенлек алу.

282. Взять под свое крыло. — Канат астына алу (яклау мәгънәсендә).

283. Взять своё слово назад. — Сүзеңне кире (кайтарып) алу.

284. Взяться за ум. — Акыл керү.
Акылга утыру.

285. Видавший виды. — Күпне күргән.
Ачыны-төчене татыган.
Дөньяның ачысын-төчесен татыган.

286. Видеть (знать) насквозь. — Үтәдән-үтә күрү.

287. Видит глаз, да рука не сягнет. — Күз күрә дә, кул (буй) җитми.

288. Видит не далее своего носа. — Тар карашлы кеше.

289. Видит око, да зуб неймёт. — Күз күрә дә, теш үтми (к. 287).

290. Видна птица по полёту. — Кош һавада (очканда) билгеле (к. 2613).

291. Видно будет. — Күз күрер.

292. Вилять хвостом. — к. 258.

293. Винтика не хватает. — Бер тактасы җитми (ким).
Гәрәңкәсе җиңел.
Йөзгә бер тулмаган.

Туксан тугызлы.
Утыз тугызлы—кырыкка бер тулмаган.

294. Висеть на волоске (на ниточке). — Кыл өстендә тору.

295. Витать в облаках. — к. 191.

296. Владеть собою. — Үз-үзеңне тота белү.
Үз-үзеңне кулда тоту.

297. Влезть в душу. — к. 37, 80.

298. Вне себя. — Үз-үзен белештермичә.

299. Во благо время много друзей, а в безвременьи и свои оставляют. — Акча барда бар да дус шул, бар да яр: акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр.
*(Г. Тукай.)*

300. Во времена оны. — Хан заманында.
Әби патша заманында.

301. Во время брани добра не говорят. — Кычкырышка яхшы сүз керми.

302. Во все лопатки. — Бөтен көчкә.
Җан-фәрманга.

303. Во всем знай меру. — Һәрнәрсәнең чиге булырга тиеш.
Үз чамаңны үзең бел.

304. Во всю прыть. — к. 302.

305. Во цвете лет. — Чәчәк чагы (вакыты).
Чәчәк аткан чагы.
Яшьнәп торган чагы.

306. Во что бы то ни стало. — Ни генә булмасын.
Ничек кенә булса да.

307. Вогнать в гроб (в могилу). — Кабергә кертү.

308. Вода мутнеет с истока. — Су баштан болгана.
Диңгез баштан болгана.

309. Вода с водой, не как гора с горой, сливается. — к. 505.

309 а. Водить за нос. — Алдап йөртү.
Алдап-йолдап йөртү.

310. Воду в ступе толочь. — Юкны бушка аудару (бушату).
Комнан аркан ишү.

| | |
|---|---|
| | Корыны бушка аудару.<br>Сәнәк белән җил куу. |
| 311. Воду толочь — вода и будет. | Су язып, май төшмәс. |
| 312. Возводить клевету. | Яла ягу |
| 313. Воздушные замки (строить). | Буш хыяллар (белән хыяллану). |
| 314. Возле пылу постой — раскраснеешься, возле сажи — замараешься. | Казанга якын барсаң, карасы йогар, яманга якын барсаң, бәласе йогар. |
| 315. Возносить до облаков. | Күкләргә күтәрү (чөю). |
| 316. Возьмёшь лычка, отдашь ремешок. | Кешенең юкәсен өзсәң, каеш түләрсең. |
| 317. Войти в плоть и кровь. | Канга сеңү. |
| 318. Войти в привычку. | Гадәт булып китү.<br>Гадәткә керү. |
| 319. Волей-неволей. | Ирекле-ирексез. |
| 320. Волею-неволею; хочешь-не хочешь. | Теләсәң-теләмәсәң дә. |
| 321. Волк в овечьей шкуре. | Сарык тиресе бөркәнгән бүре. |
| 322. Волк волка не съест. | Аюны аю ашамас, бүрене бүре ашамас.<br>Бер юлдан йөргән бүреләр берен-бере ашамас.<br>Түрә түрәне яклар (к. 335). |
| 323. Волка ноги кормят. | Бүрене аягы туйдыра. |
| 324. Волков бояться — в лес не ходить. | Бүредән курыккан урманга бармас.<br>Аюдан курыккан урманга бармас (к. 100). |
| 325. Волос долог, да ум короток. | Чәче озын, акылы кыска. |
| 326. Волосом не трону (не обижу). | Тырнак белән дә чиертмәм (к. 1844). |
| 327. Волосы встают дыбом. | Чәчләр үрә тора. |
| 328. Волчий аппетит. | Аю (ат) урынына ашый. |
| 329. Вольно было Фомушке жениться на вдовушке. | Теләп алган картаң. |

ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

| | |
|---|---|
| | Үзе абынган (егылган бала еламас. |
| 330. Вольному воля, спасённому рай. | Ихтыярың — үз кыярың.<br>Мәйлең — падиша. |
| 331. Вор ворует не для прибыли, а для своей гибели. | Карак үз башына урлый. |
| 332. Вор лучше пожара. | Карак берне алса, ут кырып сала. |
| 333. Вор слезлив, а плут богомолен. | к. 2616. |
| 334. Вор у вора дубинку украл. | Каракныкын бур урлый. |
| 335. Ворон ворону глаз не выклюнет. | Карга күзен карга чукымый (к. 322). |
| 336. Ворон считать. | Авыз ачып тору. |
| 337. Ворона под пару вороне, а сорока—сороке. | Ишише белән, иш кошы белән (к. 2266). |
| 338. Ворона в павлиньих перьях. | Салам торхан. |
| 339. Воспрянуть духом. | Күңел күтәрелеп китү. |
| 340. Вот где собака зарыта! | Менә аның сере кайда икән!<br>Имәндә икән чикләвек!<br>Юкәдә икән чикләвек!<br>Хикмәте әнә кайда икән! |
| 341. Вот тебе бог, вот тебе порог. | Алдыңнан артың ыспай.<br>Килгән юлың тал утырткан, китәр юлың күрсәтим.<br>Килгән юлың тап-такыр.<br>Ишек ачык, юл такыр. |
| 342. Вот тебе на! | Менә сина кирәк булса!<br>Менә сиңа кирәк булса, иске авыздан яңа сүз! |
| 343. Вот тебе и раз! | к. 342. |
| 344. Впитал с молоком матери. | Ана сөте белән кергән. |
| 345. В пух и в прах (разнести). | Пыр туздыру.<br>Астын-өскә китерү.<br>Көлен күккә очыру. |
| 346. Время — деньги. | Вакыт—акчадыр, гафил булма — качадыр. |

347. Врёт и глазом не моргает (не сморгнёт).
Күзен дә йоммый алдый (ялганлый).

348. Врёт, не кашлянет.
к. 347.

349. Врёт, не поперхнётся.
к. 347.

350. Все беды пропали, что в воду упали.
Су белән юып алгандай булды (бәла, кайгы, авыру турында).

351. Все глаза проглядел.
Көтә-көтә көтек булып беттем.
Көтә-көтә күзләрем күмергә әйләнде.
Көтә-көтә күзләрем күгәрде.

352. Всё может случиться, и богатый к бедному стучится.
Дөнья куласа (тәгәрмәч), әйләнә дә бер баса.

353. (Все) на один покрой.
(Бар да) бер чыбыктан сөрелгән.
(Үзләрен) парга жигәрлек.

354. Все на один шлык.
к. 353.

355. Все на одну колодку.
Бар да (бөтенесе) бер калыпка суккан.

356. Все невесты хороши, а откуда берутся злые жёны.
Кыз чагында бар да яхшы була, кайдан чыга усал хатыннар.

357. Все одним миром мазаны.
к. 353, 355.

358. Всё пошло на ветер.
Бөтенесе җилгә китте (очты, туздырды).

359. Всё своё ладит.
Һаман үзенекен тукый.

360. Всё спустил и сам сел.
Бөтенесен җилгә туздырды.

361. Все уши прожужжать.
Колак итен ашау.
Колак итен чәйнәү.
Колакны тондыру.

362. Всему своё время.
Һәр эш жае белән, ботка пешә мае белән.
Һәр эшнең жае бар,
һәр ашның тәме бар.
Һәр нәрсә вакыты белән.

363. Всех дел не переделаешь (отговорка лодыря).
Эш бетми ул, үлгәч тә өч көнлек эш кала ди.

364. Вскорми ворона — он тебе очи выклюет.
к. 58.

| | |
|---|---|
| 365. Вскружить голову. | Башны әйләндерү. |
| 366. Вспоил, вскормил на себя ворога. | Үз башына үстергән икән (к. 58.) |
| 367. Вставлять палки в колёса. | Тәгәрмәченә таяк тыгу (кыстыру). |
| 368. Встать пораньше да шагнуть подальше. | Юлга чыксаң, иртәрәк чык.<br>Иртә чыккан юл алыр. |
| 369. Встать поперёк дороги. | Юлга аркылы төшү. |
| 370. Встречать с распростёртыми объятиями. | Кочак җәеп каршы алу.<br>Күтәреп кенә алмау. |
| 371. Всыпать горячих. | Бераз төшереп (биргәләп) алу (к. 54). |
| 372. Всю ночь собака на месяц пролаяла, а месяц того и не знает. | к. 2401. |
| 373. Всюду вхож как медный грош. | Ачмаган ишеге, кермәгән тишеге юк. |
| 374. Всяк знает, где его сапог жмёт. | Һәркем үз хәлен үзе белә. |
| 375. Всяк кулик на своём болоте велик. | Җирле җирендә, җикән күлендә.<br>Һәркем үз урынында зур. |
| 376. Всяк своим умом живет. | Һәркемнең үз акылы үзенә. |
| 377. Всякая птица свои песни поёт. | Барча кошның да үзенчә сайравы бар... (*Г. Тукай*).<br>Һәркем үзенчә каркылдый. |
| 378. Всякая работа мастера хвалит. | Эш иясе беләң.<br>Эш иясен мактый. |
| 379. Всякая собака по-своему лает. | Һәркем үзенчә өрә. |
| 380. Всякая сорока от своего языка погибает. | Тартар теленнән табар. |
| 382. Всякий дурак красному рад. | Тиле кызылга гашыйк.<br>Тиле кызылга кызыга. |
| 383. Всякий поп по-своему поёт. | к. 377. |
| 384. Всякий своим голосом поёт. | Һәркем үзенчә сөйли (эш итә). к. 377. |

385. Всякий смех о себе ударит. — Көлке көлә килә, артыннан куа килә.
Иртә көлсәң кешедән, кич көләрләр үзеңнән.

386. Всякий смех тридцать лет у ворот стоит. — к. 385.

387. Всякое даяние благо. — Читтән килгән ямаулык та зур.

388. Всякому овощу своё время. — Чәчәкне вакытында җыялар.
Һәр җимеш (үз) вакыты белән (к. 362).

389. Всякому своё дитя милее. — Һәркемнең үз баласы үзенә якын.

390. Всякому своё и не мыто бело. — Һәркемнеке үзенә ай күренә күзенә (к. 879).

391. Всякому своё счастье. — Һәркемнең үз бәхете үзенә.
Һәркем үз бәхете белән.
Кеше бәхетенә кеше керми.

392. Всякому своя болезнь больна. — Һәркемнең үз хәле хәл.

393. Втирать очки. — Күз буяу (алдау мәгънәсендә).

394. Вы что, с луны свалились? — Теге дөньядан кайттыгызмы әллә?
Айдан төштеңме әллә?

394а. Выбить почву из-под ног. — Тез астына сугу.

395. Выбиться (выйти) из колеи. — Чыгырыннан чыгу.

396. Выбиться из сил. — Хәлдән таю.

397. Выбиться в люди. — Кеше рәтенә керү.
Кеше арасына керү.

398. Выбрала молодца, так уж после не пеняй на отца. — к. 329.

399. Выбросить деньги на ветер. — Акчаны җилгә очыру (туздыру).

400. Вывести из строя. — Сафтан чыгару.

401. Вывести на чистую воду. — Йөзен ачу.
Йөзен фаш итү.

| | |
|---|---|
| 402. Выглядеть моложе своих лет. | Яшь чырайлы булу (күренү). |
| 403. Выдрать за уши. | Колакны бору. |
| 404. Выжать (высосать) все соки. | Җелеген суыру. |
| 405. Выжить из ума. | Акылдан шашу.<br>Акылдан язу. |
| 406. Выйти из границ (из рамок). | Чиктән чыгу.<br>Чиктән ашу. |
| 407. Выйти из себя. | Үз-үзен тыя алмау.<br>Үз-үзен тота алмау. |
| 408. Выйти из терпения. | Түземлек төкәнү (бетү).<br>Сабырлыкны югалту. |
| 409. Выйти чистым. | к. 922. |
| 410. Выкинуть из головы. | Баштан чыгарып ташлау. |
| 411. Выкормил змейку на свою шейку. | Куенында елан җылыткан.<br>Этне үз башына симерткән (к. 58). |
| 412. Вылитый отец (мать). | Койган да куйган, нәкъ атасы (яки нәкъ анасы).<br>Суйган да каплаган, нәкъ атасы (яки нәкъ анасы).<br>Тамып (өзелеп) төшкән.<br>Чапмаган да, юнмаган да. |
| 413. Выменял кукушку на ястреба. | Балта биреп шөшле алган.<br>Сандугачны каргага алыштырган. |
| 414. Вымокнуть до нитки. | (Коры) җеп бөртеге дә калмау.<br>Манма су булу. |
| 415. Вымотать душу. | Теңкәгә тию (тиеп бетү).<br>Үзәккә үтү. |
| 415а. Выносить сор из избы. | Өендәгеn тышка чыгару.<br>Өйдәге хәлне кешегә сөйләү (чыгару). |
| 416. Вынь да положь. | Аңа чыгар да сал булсын (булмаслык, үти алмаслык таләп турында). |
| 417. Выплакать глаза. | Елый-елый күзсез калу. |

| | |
|---|---|
| 418. Вырасти вырос, а ума не вынес. | Буе үскән, акылы үсмәгән.<br>Гәүдәсе бар, башы юк.<br>Тушы бар, ушы юк. |
| 419. Вырвать с корнем. | Тамырын корыту.<br>Тамыры белән йолкып ташлау. |
| 420. Вырыть себе могилу. | Үзенә-үзе кабер казу. |
| 421. Высмотрел все глаза. | к. 351. |
| 422. Высоко летает, да где-то сядет. | Очуын югары оча да, кайда утырыр. |
| 423. Выставить грудь. | Күкрәк (не) киерү.<br>Түшне киерү. |
| 424. Выстрелив, пулю не схватишь, и сказав, слово не поймаешь. | Әйткән сүз — аткан ук: кире кайтмый.<br>Әйткән сүз кире кайтмый, кискән икмәк кире ябышмый (к. 2363). |
| 425. Вытянуть в нитку. | Тигез сафка тезү. |
| 426. Выше лба уши не растут (о несбыточном). | Башны колак узмый. |
| 426а. Выше носу плюнешь — себя заплюнешь. | Югары (күккә) төкерсәң, битеңә төшәр. |
| 427. Вьётся ужом. | Еландай бөтерелә.<br>Җирдә елан булып ишелә. |
| 428. Въехать в морду. | Яңагына менеп төшү.<br>Ипи шүрлегенә менеп төшү. |
| 429. Вяжись лычко с лычком, а ремешок с ремешком. | Тибешкәндә дә тиңең булсын.<br>Тиңең белән тибешкәндә дә килешә. |

## Г

| | |
|---|---|
| 430. Гадать на кофейной гуще. | Һавадан алып сөйләү (юкны сөйләү). |
| 431. Где баба, там рынок, где две — там базар. | Алты хатын бер базар. |

| | |
|---|---|
| 432. Где беде быть, там ее не миновать. | Күрәсене күрми, гүргә кереп булмый. Язмыштан узмыш юк. |
| 433. Где больно, там рука, где мило, там глаза. | Авырткан җирдән кул китми, сөйгән кешедән күз китми. |
| 434. Где две бабы, там суём (сход), а где три — там содом. | к. 431. |
| 435. Где дрова рубят, там и щепа валится. | к. 437, 1212. |
| 436. Где дым, там и огонь. | Утсыз төтен булмый. Җилсез яфрак (кура) селкенми. |
| 437. Где конь катается (ложится), там и шерсть останется. | Ат аунаган җирдә төк калыр (к. 1212). |
| 438. Где лад, там и клад. | к. 170. |
| 439. Где мило, там глядь-поглядь, где больно, там хват-похват. | к. 433. |
| 440. Где ногой ступит, там и трава не растёт. | Баскан җирендә үлән корый, эчкән җирендә су кибә. |
| 441. Где нянек много, там дитя безного. | к. 2602. |
| 442. Где один горюет, там артель воюет. | Ил көче — Идел көче. Күмәкләшкән — яу кайтарган. |
| 443. Где сердце лежит, туда и око бежит. | Яраткан (сөйгән) кешедән күз китми (к. 433). |
| 444. Где тонко, там и рвется. | Җеп нечкә җирдән өзелә (бәла, бәхетсезлек турында). |
| 445. Где хорошо, там отечество (*устар.*) | Туган җирдән торган җир яхшы (*искер.*) |
| 446. Где хотенье, там и уменье. | Теләге булган булдырган. |
| 447. Гладить по шерсти. | Йон ыспаена сыпыру. Йонны ятышына таба сыпыру. |
| 448. Гладко сошло. | Шоп-шома үтеп китте. |
| 449. Гладко стелит, да кочковато спать. | к. 1346. |

| | |
|---|---|
| 450. Глаз не казать. | Күзгә-башка күренмәү. |
| 451. Глаз не сводить. | Күз алмау.<br>Күз язмау. |
| 452. Глаз не сомкнуть. | Керфек какмау. |
| 453. Глаз не спускать. | к. 451. |
| 454. Глаза без души слепы, уши без сердца глухи. | Күңел күзе булмаса, маңгай күзе ботак тишеге. |
| 455. Глаза бы не глядели. | Күрәсем дә (карыйсым да) килми!<br>Күземә күренмәсен.<br>Күзем күрмәсен иде! |
| 456. Глаза на выкате. | Акай күз.<br>Шар күз. |
| 457. Глаза на мокром месте. | Күзеннән агыза да тора. |
| 458. Глаза налились кровью. | Күзләрне кан баскан. |
| 459. Глаза страшат, а руки делают. | Күз куркак, кул батыр. |
| 460. Глаза шире брюха. | Ач күзле.<br>Туймас күз. |
| 461. Глазами ест (пожирает). | Күзләре белән ашый. |
| 462. Глубокая ночь. | Җиде төн уртасы. |
| 463. Глубокая тайна. | Тирән сѐр.<br>Яшерен сер. |
| 464. Глуп, как пробка. | к. 1143. |
| 465. Глупый ищет большого места, а умного и в углу видать. | Тиле түргә үрелер, акыллы почмактан күренер. |
| 466. Глупый осудит, а умный рассудит. | Тиле гаеп итәр, акыллы фикер итәр. |
| 467. Глупый свистнет, а умный смыслит. | Акыллы уйлап торганчы, тиле эшен бетергән. |
| 468. Глухая ночь. | к. 462. |
| 469. Глухому попу две обедни не служат (не поют). | Һәрбер саңгырауга чаң какмыйлар.<br>Ишетмәгәнгә ике рәт азан әйтмиләр. |
| 470. Глядеть боком. | Кырын карау.<br>Күз кырые белән карау. |
| 471. Глядеть бычком. | Каш астыннан карау.<br>Үгез кебек карау. |

472. Глядеть в гроб. — к. 154.

473. Глядеть в оба. — Сак булу.
Алны-артны карап йөрү (эш итү).

474. Глядеть глядим, а видеть, ничего не видим. — к. 2701.

475. Гнаться за двумя зайцами. — Ике куян артыннан куу.
Ике көймә койрыгын тоту.

476. Гни дерево, пока гнётся, учи дитятку, пока слушается. — к. 477.

477. Гни прут, пока гнётся, не дай ему вырасти в бревно. — Агачны чыбык чакта бөгәргә кирәк.
Чыбык чакта бөгелмәгән, таяк булгач бөгелми.
Чыбык вакытында бөкмәсән, зурайгач бөгә алмассың (к. 612).

478. Гнило слово от гнилого сердца. — Яман кешедән яман сүз ишетерсең.

479. Гнуть свою линию. — Үзенекен сукалау.
Үзенекен туку.

480. Гнуть спину (шею). — Баш ию.
Арка бөгү.
Бил бөгү.

481. Говори с другими поменьше, да с собой побольше. — Телең белән фикер йөртмә, акылың белән фикер йөрт.
Белгәненне сөйләмә, ни сөйләгәненне бел.

482. Говорит день до вечера, а слушать нечего. — Сүзе сүзгә ошамый, авызы сүздән бушамый.
Теленең тупсасы юк, авызының туктасы юк.

483. Говорить правду — терять дружбу. — Туры әйткән туганына ярамый.
Туры әйткән тутакайга ярамаган.

484. Говорить, взвешивая слова. — Сүзне үлчәп сөйләү.

| | |
|---|---|
| 485. Говорить со своей колокольни. | Үз төнлегеңнән генә карап сөйләү. |
| 486. Говоря про чужих, услышишь и про своих. | Гаеп сүз сөйләсәң, гаеп сүз ишетерсең.<br>Авызың ни әйтсә, колагың шуны ишетер. |
| 487. Говорят, в Москве кур доят. | Агыйделнең аръягында ике энәгә бер сыер.<br>Бохарада бер энәгә бер сыер, барып баксаң, ни дә юк. |
| 488. Говорят с уха на ухо, а слышно с угла на угол. | Чыш-пышны бөтен шәһәр белгән. |
| 489. Гол как сокол. | Шыр ялангач.<br>Үзе дә күзе генә. |
| 490. Гол, но сокол. | Ярлы тәкәббер. |
| 491. Голова идет кругом. | Баш(ым) катты.<br>Баш(ым) әйләнде (әйләнеп бетте). |
| 492. Голова садовая. | Ачык авыз. |
| 493. Голова трещит. | Баш(ым) ярыла.<br>Баш(ым) чатный. |
| 494. Головой отвечать. | Башың белән җавап бирү. |
| 495. Голову морочить. | Башны катыру. |
| 496. Голову повесить. | Башны асу.<br>Башны түбән ию (күңелсез мәгънәсендә). |
| 497. Голову на отсечение даю. | Башымны (муенымны) кисәргә бирәм. |
| 498. Голову прозакладываю. | к. 497. |
| 499. Голову свернуть. | Муенын бору (яки сындыру). |
| 500. Голодному вздыхается, а сытому отрыгается. | Ач үкерә, тук кикерә. |
| 501. Голодной куме хлеб на уме. | Ачның күңеле икмәктә.<br>Ачның күңеле икмәктә, тукның күңеле хикмәттә. |
| 502. Голодной курице просо снится. | Тавык төшенә тары керә. |

503. Голый обман. — Чеп-чи ялган.

504. Гоняться за мухой с обухом. — к. 2501.

505. Гора с горой не сойдётся, а человек с человеком столкнётся (или сходится). — Тау белән тау гына очрашмый, кеше кеше белән очраша.
Тау тауга бәрелмәсә дә, адәм адәмгә бәрелә.

506. Гора с горой не сойдётся, а горшок с горшком столкнётся. — к. 505.

507. Гора с плеч (свалилась). — Өстән тау төшкәндәй булды.
Өстән авыр йөк төште (төшкәндәй булды).

508. Горбатого могила исправит. — Бөкрене кабер генә турайта (төзәтә).
Кәкрене тезгә салсаң да тураймас.
Ана сөте белән кермәгән — тана сөте белән кермәс (к. 1133).

509. Гордись не ростом, а умом. — Буй белән түгел, уй белән.
Буй белән су үлчәмиләр.
Буй белән җир үлчәмәссең.
Буең булмасын, акылың булсын.

510. Горесть не принять — сладость не видать. — к. 1557, 1709.

511. Гореть любовью. — Мәхәббәт утында яну.

512. Гореть ненавистью. — Нәфрәт уты белән яну.

513. Гореть от (со) стыда. — Оялудан бит алмалары утланып яну.
Оятыннан кып-кызыл (комач кебек) кызару.

514. Городить чепуху. — Юк-барны сөйләү.

| | |
|---|---|
| 515. Горох к стенке не прильнёт. | Стенага борчак ябышмый. |
| 516. Гору разрушает ветер, людскую дружбу — слово. | Дөньяны — җил, адәмне сүз бозар. |
| 517. Горшок котлу смеётся, а оба черны. | Ертык тишектән көлә. |
| 518. Горькая доля. | Авыр (ачы) язмыш.<br>Кара язмыш. |
| 519. Горькая истина. | Ачы хакыйкать. |
| 520. Горько плакать. | Кан елау. |
| 521. Горючими слезами обливаться. | Кайнар күз яшьләре түгү (кою). |
| 522. Горячее дело. | Кызу эш. |
| 523. Господин своего слова. | Үз сүзенә үзе хуҗа.<br>Сүзенә хуҗа була торган кеше. |
| 524. Гости навалили, а хозяина с ног сбили. | Кунак кунак өстенә — хозяин (хуҗа) бит өстенә. |
| 525. Гость во власти хозяина. | Кунак — хуҗаның ишәге. |
| 526. Гость гости, а кошелёк прости. | Кунак килсә, ит пешә, ит пешмәсә, бит пешә.<br>Кунак килсә, таптыра, тиресле җирне саттыра. |
| 527. Гость — невольный человек: где посадят, тут и сидит. | к. 525. |
| 528. Гость недолго гостит, да много видит. | Кунак аз утырыр, күп сынар. |
| 529. Гость погостит, да домой поспешит. | Кунак килер дә китәр, үз җаеңны үзең кара. |
| 530. Гость у хозяина в руках. | к. 525. |
| 531. Готов был сквозь землю провалиться. | Җир үтә китәрдәй булдым.<br>Җир тишегенә керерлек булдым.<br>Җиргә керерлек булдым (бик нык оялдым дигән мәгънәдә). |

| | |
|---|---|
| 532. Грешным делом. | Гөнаһ шомлыгына каршы. |
| 533. Грех попутал. | Шайтан котыртты. |
| 534. Громовая стрела. | Таш бармак. |
| 535. Гробовая тишина. | Кабер тынлыгы. |
| 536. Гробовое молчание. | к. 535. |
| 537. Грозцы грозят, а жильцы живут. | к. 2401. |
| 538. Гроша медного не стоит. | Сукыр бер тиен дә тормый. |
| 539. Гроша нет за душой. | Сукыр бер тиенем дә юк. |
| 540. Губа не дура! | Авызы тәм сизә (тоя)! Борыны ис сизә! |
| 541. Губы надуть. | Авыз турсайту. |
| 542. Губы не обсохли. | к. 1325. |
| 543. Гудит (или шумит) в ушах. | Колаклар шаулый. |

## Д

| | |
|---|---|
| 544. Да будет земля ему пухом! | Авыр туфрагы җиңел булсын! |
| 545. Да оскудеет рука моя. | к. 546. |
| 546. Да отсохнет рука моя. | Кулым корсын. Кулым черсен. |
| 547. Давай бог ноги. | Табанын ялтырату. |
| 548. Давши слово держись, а не давши, крепись! | Әйттеңме — кайтма! Әйткән сүз — каккан казык. |
| 549. Дадут дураку честь, так не знает где и сесть. | Тиле түрен белмәс. |
| 550. Даже бровью не поведёт. | Керфеген дә селкетми (искитмәү мәгънәсендә). Керфек тә какмый. Күзен дә йоммый (к. 1545). |
| 551. Даже камни возопили бы. | Таш әрер иде. Таш елар иде. |

552. Даже не нюхал.

Борынына да кермәгән.
(Гомерендә) иснәмәгән дә.

553. Дай бог, чтоб земля на нём легким пухом лежала!

к. 544.

554. Дай голому холст, а он скажет: толст.

Хәерчегә кыяр биргәннәр, — кәкре икән, дигән.

555. Дай грош, так будешь хорош.

Биргән бигә яраган, бирмәгән нигә яраган?

556. Дай с ноготок — попросит с локоток.

Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң, ямаулык сорый.

557. Дай только ногу поставить, а весь-то я и сам влезу.

Таягы керсә, аягы да керәсе.

558. Дай яичко, да ещё облупленное.

Балык бирсәң, бәйләп бир, башын-күзен чәйнәп бир (к. 729).

559. Дал ротик, даст и кусок.

к. 81.

560. Дал топор, дай и топорище.

к. 556.

561. Дали бабе холст, говорит: „толст"; дали и потоне — говорит: „дай более".

к. 556.

562. Дали голодной Маланье оладьи, а она говорит: испечены неладно.

к. 554.

563. Дальше положишь — ближе возьмёшь.

Еракка куйсаң, якыннан алырсың.

564. Дальше спрячешь — скорее найдёшь.

к. 563.

565. Дарёному (даровому) коню в зубы не смотрят.

Бүләк атның тешенә карамыйлар.
Биргәннең битенә карамыйлар.
Биргәннең битенә бакмыйлар.
Дөя дә бүләк, төймә дә бүләк.

566. Дать берёзовой каши.

к. 54.

567. Дать драла. — к. 569.

568. Дать лычко, чтобы получить ремешок. — Үрдәк биреп каз алу.
Үрдәк бирсәң, каз алырсың.

569. Дать (задать) стрекача. — Табан ялтырату (бик тиз качып китү мәгънәсендә).
Кыяк тешләү.

570. Дать трезвую оценку. — Аек бәя бирү.

571. Дают — бери, бранят — беги. — Чакырганда — бар, куганда — кайт (кит).
Биргәндә — ал, куганда — кит (к. 572).

572. Дают — бери, бьют — беги. — Чакырганда — бар, чакканда кач (к. 571).

573. Два века не проживёшь, две молодости не перейдёшь. — Яшьлек ике килми.

574. Два глаза и те за носом. — к. 2727.

575. Два медведя в одной берлоге не уживутся. — к. 577.

576. Два сапога пара. — Чиләгенә күрә капкачы.
Бер калыпка суккан.
Икесе дә бер очтан кискән.

577. Две бараньи головы в один котёл не лезут. — Ике тәкә башы бер казанга сыймас.
Ике куйның башы бер табакка сыймас.

578. Две головни курятся, а одна никогда. — Ялгыз утын янмас.
Ялгыз утын янмас, ялгыз куен елынмас.

579. Две кошки в одном мешке не улягутся. — к. 577.

580. Две собаки грызутся — третья не мешайся. — Эт белән эт талашыр, авызын-борынын ялашыр.

581. Две стороны одной медали. — Бер үк медальнең ике ягы.

582. Дверь на петлях не стоит. — Ишек ябылып мормый (килүче-китүче күп мәгънәсендә).

583. Двум головам на одних плечах тесно. — к. 577.

584. Двум смертям не бывать, одной не миновать. — Үлем бер хак.
Үлем ике килми.

585. Двум телятам (коровам) корму не даст. — Ике бозауга кибәк (башак) аера белми.

586. Девка не мак: в один день не облетит. — ≅Бал кортламас, кыз картаймас.

587. Девушки хороши, красные пригожи! да откуда злые жёны берутся? — Кыз чагында бар да яхшы була, кайдан чыга усал хатыннар?

588. Дел по горло. — Эш муеннан.

589. Дела как сажа бела. — Эшләр хөрти (начар).

590. Дела не делаю, а от дела не бегаю. — ≅ Эшләмәгән эшем юк, кинәндергән төшем юк.

591. Делать из мухи слона. — Төймәдән дөя ясау.
Инә күзеннән дөя күрү.

592. Делать (сделать) упор. — Басым ясау; басым ясап әйтү.

593. Делить шкуру неубитого медведя. — Үтермәгән аюның тиресен тунау.
Аюны үтермәс борын тиресен сату.
Алмаган ат, тумаган тай.
Тумаган балага бишек кору.
Тумаган тайга атлану.
Тумаган тайның билен сындыру.
Яумаган яңгырга балаган кору.
Тавык йомырка салмаган, чебешләрне сатарга уйлый.

594. Дело в шляпе. — Эш бетте, көлтә генә җыясы калды.

595. Дело выеденного яйца не стоит. — Сукыр бер тиен дә тормый.

596. Дело клином сошлось. — Көймә комга терәлде.

597. Дело мастера боится. — Эш остасыннан курка.

598. Дело не вяжется. — Эшнең рәте юк.
Эш бармый.

| | |
|---|---|
| 599. Дело не голуби, не разлетятся. | к. 2115. |
| 600. Дело не медведь, в лес не уйдёт. | к. 2115. |
| 601. Дело огнём горит. | Кулында эш уйнап кына тора.<br>Ут өереп эшли. |
| 602. Денежка не бог, а полбога есть. | Акча — дөнья иманы. |
| 603. День летний год кормит. | Җәйге бер көн ел ашата (туйдыра). |
| 604. День меркнет ночью, а человек печалью. | Кешене хәсрәт саргайта. |
| 605. Деньга на деньги набегает. | Акча акчаны ярата.<br>Акча акчаны таба. |
| 606. Деньги без глаз. | Акчаның күзе юк. |
| 607. Деньги любят счёт. | Акча санауны ярата. |
| 608. Деньги не голова: наживное дело. | Мал бәя түгел, баш бәя.<br>Мал казасы баш казасы түгел; мал табыла, баш табылмый. |
| 609. Деньги — пух, только дунь на них и нет. | Акча кош, бик тиз оча. |
| 610. Деньги слепы: за что отдаёшь, не видят. | к. 606. |
| 611. Деньги, что вода. | Акча су кебек ага. |
| 612. Дерево гнётся пока молодо. | Агач чыбык чакта бөгелә (к. 477). |
| 613. Дерево от плодов, человек от дел познаётся. | Агач җимеше белән, кеше эше белән.<br>Агач беленә җимешеннән, адәм—кыланышыннан. |
| 614. Дерево смотри в плодах, человека — в делах. | к. 613. |
| 615. Дерёт уши (противно слуху). | Колакны ерта. |
| 616. Держать в ежовых рукавицах. | Каты (кулда) тоту. |
| 617. Держать в чёрном теле. | Көн күрсәтмәү. |

| | |
|---|---|
| 618. Держать камень за пазухой. | Куенында таш йөртү (саклау). |
| 619. Держать нос по ветру. | Җил кай якка иссә, шул якка борылу.<br>Җил ягына авышу.<br>Җил искән якка аву. |
| 620. Держать своё слово. | Сүзендә тору. |
| 621. Держать ухо востро. | Уяу булу.<br>Сак булу. |
| 622. Держи язык за зубами. | Телеңне тый.<br>Телеңне тешеңә кыстыр. |
| 623. Держи карман шире! | Тот капчыгыңны!<br>Тарт танавыңны!<br>Хәзерләгән ди, көтеп тор. |
| 624. Дерзок на язык. | Ачы телле. |
| 625. Десятая вода на киселе. | Ботак очы.<br>Чыбык очы (туганыбыз). |
| 626. Дёшево да гнило, дорого да мило. | Очсызның арты тынычсыз.<br>Очсызның тозы татымас.<br>Кыйммәт булса — хикмәте бар, арзан булса — гыйльләте бар. |
| 627. Дешёвое удовольствие. | Кечкенә рәхәт (ләззәт). |
| 628. Диву даваться. | Таңга калу. |
| 629. Дитя не плачет, мать не разумеет. | Еламаган балага имчәк бирмиләр. |
| 630. Длинный язык. | Озын телле. |
| 631. Для милого друга и волы из плуга. | к. 632. |
| 632. Для милого дружка и серёжку из ушка. | Син дигәндә аяк идәндә.<br>Син дигәндә мин коры бүкәннән корбан чалам.<br>Син дигәндә мин өч көн якмаган мичкә керәм.<br>Син дигәндә сәнәк тә кирәк. |
| 633. Для очистки совести. | Вөҗдан тынычлыгы өчен. |

634. Днём со свечой (огнём, фонарём) не отыскать. — Көндез шәм (чыра) яндырып эзләсәң дә таба алмассың.

635. Дни его сочтены. — Көннәре санаулы.

636. До небес вознести. — Күкләргә күтәрү (чөю).

637. До нитки (обобрать). — Шыр ялангач калдыру.
Шәрә көе калдыру.
Штансыз калдыру.

638. До свадьбы заживёт. — Туена чаклы төзәлер.

639. Добрая жена — веселье, а худая — злое зельё. — Хатын уңса — казна, уңмаса — каза.

640. Добрая жена дом сбережёт, плохая — рукавом разнесёт. — Булдырган да хатын, бөлдергән дә хатын.

641. Добрая женитьба к дому приучает, худая от дому отлучает. — ≌ Бөлдергән дә хатын, көлдергән дә хатын (к. 639).

642. Добрая слава лежит, а худая по свету бежит. — Яман хәбәр — озын колаклы.
Яман х бәр — озын аяклы, ялган сөйләүче — озын колаклы.

643. Добро не умрёт, а зло пропадёт. — Яхшылык җирдә ятмас.
Яхшылык онытылмас, яманлык җиргә күмелмәс.

644. Добро пожаловать, а сам за шапку. — Үзе кунак чакырган, үзе баланга (урманга) киткән.

645. Добро скоро забывается, а худое в памяти сохраняется. — Яхшылык тиз онытыла, яманлык онытылмый.
Яхшылык күзгә күренми, яманлык күмеп куелмый.

646. Доброе дело и в воде не тонет. — Яхшылыкны кылып диңгезгә ташласаң да кайтыр.
Яхшылык ит тә диңгезгә ташла — балык белер, балык белмәсә, халык белер.

647. Доброе слово. — Яхшы сүз.
Йомшак сүз.

648. Доброе слово лучше мягкого пирога. — Яхшы сүз — җан азыгы, яман сүз — баш казыгы.

649. Добром сказать (сделать, уйти). — Яхшылык белән әйтү (эшләү, китү).

650. Добрую жену взять — ни скуки, ни горя не знать. — к. 639.

651. Добрые слова дороже богатства. — к. 648.

652. Добрый добру научает, а злой на зло наставляет. — Яхшыга ияргән ялпайган, яманга ияргән картайган.

Яхшыга ияргән — чәчәккә, яманга ияргән — тозакка. Яхшы белән юлдаш булсаң, эшең бетәр; яман белән юлдаш булсаң, башың бетәр.

Яхшы белән юлдаш булсаң, җитәрсең син моратка, яман белән юлдаш булсаң, калырсың син оятка.

653. Добрый привет и кошке приятен. — Яхшы сүзгә җан эри.

654. Добрый человек добру и учит. — к. 652.

655. Доведёт нужда пить из лужи. — Нужа печән ашата.

656. Дождёшься, как от вербы яблок. — Абага чәчәк атканда (к. 1072).

657. Дождь как из ведра. — Яңгыр чиләклэп коя.

658. Дойти до геркулесовых столбов. — Ахыр чиккә җитү.

659. Долг платежом красен. — Алмак күрке — бирмәк.

Алмак бирмәк белән ярашыр (к. 2620).

660. Долго будет жить. — Гомере озын булыр.

Гомерле булыр.

661. Долго ли до беды! — к. 19.

662. Долго прожил, да ума не нажил. — Яше күп тә акылы юк.

Яше зур да акылы кеч-
кенә.

663. Дом без детей — могила, дом с детьми — базар.
Балалы өй — базар, баласыз өй — мазар.

664. Дом высок, да под ним песок.
Өе биек, өйрәсе сыек.

665. Дома-то и не голод, да подарок дорог.
к. 1316.

666. Дома щи без круп, а в людях шапка в рубль!
Үз өендә умач умаганны кешегә барып токмач җәйгән.
Үз өендә өйрә пешерә белмәгәнне кеше өендә ботка пешерә.

667. Домом не управил — так и волостью не управит.
Үз өендә баш булмаган өязгә чыгып баш булмас.

668. Дорога, хоть кубарем ступай (гладкая).
Тимер (чуен) юл шикелле такыр (тигез) юл.
Таба кебек тап-такыр юл.

669. Дорого обойдётся.
Кыйммәткә төшәр.

670. Дорого яичко к Великодню.
к. 671.

671. Дорого яичко к светлому дню, а сыр молодой к Петрову дню.
Сырлы (буяулы) йомырка сабан туенда кыйммәт.

672. Дороже головы не стоит.
Баш бәясе түгел (к. 608).

673. Достаётся сычке от своего язычка.
к. 380.

674. Досталось ему на орехи.
Арт сабагын укыттылар.

675. Достать из-под земли.
Җир астыннан табу.
Жир тишегеннән табу.

676. Дочернины детки милее своих.
Балаң баласы балдан татлы

677. Дочь — чужое сокровище.
Кызлар — күрше тавыгы.

678. Дошёл до мозга костей.
Җелеккә үтте.

679. Драть глотку (горло).
Бугазы ертылганчы кычкыру.

680. Драть шкуру.
Тиресен тунау (талау мәгънәсендә).

681. Дрожать над каждой копейкой.

Бер тиен өчен җан бирергә тору.

Бер тиен өчен дерелдәп (калтыранып) тору.

682. Дрожит, как овечий хвост.

Куян кебек калтырый.

683. Друг познаётся в несчастье.

к. 684.

684. Друг познаётся при рати, да при беде.

Телчән дауда беленә, дус яуда беленә.

Ат яхшысы чанада, ир яхшысы сәфәрдә (яуда) беленә.

685. Другими (иными) словами.

Икенче төрле (итеп) әйткәндә.

686. Других не суди, на себя погляди.

Кешене тикшермә, үзеңне бел.

687. Другу и недругу не пожелаю.

Дуска-дошманга күрсәтмәсен.

Дусыма-дошманыма теләмимен.

688. Дружба — дружбой, а денежкам счёт.

Дусың дус булсын, хисабың дөрес булсын (к. 2519).

689. Дружба — дружбой, а служба — службой.

Дус дуслык белән, ә хезмәт эш белән.

690. Дружный табун и волков не боится.

к. 170.

691. Друзья познаются в беде (несчастье).

к. 684.

692. Дубовая голова.

Кабак баш (аңгыра баш).

693. Дурак красное любит.

к. 382.

694. Дурака пошли по ложку, а он тащит кошку.

Шөшле сораганга балта бирә.

Иләк сораганга чиләк бирә.

695. Дуракам закон не писан.

Тилегә түрә юк.

Тилегә суд юк.

696. Дураков не сеют — сами родятся.

Юләрне чәчеп үстермиләр, алар үзләре туа.

Юләрне чәчмиләр, үзе үсә.

697. Дурману объелся. — Тилебәрән орлыгы ашаган.

698. Дурная голова ногам покоя не даёт. — Башында белем булмаса, аягына авырлык.
Башың эшләмәсә, аягың ял итмәс.
Башың эшләмәсә, аякларга көч.

699. Дурная слава. — Яман ат.

700. Дурного (дурака) не спрашивай: сам скажет. — Тиледән сорама: үзе әйтер.

701. Дурной глаз. — Яман күз.

702. Дурной пример заразителен. — Яман чир тиз йога, яман гадәт тиз керә.

703. Дуть и в хвост и в гриву. — Борылырга да ирек бирмәү.

704. Дух времени. — Замана таләпләре.

705. Духу нехватает. — Йөрәк җитми.
Батырлык җитми.

706. Душа в пятки ушла. — Котым очты.
Котым ботыма җитте (төште).

707. Душа замирает. — Җаным калтырана.

708. Душа на распашку. — Эчендәге тышында.

709. Душа не лежит. — Күңел тартмый (ятмый).

710. Душа не на месте. — Җаным үз урынында түгел.

711. Душа не принимает. — Күңел бармый.
Күңел йөкләми.

712. Душа не принимает, а глаза всё просят. — к. 120.

713. Душа (сердце) разболелась. — Йөрәгемә кабынды.

714. Душа-человек. — Дөнья бәясе кеше.

715. Души не чаять. — Үлеп тору (бик ярату).
Күз өстендә каш к бек тоту.
Җаны да жәл түгел.

716. Душой и телом. — Җаны-тәне белән бирелеп.
Җанын фида кылырлык булып.

717. Душу раздирать. — Йөрәкне өзү.

718. Дыбом встать (о волосах).

Бәгырьне өзү.
Үзәкне өзү.
Үрә тору (чәч турында).

719. Дым отечества лучше, чем огонь на чужбине.

к. 885.

720. Дыма без огня не бывает.

к. 436.

721. Дырявая голова.

Тавык (тилгән) мие эчкән.

722. Дышит на ладан.

Авызыннан жаны чыгарга тора (җитешкән).
Үләр хәлгә җиткән.
Актык тәрәшлене элгән.

# Е

723. Его песенка спета.

Аның ясины укылган (җыры җырланган) инде.
Ашын ашаган, яшен яшәгән.
Туе узган, туны тузган.

724. Его сюда за космы не притянешь.

Аны аркан белән дә тарттырып китерә алмассың.

725. Едешь на день — бери хлеба на неделю.

Бер көнлек юлга чыксаң, атналык (җиде көнлек) азык ал.

726. Еле-еле душа в теле.

Авызын ачса, үпкәсе күренә.
Чыкмаган җаны гына бар (к. 722).

727. Ему замеси, да и в рот положи.

к. 558, 729.

728. Ему не жарко и не холодно.

Аңар эссе дә түгел, суык та түгел.

729. Ему разжуй да и в рот положи.

Авызына чәйнәп салганны көтә (к. 558).

730. Ему, хоть плюй в глаза, а он говорит: божья роса!

Аның битен юмаган.
Битенә төкерсәң дә сөртеп кенә ала.

731. Если бы, да кабы во рту росли бобы, был бы не рот, а целый огород.
„Дыр"ны чәчкәнгә илле ел ди, һаман да тишелмәгән ди.

732. Если вздохнуть всем народом — ветер будет.
Ил (мир) төкерсә, күл була.

733. Если вороны слетаются, значит пахнет мертвым телом.
Карга (чебен) үләксәгә җыела.

734. Если ложкой не наелся, языком не налижешься.
Ашап туймаганны ялап туймассың.

735. Если поклонишься, голова не отломится (не отвалится).
Селкенгәннән сын талмас, бөгелгәннән бил сынмас.

736. Если рука руку моет, то другая рука лицо моет.
к. 2162.

737. Если человека не знаешь, посмотри на его друга.
Кешенең кем икәнлеген беләсең килсә, дустын сына.

738. Есть всё, что угодно душеньке.
Җаныңа ни кирәк, бар да бар.

739. Есть (хлеба) не просит же.
Ашарга сорамый бит.

740. Ехать в Тулу со своим самоваром.
Урманга утын төяп бару.

741. Ешь до поту, работай до ознобу—дело пойдет скоро.
Ашаганда колагың селкенсен, эшләгәндә йөрәгең җилкенсен.

## Ж

742. Ждать у моря погоды.
Аяз күктән яңгыр көтү.
Һавадан очып барган торнадан, күкәй сал, күкәй сал, дип күктән күкәй көтеп яту.

743. Ждать со дня на день.
Бүген таңда көтү.

744. Ждать, чтобы жареные голуби в рот сами полетели.
Алма пеш, авызыма төш (к. 558, 729).

745. Жевать жвачку.
Бер үк балык башын чәйнәү.

ТІЛ БІЛІМІ

| | |
|---|---|
| 746. Жениться — не лапоть надеть. | Өйләнү—түгелдер сөйләнү. |
| 747. Жену выбирай не глазами, а ушами. | Ат алсаң — авылың белән, хатын алсаң — кавымың белән. |
| 748. Женщина без мужа, что конь без узды. | Ирсез хатын — йөгәнсез ат. |
| 749. Жестокий мороз. | Чатнама суык. |
| 750. Жива — наша, умерла — бога. | Үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын.<br>Пеште ни, төште ни — барыбер. |
| 751. Живая кость мясом обрастает. | Чыкмаган җанда өмет бар. |
| 752. Живём богато, со двора покато, чего ни хватись, всё в люди катись. | Берсе кешенеке, берсе күршенеке.<br>Икесе кешенеке, өчесе күршенеке. |
| 753. Живительная вода. | Терелтеп (хәл кертеп) җибәрә торган су. Тереклек суы. |
| 754. Живое существо. | Тереклек иясе. Җан иясе. |
| 755. Живут, как собака с кошкой. | Этле-мәчеле торалар. |
| 756. Живут рука в руку, душа в душу. | Күзгә-күз карашып кына торалар. |
| 757. Живьём проглотит (съест). | Терелэй тотып ашар. |
| 758. Жизнь вошла (попала) в колею. | Тормыш үз эзенә төште. |
| 759. Жизнь на волоске висит. | Җаны кыл өстендә генә тора. |
| 760. Жизнь на нитке. | к. 759. |
| 760а. Жизнь пережить — не поле перейти. | Гомер түгелдер күпер: чыгып китәргә генә түгел, бөтенесен күрәсең. |
| 761. Жирно будет. | Эчен тишелер.<br>Эчеңә тияр. |
| 762. Жить барски (по-барски). | Байларча яшәү. |

АХМЕТ БАЙТҰРСЫНҰЛЫ атындағы ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

763. Жить в совете. — Дус яшәү.
Тату яшәү.

764. Жить душа в душу. — Күзгә-күз карашып яшәү.
Бер-берсе өчен үлеп тору.

765. Жить на широкую ногу. — Муллыкта яшәү.
Иркен (лектә) яшәү (к. 1018).

766. Жить припеваючи. — Типтерен яшәү.
Үкертеп яшәү.
Рәхәт яшәү.

767. Жить только одним желудком. — Ашау (тамак) өчен генә яшәү.

768. Журавль в небесах, а синица в руках. — Һавадагы торнадан кулындагы чыпчык артыграк.
Һавадагы торнаны көтеп, кулыңдагы чыпчыкны ычкындырма.
Һавадагы торнаны тотам дип, кулындагы чыпчыктан коры калма.
Иртәге койрыктан бүгенгә үпкә яхшырак.

## З

769. За всё берётся — да не всё удаётся. — Эшләмәгән эше юк, кинәндергән төше юк.

770. За глаза довольно. — Артыгы белән (җиткән).
Җитеп арткан.

771. За глупою головою и ногам плохо. — к. 698.

772. За двумя зайцами погонишься — ни одного не поймаешь. — Ике куян артыннан куссаң, берсен дә тота алмассың.

773. За добро не жди добро. — Ит яхшылык — көт яманлык (явызлык).

774. За дурацкою головою и ногам неупокой. — к. 698.

775. За морем телушка полушка да рубль перевоз. — Әстерханда сыер бер акча, килә-килә мең акча.

| | |
|---|---|
| 776. За мужа завалюсь, никого не боюсь. | ≅ Аем туры бакканда, йолдызларга йодрык. |
| 777. За недобрым пойдёшь—на беду набредёшь. | Кешегә начарлык теләсәң, үзенә кайтыр (к. 1170, 15~2). |
| 778. За ответом за пазуху не полезет. | Җавапка аптырамый (к. 784). |
| 779. За своими щеками не удержал — за чужими не удержишь. | Үз авызында тотмаганны кеше авызында тотмассың. |
| 780. За семь вёрст киселя хлебать. | Юкка (бушка) вакыт уздырып, чабага туздырып йөрү. |
| 781. За семь вёрст комара искали, а комар на носу. | Борын астындагын алты ай эзләгән.<br>Астындагы атын алты ай эзләгән. |
| 782. За семью замками. | Җиде кат җир астында. |
| 783. За сердце берёт. | Йөрәккә үтә.<br>Үзәккә үтә. |
| 784. За словами в карман не полезет. | Сүзгә аптырамый.<br>Сүзне сатып алмый.<br>Сүз өчен күршегә керми (к. 778). |
| 785. За твоим языком не поспеешь и босиком. | Сөйләргә үзен җиде кала җиңмәс. |
| 786. За худом пойдёшь, не добро найдёшь. | к. 777. |
| 787. За час так, через час инако. | Әле генә болай, ул да түгел тегеләй.<br>Кырыкмаса кырык төргә керә.<br>Минутына кырык төрле акыл. |
| 788. За чужой головой поливай (маслом) как водой. | Үзем тапкан мал түгел, әтинеке җәл түгел.<br>Бабайныкы—илнеке дип әйтте ди борынгы кияү. |
| 789. Забрала тоска. | Кайгы басты. |
| 790. Забрало его за живое. | к. 800. |
| 791. Забросать грязью, | Пычрак ташлау.<br>Кара ягу. |

| | |
|---|---|
| 792. Загнать в могилу. | Кабергә кертү. |
| 793. Загребать жар чужими руками. | Кеше кулы белән утлы күмер көрәү.<br>Кеше кулы белән ут күсү. |
| 794. Задали памятку, что до новых веников не забудет. | Арт сабагын өйрәттеләр (укыттылар), озак вакытлар онытмас! |
| 795. Задать баню. | Мунча кертү.<br>Мунча чабындыру.<br>Себеркесез мунча чабындыру (бик нык тиргәү мәгънәсендә). |
| 796. Задать дёру. | к. 569. |
| 797. Задать жару. | Утлы (эссе) табага бастыру. |
| 798. Задать лататы. | к. 569. |
| 799. Задать перцу. | Суганлап-борычлап кыздыру (бик каты тиргәү мәгънәсендә). |
| 800. Задеть за живое. | Кәефенә тию. |
| 801. Задирать нос. | Борын күтәрү.<br>Борын чөю. |
| 802. Задние колёса наперёд не катятся. | Ал тәгәрмәч кайдан йөрсә, арт тәгәрмәч шуннан йөрер. |
| 803. Задним умом и всяк (и дурак) догадлив. | Тинтәккә акыл төштән соң төшәр. |
| 804. Задор берёт, да мочи нет. | Дәрт бар, дәрман юк. |
| 805. Задору много, да силы нет. | к. 804. |
| 806. Задурить голову. | Башын-күзен әйләндерү. |
| 807. Заедать (*чей-либо*) век. | Гомерен ашау. |
| 808. Закидывать (закинуть) удочку. | Кармак салу.<br>Кармак салып карау (к. 871). |
| 809. Заколоти в него хоть осиновый кол, он всё будет говорить соломинка, | Кайчы белән кырыккан.<br>Үз бер тиене бер тиен.<br>Үз биш тиене биш тиен.<br>Үз туксаны туксан, кешенең туксаны да сиксән. |

ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

| | |
|---|---|
| 810. Закрывать глаза. | Күз йому (мәсәлән, житешсезлекләргә). |
| 811. Заладила сорока Якова (одно про всякого). | Һаман бер балык башын чәйни. |
| 812. Залепить пощёчину. | Яңакка утырту.<br>Яңакка салу.<br>Яңакка менеп төшү. |
| 813. Замести следы. | Эзне югалту.<br>Эзне жую.<br>Эз яздыру. |
| 814. Замолвить слово. | Сүз кыстыру(яклап сүз әйтү). |
| 815. Заморить червячка. | Тамак ялгап алу.<br>Йөрәк ялгап алу. |
| 816. Замыкаться в свою скорлупу. | Үз кабыгыңа кереп бикләнү.<br>Үз кабыгына төренү. |
| 817. Запас беды не чинит. | Бар әйбердә зыян юк (эчеңне тишмәс). |
| 818. Запас мешка не дерёт. | к. 817. |
| 819. Запас хлеба не просит. | Ашарга сорамый (к. 817). |
| 820. Запестрело в глазах. | Күз алларым чуп-чуар (әлҗемөлҗе) булып китте. |
| 821. Заплыть жиром. | Май басу. |
| 822. Запили соседи — запьём и мы. | Күрше күрә кылана. |
| 823. Запрос по рылу не ударит. | Сораган өчен авызыңа сукмаслар. |
| 824. Запустить руки (лапы). | Кул сузу. |
| 825. Запутать след. | к. 813. |
| 826. Зарубить на носу (на лбу). | Колакка киртеп кую. |
| 827. Заря занимается. | Таң ата.<br>Таң сызыла.<br>Таң туа.<br>Таң ярыла. |
| 828. Зарядить одно и то же. | к. 811. |
| 829. Заснуть вечным сном. | Мәңгелек йокыга талу. |
| 830. Заставь дурака богу молиться, он и лоб расшибёт. | Тиле купса, зур куба. |

831. Застыть с разинутым ртом.
Авызын ачып катып калу.

832. Засыпь правду золотом, а она всплывёт.
Дөреслек (кайчан да булса) бер чыга.
Дөреслек җирдә ятмас.

833. Заткнуть глотку.
Авызын томалау (каплау).

834. Заткнуть за пояс.
Уздырып җибәрү.

835. Заткнуть рот (глотку).
Авызны томалау.

836. Затоптать в грязь.
Пычракка салып таптау.

837. Захотел ты от калачника дрождей!
к. 839.

838. Захотели у калачника дрожжей купить.
к. 839.

839. Захотел от кошки — лепёшки, от собаки — блинов.
Алырсың эт авызыннан сөякне.
Эт авызыннан белен алып булмас.
Алырсың шайтаннан иман!

840. Заячья губа.
Фыртык.
Дөя ирен.
Ертык ирен.

841. Звонки бубны за горами.
Агыйделнең аръягында ике энәгә бер сыер.

842. Звону много, да толку мало.
Төтене күп, ялкыны аз.

843. Здоров буду и денег добуду.
Баш исән булса, мал табылыр.

844. Здоровье дороже (лучше) богатства (денег).
Саулык — зур байлык.
Саулыкта байлык.

845. Земли под собой не чует.
Аягы җиргә тими.

846. Зеркало не виновато, коли рожа крива.
Авызың кыек булса, көзгегә үпкәләмә.

847. Зимой снега не выпросишь.
Кыш көне кар бирмәс (к. 1731, 2461).

848. Злая жена—та же змея.
Явыз хатын — шайтан камчысы.

849. Зла за зло не воздавай.
Таш белән атканга аш белән ат.

| | |
|---|---|
| 850. Зло помнить. | Ачу саклап йөрү. |
| 851. Зло сорвать. | Ачу алу.<br>Үч алу. |
| 852. Злословить за спиной. | Артында гайбәтен сату. |
| 853. Змею за пазухой держать. | к. 854. |
| 854. Змею за пазухой отогреть. | Куенында елан асрау. |
| 855. Змея подколодная. | Җир еланы.<br>Кара елан. |
| 856. Знает кошка, чьё мясо съела. | Үз гаебен үзе белә.<br>Май ашаган мәченең күзе ялтырый ди. |
| 857. Знай больше, говори меньше. | Күп бел, аз сөйлә. |
| 858. Знай сверчок свой шесток. | Үз урыныңны (үзең) бел. |
| 859. Знала бы наседка, узнает и соседка. | Яраусыз кешегә сүз әйтсәң, ярылып-ярылып йортка җәяр. |
| 860. Знать золото и на грязи. | Алмазны балчык арасына ташласаң да, алмаз булыр. |
| 861. Знать как свои пять пальцев. | Биш бармагың кебек белү. |
| 862. Знать как свою ладонь. | к. 861. |
| 863. Знать назубок. | Күңелдән белү.<br>Яттан белү. |
| 864. Знать не знаю и ведать не ведаю. | Белмәдем дә күрмәдем дә. |
| 865. Знать птицу по перьям, а человека — по речам. | к. 2613. |
| 866. Знают и в Казани, что люди сказали. | к. 2282. |
| 867. Зоб полон, а глаза голодны. | к. 120, 264. |
| 868. Золотом осыпать. | Алтынга ману (күмү). |
| 869. Золотые горы сулить. | к. 2507. |
| 870. Золотые руки. | Куллары алтын. |
| 871. Зондировать почву. | Кылын тартып карау.<br>Җәясен тарту. |

872. Зуб на зуб не попадает. — Теше тешкә тими (калтырана).

873. Зубы точить. — Теш кайрау.

874. Зуд в языке. — Теле кычыта.

## И

875. И в аду обживёшься. — Тамуг газабына да кунәләр ди.

876. И в помине нет (не было). — Истә дә юк (юк иде).
Искә дә кермәде.

877. И в уме нет (не было). — Уемда да юк (иде).
Башыма да килмәде.

878. И в ус себе не дует. — Мыегын да селкетми (исе дә китми мәгънәсендә).

879. И ворон говорит: „беленький мой", и ёж говорит: „мягонький мой". — Карга да үз баласын аппагым дип сөяр, керпе дә үзенең баласын йомшагым дип сөяр.
Аю да үз баласын аппагым дип, керпе дә йомшагым дип сөя ди (к. 389, 390).

880. И глазом не успеешь моргнуть. — Күз ачып йомганчы.

881. И дело с концом. — Шуның белән эш тә бетте.
Шуның белән вәссәлам.

882. И дрова без поджогу (без подтопки) не горят. — Кабызмасаң, утын да (шырпы да) янмый.

883. И думать не стоит. — Уйлап та торасы юк.

884. И дурак кашу съест, было бы масло. — к. 183.

885. И дым отечества сладок. — Илнең төтене дә тәмле.
Туган илнең әреме дә тәмле.

886. И медведя плясать учат. — Аюны да биергә өйрәтәләр.
Кеше түгел, аю да кулга ияләшә (биергә өйрәнә).

887. И мы не на руку лапоть надеваем. — Без дә төшеп калганнардан түгел.
Безнең дә башка тай типмәгән.

888. И на дереве лист на лист не приходится. — к. 196.

889. И на доброго коня бывает спотычка. — к. 1099.

890. И на ёлку бы лез, и ног бы (одежи бы) не ободрал. — Суга да төшсен, коры да чыксын.

891. И на Машку бывает промашка. — Андый гына гаеп мулла кызында да була (к. 894, 895, 1099).

892. И на молодца оплох живёт. — к. 891, 894, 895, 1099.

893. И на руке пальцы не равны. — Бармак та тигез түгел.

894. И на старуху бывает проруха. — Сөртенмәс тояк юк (к. 891, 895, 1099).

895. И на солнце бывают пятна. — Кояшта да таплар була (к. 891, 894, 1099).

896. И нашим и вашим. — к. 897.

897. И нашим и вашим всегда спляшем. — Ике яклы пычак (яки пәке).
Ике койрыклы (булу).
Сина да ярый, мина да ярый.

898. И не красива, да счастлива. — Буен булмасын, бәхетен булсын.

899. И от доброго отца родится бешеная овца. — Аттан ала да туа, кола да туа.
Атага тартып ул тумас, анага тартып кыз тумас.

900. И пальцем не тронет. — Бармак белән дә чиертмәс.

901. И с камня лыко дерёт. — Таштан юкә суя (саран мәгънәсендә).

902. И сам вперёд не стану, и другу и недругу закажу. — (Моннан соң) үземә генә түгел, нәселемә дә кушмам.
Дуска түгел, дошманыма да теләмәм.

903. И сила уму уступает. — Беләге юан берне егар, белеме булган меңне егар.

904. И след простыл. — Эзе дә калмаган (китеп югалган).
Җилләр искән.

905. И смех и горе. — Көлсәң дә вай, көлмәсәң дә вай.

| | |
|---|---|
| | Көл дә ела.<br>Теләсәң ела, теләсәң көл. |
| 906. И собака помнит, кто её кормит. | Эт тә белә яхшылыкның кадерен. |
| 907. И ухом не ведёт. | Колагына да элми.<br>Колагын (мыегын) да селкетми.<br>Колак артыннан гына җибәрә. |
| 908. Иван кивает на Петра, Петр на Ивана. | Гали — Вәлигә, Вәли Галигә (җибәрә).<br>Эт — эткә, эт койрыкка (җибәрә). |
| 909. Иголке негде упасть. | Инә төшәр(гә) урын юк.<br>Инә төртерлек тә урын юк.<br>Инә чәнчерлек тә урын калмаган. |
| 910. Игра в прятки. | Качыш уйнау. |
| 911. Игра не доведёт до добра. | Уеннан уймак чыга. |
| 912. Игра не стоит свеч. | Биш тиенлек куян, ун тиенлек зыян.<br>Маташып торасы да юк. |
| 913. Играть, как кошка с мышкой. | Тычкан белән уйнаган мәче төсле (уйнау). |
| 914. Идёт как по маслу. | Майлагандай бара. |
| 915. Иди, куда глаза глядят. | к. 1356. |
| 916. Идти в огонь, в воду (готов). | Утка-суга керергә (хәзер тора). |
| 917. Идти, куда ветер дует. | Җил искән якка авышу. |
| 918. Идти на попятный. | Кире кайту.<br>Кире чигенү. |
| 919. Идти по стопам. | Эзеннән бару.<br>Эзенә басып бару. |
| 920. Идти против течения. | Агымга каршы бару. |
| 921. Из блохи голенище кроит. | Учыннан тамганны (акканны) ялый. |
| 922. Из воды сухим вылезает. | Суга төшсә, судан да коры чыга торган кеше |

| | |
|---|---|
| 923. Из глубины души. | Чын күңелдән. |
| 924. Из грязи, да в князи. | к. 278. |
| 925. Из избы сору не выноси, а под лавку копи. | Өендәген тышка чыгарма.<br>Өендәге чүпне тышка чыгарма.<br>Өйрәне өйдә суыт. |
| 926. Из искры возгорится пламя. | Очкыннан ялкын кабыныр.<br>Очкыннан ут чыгар. |
| 927. Из кожи лезть. | Тиресеннән чыкканчы тырышу.<br>Камыттан чыгу. |
| 928. Из крошек — кучка, из капли — море. | Күп тамчыдан күл була (к. 1055.) |
| 929. Из мухи слона делать, из блохи — верблюда. | к. 591. |
| 930. Из огня да в полымя. | Уттан ялкынга (төшү) (к. 1787). |
| 931. Из одной печи, да не одни калачи. | к. 196. |
| 932. Из одной чаши кашу ели. | Бер табактан (кашыктан) ашаган кешеләр. |
| 933. Из пальца высосать. | Һавадан алып сөйләү. |
| 934. Из пелёнок ещё не вышел. | Ана куенынинан чыгып җитмәгән<br>Күкәй кабыгыннан чыкмаган (к. 1325). |
| 935. Из песку верёвки вьёт. | к. 901. |
| 936. Из-под земли достану (найду). | Җиде кат җир астына керсә дә табармын. |
| 937. Из приличия. | Әдәп йөзеннән. |
| 938. Из рук валится. | Кулым йокмый.<br>Кулым эшкә бармый.<br>Кулым эшкә ятмый (күтәрелми). |
| 939. Из рук вон плохо. | Кулга алырлык түгел (шулкадәр начар).<br>Телгә алмаслык начар. |
| 940. Из семи печей хлебы едал. | Дөньяның әчесен-төчесен татыган. |

| | |
|---|---|
| | Тормыш казанында кайнап чыккан. |
| 941. Из спасибо шубы не сошьёшь. | Рәхмәттән тун текмиләр. |
| 942. Излить душу (чувства). | Эчне бушату. |
| 943. Иметь в виду. | Истә тоту.<br>Күздә тоту.<br>Күз алдында тоту. |
| 944. Иметь зуб. | Ачу саклау (тоту).<br>Үч саклау.<br>Үче булу. |
| 945. Иметь сердце. | Үпкә тоту. |
| 946. Иной пляшет, иной плачет. | Кемдә бәйрәм, кемдә туй; кемдә хәсрәт, кемдә уй. |
| 947. Искать ветра в поле. | Җил куу. |
| 948. Искреннее раскаяние — половина исправления. | Гаебеңне тану—ярты төзәлү. |
| 949. Искру туши до пожара, напасть отводи до удара. | ≌ Агай, алдан сагай. |
| 950. Искры посыпались из глаз. | Күзлән утлар күренде.<br>Күз алдында йолдызлар уйнады. |
| 951. Испортить всю музыку (всю обедню). | Бөтен эшне бозу (чуалту).<br>Бөтен эшне болгатып ташлау. |
| 952. Испустить дух. | Җан бирү (үлү мәгънәсендә).<br>Дөнья кую. |
| 953. Исходя из (*чьих*) интересов. | (Берәр кешенең) интересыннан чыгып.<br>(Берәр кешене) күз алдында тотып. |
| 954. Идти нога за ногу. | Аякларны сөйрәп бару.<br>Аякларны көчкә атлау. |
| 955. Их водой не разольёшь. | Araларыннан җил дә (су да) үтми.<br>Araларына кыл да сыймый.<br>Araларын су белән дә, ут белән дә аерып булмас. |

956. Ищи ветра в поле!

Аннан соң эзлә инде син аны!

(Аның) койрыгын тотарсың!

957. Ищущий друга без изъяна останется без друга.

Гаепсез аш эзләмә — ач калырсың, гаепсез дус эзләмә — ялгыз калырсың.

Гаепсез дус эзләгән ялгыз калыр.

## К

958. К (великому, крайнему) сожалению.

Кызганычка каршы.

(Зур) үкенечкә каршы.

959. К готовому костру легко щепу подбросить.

≅ Әзергә бәзер булу жиңел ул.

Әзергә хәзер булу жиңел ул.

960. К месту положи, у места и возьмёшь.

Урынына куйсаң, урыныннан алырсың да (табарсың да).

961. К позорному столбу поставить.

Хурлык тактасына бастыру.

Хурлык пичәтен басу.

962. К слову сказать.

Сүз жае (туры) килгәндә.

Сүз уңаенда (к. 214).

963. К чёрту на кулички.

Жәһәннәм астына.

964. К шапочному разбору.

Туйдан соң дөмбергә.

Туйдан соң тукмакка.

Эш узгач, туй узгач.

965. Кабы знать, где упасть, так соломки бы подослал.

Кеше егыласын белсә, алдан салам түшәр иде.

Үләсен белсә, алдан кабер казып куяр иде.

966. Кабы на горох не мороз, он бы через тын перерос.

Хәленнән (кулыннан) килсә, кешенең башыннан йөрер иде.

967. Кабы на крапиву не мороз, с нею бы и ладов не было.

к. 966.

968. Кабы на хмель не мороз, так бы через дуб перерос.
к. 966.

969. Кадка (бочка) мёду, ложка дёгтю: все испортит.
Бер кашык дегет бер мичкә балны боза.

970. Каждая копейка алтынным гвоздиком пробита.
Тир түгеп табылган акча (яки мал).

971. Каждый божий день.
Алланың һәр бирмеш көне.

972. Как аукнется, так и откликнется.
Урманда ни аваз кычкырсаң, шул ишетелер.
Авызың ни әйтсә, колагың шуны ишетер (к. 1030).

973. Как бельмо на глазу.
Күзгә кергән чүп кебек.

974. Как блин по маслу.
к. 1006.

975. Как блины печёт.
Кулы кулга йокмый (тиз эшли мәгънәсендә).

976. Как-будто по голове ударили палкой.
к. 985, 1005.

977. Как бы не так!
Шулай булмыйча соң!
Шулай булмый ни!

978. Как в воду канул.
Суга төшкәндәй булды.
Суга сеңгәндәй булды.

979. Как в воду опущенный.
Балтасы суга төшкән кеше кебек (күңелсез мәгънәсендә).
Суга төшкән тавык кебек.
Әвене янганмыни.

980. Как верёвочка ни вьётся, а кончику быть.
Жеп очсыз булмый, бер очы була аның.
Чуалган жепнең дә бер очы табыла.

981. Как во сне.
Төштә күргәндәй.
Кичтә күргән төш кебек.
Төштәге кебек.

982. Как волка ни корми, а он всё в лес смотрит (глядит).
Бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый (тәгәрәп төшә).
Бүрене күпме ашатма, һаман урманга таба бага.
Бүре баласын салсаң та-

ТІЛ БІЛІМІ
ИНСТИТУТЫ

бакка, тәгәрәп төшәр тагаракка.
Бүрене нихәтле кадерләсәң дә урманга карый.

983. Как воск (мягкий). — Балавыз кебек эреп аккан (йомшак, булдыксыз мәгънәсендә).

984. Как вылито на нём. — Өстенә коеп куйган кебек (кием турында).
Үзенә үлчәп теккәнмени.

985. Как гром среди ясного — Аяз көнне яшен суккандай (булу).

986. Как грибы после дождя. — Су сибеп үстергәндәй.

987. Как две капли воды (похожи). — Ике тамчы су кебек (охшашлар) (к. 412).

988. Как его, грешника, мать-сыра земля носит?! — Ничек аны җир йотмый (күтәрә)?!

989. Как жук в навозе копается. — Тирес корты кебек кайнаша.

990. Как замешал, так и выхлебаешь. — к. 2758.

991. Как избитый. — Кыйналып ташлангандай.

992. Как ключ ко дну. — к. 1019.

993. Как курица с яйцом носится. — Йомыркасы бар тавык кебек йөри (әйләнә).

994. Как липу ободрать. — Шыр ялангач калдыру.
Кара җәяү(гә) калдыру.

995. Как молодой месяц, покажется, да спрячется. — Ай күрде, кояш алды.
Ай күрде, көн йотты.

996. Как муха к мёду льнёт. — Балга каныккан чебен кебек ябыша.

997. Как на корове седло. — Сыерга ияр килешмәс.
Сыерга ыңгырчак кидергән кебек.

998. Как на ладони. — Уч төбендәге кебек.

999. Как нам жениться, так и ночь коротка. — Без өйләнгәч, төн кыска.

1000. Как небо от земли (отличается). — Җир белән күк аермасы (бар).

1001. Как ни в чём не бывало. — Берни дә булмагандай.

ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

1002. Как ни крой, а швы наружу выйдут. — Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә.

1003. Как ни тяни, а чужого веку не заешь. — ≃Кеше гомеренә кеше керми.

1004. Как об стенку горох. — Стенага борчак сипкәндәй.
Колагына да элми (к. 907)

1005. Как обухом по голове. — Башка таяк белән суккандай булды (кинәт ишетелгән хәбәр, сүз турында).

1006. Как по маслу идёт. — Майлаган кебек бара.

1007. Как постелешь, так и поспишь. — к. 1027.

1008. Как рак на мели. — Көймәсе комга терәлгән.

1009. Как рыба в воде. — Суга җибәргән балык кебек (сизә, иркен тота үзен).

1010. Как с гуся вода. — Исе дә китми (к. 907, 1001).

1011. Как с неба свалился. — Күктән төшкәнмени.

1012. Как с цепи сорвался. — Бәйдән ычкынган эт кебек (усал кешегә карата әйтелә).

1013. Как сельди в бочке. — к. 909.

1014. Как сквозь землю провалился. — Җир тишегенә кергәнмени.

1015. Как снег на голову. — Уйламаганда-көтмәгәндә.
Көтмәгән җирдән.

1016. Как собак нерезанных. — Эт тезеннән.
Эт көтүе чаклы.

1017. Как собака на сене: и сама не ест, и другим не даёт. — Печән өстендәге эт кебек: үзе дә ашамый, кешегә дә бирми.
Үзе дә җимәс (ашамас), кешегә дә бирмәс.

1018. Как сыр в масле катается. — Бал-май эчендә тора.
Пычагы майда йөзә.
Сары май эчендәге балавыз кебек.
Бер кулы майда, берсе — балда.

1019. Как топор ко дну. — Суга төшкән балта кебек (төпкә китү).

1020. Как хлеба край, так и под елью рай; как хлеба ни куска, так и в тереме тоска.

♎ Бар сөйдерә, юк көйдерә.
Байлык яраштыра, ярлылык талаштыра.

1021. Каким ветром занесло?!

Нинди җилләр ташлады?!

1022. Какими судьбами?!

Нинди язмыш ташлады?!

1023. Каков батька, таковы и детки.

Атасы нинди, баласы шундый.
Аргамактан ат туа, кандаладан бет туа (к. 1036).

1024. Каков голосок, таков и отголосок.

к. 972, 1030.

1025. Каков гость, таково ему и угощение.

Ашына күрә катыгы, кешесенә күрә кашыгы.

1026. Каков грех, такова и расправа.

Гаебенә күрә җәзасы.

1027. Каков дядя до людей, таково ему и от людей.

Үзең аш куйсаң, аш куярлар, таш куйсаң, таш куярлар (к. 1047).

1028. Каков корень, таков и отпрыск.

к. 1023, 1040.

1029. Каков поп, таков и приход.

Көтүче нинди, көтүе шундый.

1030. Каков привет, таков и ответ.

Соравына күрә җавабы.
Сүзенә күрә җавабы, сәдакасына күрә сәвабы (к. 972).

1031. Каков род, таков и приплод.

к. 1023.

1032. Каков ты до меня, таков и я до тебя.

Үзең ничек, мин шулай.

1033. Каков у хлеба, таков и у дела.

Ашы тизнең эше тиз.

1034. Какова деревня, такова и обрядня (обедня).

Авылына күрә кавымы.
Авылы башканың рәте (кавымы) башка.
Төрле авылда төрле әттәхият.

1035. Какова еда, такова и хода.

Ашы барның эше бар (яхшы ашаган кешенең эшләргә көче дә була дигән мәгънәдә).

| | |
|---|---|
| 1036. Какова мать, такова и дочь. | Анасының кызы (к. 1023). |
| 1037. Какова от пса ловля, такова ему и кормля. | Эшенә күрә ашы. |
| 1038. Какова работа, такова и плата. | к. 1037. |
| 1039. Каково в лесу кликнется, таково и откликнется. | к. 972. |
| 1040. Каково дерево, таков и плод. | Агачына күрә җимеше (алмасы) (к. 1023, 1808). |
| 1041. Каково кликнется, таково и аукнется. | к. 972. |
| 1042. Каково лукошко, такова ему и покрышка. | Чиләгенә күрә капкачы. |
| 1043. Каково семя, таково и племя. | к. 1023, 1036, 1040, 1808. |
| 1044. Каковы девки, таковы и припевки. | Аның кемлеге кыланышыннан күренә. |
| 1045. Каковы сани, таковы и сами. | Җиренә күрә җикәне. Җиренә күрә җимеше. |
| 1046. Какой ни на есть. | Нинди генә булмасын. |
| 1047. Какую другу чашу налил, такую и сам выпьешь. | Үзең ипи киссәң, ипи кисәрләр; калач киссәң, калач кисәрләр (к. 1027). |
| 1048. Калиф на час. | Бер сәгатьлек хәлифә. |
| 1049. Каменное сердце. | Таш йөрәкле. |
| 1050. Камень за пазухой держать (прятать). | Куенында таш саклау (ачу саклау мәгънәсендә). |
| 1050а. Камень и тот бы растаял. | Таш та эрер иде. |
| 1051. Камень от сердца отвалился. | Йөрәктәге авыр таш төшкәндәй булды. |
| 1052. Камень с плеч (свалился). | к. 507. |
| 1053. Камня на камне не оставить. | Тетмәсен тетү. |
| 1054. Капля в море. | Дингездән бер тамчы. |
| 1055. Капля за каплей — образуется озеро. | Тамчы тамса (тама-тама) күл була. |

| | |
|---|---|
| 1056. Капля по капле — камень долбит. | Тамчы тама-тама таш тишә. |
| 1057. Каркать как ворона. | Ала каргадай алдан-алы кычкыру. |
| 1058. Картофель хлебу подспорье. | Бәрәңге — ярты икмәк. |
| 1059. Картошка хлебу присошка. | к. 1058. |
| 1060. Катись колбасой! | Табаныңны ялтырат!<br>Үкчәңне күтәр! |
| 1061. Катучий камень мохнат не будет. | Йөргән таш шомара (к. 1929). |
| 1062. Каши не сваришь (*с кем.*) | (Аның белән) эшең пешмәс.<br>(Аның белән) борчагың пешмәс. |
| 1063. Кашу маслом не испортишь. | Майдан ботка бозылмас. |
| 1064. Кашу свари, да ещё и в рот положи. | к. 558, 727, 729. |
| 1065. Кишмя кишеть. | Мыж килеп тору. |
| 1066. Класть (положить) зубы на полку. | Авызны чөйгә элү.<br>Нәфел уразасы тоту. |
| 1067. Клёпки не достаёт. | к. 293. |
| 1068. Коверкать язык. | Тел бозу. |
| 1069. Ковыряя в зубах, не насытишься. | к. 734. |
| 1070. Когда есть, так густо, а коли нет, так пусто. | Булганда бүредәй, булмаганда шүредәй.<br>Бар чакта бүредәй, юк чакта шүредәй.<br>Булса бохарый, булмаса сохари. |
| 1071. Когда месяц светит, так и звёзд не нужно. | Аем туры бакканда йолдызларга йодрык. |
| 1072. Когда на горе рак свистнет. | Кызыл кар яугач.<br>Карт алаша тай булганда. |
| 1073. Когда на охоту ехать, тогда и собак кормить. | Этне ауга чыкканда гына ашату (эшне вакыты килеп терәлгәч кенә эшләү мәгънәсендә). |

Кодалар килде кабакка,
кыз утырды кабага.

1074. Когда на сосне груши будут.

к. 1072.

1075. Когда нет состязания в стрельбе — все стрелки, когда нет борьбы — все силачи.

Сугыш беткәч бар да батыр.

1076. Когда песок в камень (по камню) взойдёт.

к. 1072.

1077. Когда потчуют, и воду пей.

Сыйлаганда су эч.
Сыйлап биргәннең суын эч.

1078. Когда солнце взойдёт от заката.

Кояш кире яктан чыкканда (к. 1072).

1079. Когда солнце задом оборотится.

к. 1072, 1078.

1080. Кого медведь драл, тот и пня боится.

Елан чаккан баудан (киндерәдән) курыккан (к. 2605).

1081. Кожа да кости.

Тире дә сөяк кенә (бик ябык мәгънәсендә).
Күн дә сөяк.

1082. Коза сыта и капуста цела.

к. 2766.

1083. Козёл по горам и баран по горам.

Кәҗә койрык күтәрә дип, сарык та койрык күтәргән.
Күрше күрә кылана.
Эт чаба дип бет чаба.

1084. Кол ему в глотку.

Бугазына пычак кергере (кадалгыры).

1085. Коли дают, так бери; коли бьют, так беги.

к. 571, 572.

1086. Колосс на глиняных ножках.

Тышы мамык, эче кабык.
Тыштан ал да гөл, эчендәген үзең бел.

1087. Колотись, бейся, а всё надейся!

(Никадәр авыр булса да), өметенне өзмә!

1088. Колоть (в) глаза.

Күзенә (йөзенә) бәреп әйтү.
Йөзне ерту.
Йөзне ертып әйтү.

1089. Комар комара нарождает, а человек человека.

к. 1808.

1090. Комар носа не подточит.

Тел тидермәслек.
Менә дигән.
Гаеп табарлык түгел.
Аюга шырпы кадалган.

1091. Комар парню ногу отдавил.

1092. Кому детей родить, тому бы их и возрастить.

Баланы кем тапкан, шул баксын (үстерсен).

1093. Кому на ком жениться, тот в того и родится.

Каениш туфрагыннан алына.
Килен (яки кияү) — каениш туфрагы.

1094. Кому поживётся, у того и петух несётся.

Анын әтәче дә йомырка сала.
Анын үгезе дә бозаулаган вакыт.
Анын бүресе улый.
Анын мәчесе дә куян тота.
Бәндәнен бәхете алга киткәндә кулына туфрак алса, алтын була ди.
Бәхетленең әтәче дә күкәй сала ди.

1095. Кому что думается, тот того и боится.

Күңелгә килгән алга килә диләр.

1096. Конца-краю нет.

Иге-чиге юк.

1097. Концы в воду (хоронить).

Эзен яшерү.

1098. Кончил дело—гуляй смело.

Эш беткәч уйнарга ярый.

1099. Конь о четырёх ногах — и тот спотыкается.

Дүрт аяклы ат та абына (сөртенә) (к. 891, 894, 895).

1100. Конь познаётся при горе, а друг при беде.

к. 684.

1101. Коня в рати узнаёшь, друга в беде.

Ат чабышта, дус яуда беленер (к. 684, 1100).

1102. Коня куют, а жаба ногу подставляет.

Ат аягын дагалаганда бака ботын кыстыра.

Ат аягын сузган жиргә
бака ботын кыстыра.
к. 51.

1103. Копейка рубль бережёт. — Файдасыз түмгәк булып яшәү.

1104. Коптить небо. — Ишкәксез көймә.

1105. Корабль без руля. — ≅ Уку — инә белән кое казу.

1106. Корень ученья горек, а плоды сладки. — Сыерның сөте телендә.

1107. Корова доится пастью. — Сыерның сөте җиленендә түгел — тагарагында.

1108. Корова доится пастью, курица несётся клювом. — к. 1107.

1109. Корова на дворе — харч на столе. — Сыеры барның сые бар.
Сыерлы кеше — сыйлы кеше.

1110. Коротко (короче) говоря. — Озын сүзнең кыскасы.

1111. Короче воробьиного носа. — Бармак башы кадәр генә.
Инә очы кадәр генә.

1112. Косо смотреть (глядеть). — Кырын карау (яратмау мәгънәсендә).

1113. Которая корова пала, та по три удоя давала. — Үлгән сыер сөтле була.
Үлгән сыер сөтле була,
калган сыер бетле була.
Үлгән сыер сөтле була,
киткән килен уңган була.

1114. Который палец ни укуси — все больно. — Бармакның кайсын тешләсәң дә авырта (ата-анага балалар бертигез якын була мәгънәсендә).

1115. Кошке — игрушки, а мышке — слёзки. — Тычканга үлем, мәчегә көлке.

1116. Кошке смех, мышке слёзы. — к. 1115.

| | |
|---|---|
| 1117. Кошки грызутся — мышам приволье (раздолье). | Ике карга сугышса, ябалакка йон. |
| 1118. Кошки скребут. | Йөрәкне тырнап тора (борчу, кайгы турында). |
| 1119. Кошку бьют, а невестке наветки дают. | к. 245. |
| 1120. Краденое добро в прок не идёт. | Урлаган малда бәрәкәт юк. |
| 1121. Краем уха (слышал). | Колак читем белән генә (ишеттем). |
| 1122. Краеугольный камень. | Нигез ташы. |
| 1123. Краса приглядится, а ум вперёд годится. | Матурлык туйда кирәк, акыл көн дә кирәк. |
| 1124. Краснеть до корней волос. | Чәч төпләренә хәтле кызару (бик нык оялу мәгънәсендә). Комач кебек кызару. |
| 1125. Красной нитью проходит. | Кызыл җеп булып сузыла. |
| 1126. Красный, как кумач (как пион). | Комач кебек кызыл. |
| 1127. Красный товар. | Кызыл мал. |
| 1128. Красота до венца, а ум — до конца. | к. 1123. |
| 1129. Красота нужна на свадьбе, а любовь — повседневно. | Матурлык туйда кирәк, мәхәббәт көн дә кирәк. |
| 1130. Крепок задним умом. | Аңа салма ашагач акыл төшә. Аңа тау менгәч акыл керә. |
| 1131. Крепок на ухо. | Колакка каты. Колакка сак (саграк). |
| 1132. Кривить душой. | Җанын сату (ялганлау мәгънәсендә). Сырт сукмагы белән маташу. |
| 1133. Кривое веретено не исправишь. | Анадан кыйшык туган тезгә салсаң да тураймас. Кәкре үсеп картайган агачны төз итеп булмый (к. 508). |

| | |
|---|---|
| 1134. Кровавые слёзы лить (проливать). | Канлы күз яшьләре түгү. Кан елау. Кан-яшь түгү. |
| 1135. Кровь бьёт в голову. | Башка кан йөгерә. |
| 1136. Кровные деньги. | Хәләл акча. Хәләл көч түгеп тапкан акча. |
| 1137. Кровь бушует. | Кан кайный (ачу килә мәгънәсендә). |
| 1138. Кровь за кровь. | Канга кан (үч алу мәгънәсендә). |
| 1139. Кровь проливать. | Кан коя. Кан түгү. |
| 1140. Кровь с молоком. | Чиртсәң кан чыгар (симез, таза мәгънәсендә). |
| 1141. Кронштадт виден. | к. 2531. |
| 1142. Круглый год. | Ел әйләнәсе. |
| 1143. Круглый дурак. | Шыр тиле. Шыр чыккан тиле. |
| 1144. Крылья выросли. | Канатланып китте. Күңеле үсеп китте. Рухы (күңеле) күтәрелеп китте. |
| 1145. Крышей покрыто, да потолка нет. | Бер тактасы җитми. Үлчәве таманрак. |
| 1146. Кстати сказать. | к. 214, 962. |
| 1147. Кто в деле, тот и в ответе. | Таяк эшләгән башка төшә. |
| 1148. Кто в парче, кто в камке, а мы в холсту на том же мосту. | Асыл ефәк кисә дә без йөргән юлдан йөри әле. |
| 1149. Кто взял, на том один грех; у кого пропало, на том— сто. | Алган бер языклы, алдырган мең языклы. |
| 1150. Кто грамоте горазд, тому не пропасть. | Укыган кеше хур булмый. |
| 1151. Кто едет скоро, тому в дороге нет споро. | ≌ Аптырамый ашык, юлың булыр ташлык. |

| | |
|---|---|
| 1152. Кто ест скоро, тот и работает споро. | к. 1033. |
| 1153. Кто избирает, тот век измеряет. | Сайлаган сазга, очраган тазга. |
| 1154. Кто именинник, тому и пирога нет. | Бакча иясенә түтәл юк (к. 2231). |
| 1155. Кто как хочет, тот так и хохочет. | Ихтыярың — бәрәнге.<br>Ихтыярың — үз кыярың. |
| 1156. Кто кому милёнок и не умыт — белёнок. | к. 1563. |
| 1157. Кто мало говорит, тот больше делает. | Аз сөйләгән күп эшләр. |
| 1158. Кто много спит, у того нет ума; кто много говорит, у того нет правды. | Күп йоклаган бөләр, күп сөйләгән алдар.<br>Күп йөргән азар, күп сөйләгән язар. |
| 1159. Кто на кого похож, тот с тем и схож. | Иш ишен табар, җил тишеген табар (к. 2266.) |
| 1160. Кто не пашет, у того и огрехов нет. | Эшләмәгән кеше генә ялгышмый. |
| 1161. Кто не работает, тот не ест. | Кем эшләми, шул ашамый.<br>Эшләмәгән ашамый. |
| 1162. Кто не рискнёт, тот не выиграет. | Тәвәккәл таш ярыр. |
| 1163. Кто не стучится, тому не открывают. | к. 629. |
| 1164. Кто новины не видал, и ветоши рад. | Ит күрмәгәнгә үпкә тансык. |
| 1165. Кто нужды не видел, тот и счастья не знает. | к. 1557, 1709. |
| 1166. Кто от кого, тот и в того. | к. 1023, 1036, 1040, 1808. |
| 1167. Кто поздно пришёл, тому и мосол. | Соңга калганга сумала. |
| 1168. Кто посеет ветер, тот пожнёт бурю. | Җил чәчсәң, давыл урырсың. |
| 1169. Кто прямо ездит, дома не ночует. | ≅ Әйләнеч булса да юл яхшы. |

ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

1170. Кто роет другому яму, сам в неё попадёт.
Кешегә баз (чокыр) казысаң, үзең төшәрсең.

1171. Кто с мечом войдёт, от меча и умрёт.
Кылыч белән кергән кылычтан үләр.

1172. Кто сам себя хвалит, в том пути никогда не бывает.
Үзен үзе мактаган кешедә мәгънә юк.

1173. Кто смел, тот и на коня сел.
Кыюның бәхете артык.
Кыюның бәхете алдан йөрер.

1174. Кто смел, тот и съел.
Оялмаган (кыю) боермаганны ашар.

1175. Кто старое вспомянет, тому глаз вон.
Үткәнне искә төшерүченең күзе чыксын.

1176. Куда ветер подует.
к. 619.

1177. Куда грива, туда и хвост.
Эт артыннан койрык.
Эт артыннан койрык, мәче артыннан йөгерек.

1178. Куда иголка, туда и нитка.
Җеп инә артыннан йөри (иярүчәнлек турында).

1179. Куда конь с копытом, туда и рак с клешнёй.
к. 1102.

1180. Куда нам есть сметану с калачом, хлебаем и снятое с чернячком.
≅ Ярый безгә—майлы кузгә әйрән каткан сөтле умач.

1181. Куда ни шло.
Булмаса булган икән.
Ни булса, шул булыр.

1182. Куй железо, пока горячо.
Тимерне кызуында сук.

1183. Купаться в золоте.
Алтынга чуму (күмелү).

1184. Купит и внучек, а продавать—так и дед намается.
Алганда үзем генә дә алдым, сатканда эти белән дә сата алмыйм.

1185. Курам на смех.
Тавыклар көлешер.
Әдәм көлкесе (булырга).

1186. Курицу яйца не учат.
Йомырка тавыкны өйрәтми.

1187. Курицы не обидит.
к. 1342.

1188. Куры не выклюют.
Тавык чүпләп бетермәслек (бик күп мәгънәсендә).

# Л

| | |
|---|---|
| 1189. Ладят, как кошка с собакой. | к. 755. |
| 1190. Лапти плести. | Белер-белмәс сөйләү. |
| 1191. Ласковое слово. | Ягымлы сүз. |
| 1192. Ласковое слово и кость ломит. | Яхшы сүзгә җан эри.<br>Яхшы сүз — җан азыгы, яман сүз — баш казыгы. |
| 1193. Ласковое слово пуще дубины. | к. 1192. |
| 1193а. Ласковый телёнок двух маток сосёт. | Татлы тел тау биләр. |
| 1194. Лаять из подворотни. | Капка астыннан өрү (өреп калу). |
| 1195. Лбом стены не пробьёшь (прошибёшь). | Борының белән боз тишә алмассың.<br>Башны ташка бәрер (орыр) хәл юк.<br>Артың белән киртә җимерә алмассың. |
| 1196. Лебединая песня. | Соңгы җыр (сүз, эш). |
| 1197. Левой ногой с постели ступил. | Сул аягы (ягы) белән торган (кәефе юк мәгънәсендә). |
| 1198. Легко добыто — легко и прожито. | Җилдән килгән җилгә китәр. |
| 1199. Лёгок на помине. | Гомере озын булыр (сөйләп торганда килеп керде). |
| 1200. Лёжа и камень мохом обрастает. | Яткан таш мүкләнә (к. 1929). |
| 1201. Лежать на боку. | Бот күтәреп яту.<br>Түшәмгә төкереп яту. |

| | |
|---|---|
| 1202. Лежать на печи. | Мич башында яту.<br>Мич башында таракан санап яту. |
| 1203. Лежачего не бьют. | Егылганны түбәләмиләр. |
| 1204. Лежит на душе. | Күңелдә төен булып тора.<br>Эчне пошырып тора. |
| 1205. Лезть в глаза. | Күзгә керү. Авызга керү. |
| 1206. Лезть в душу. | Эчеңә-бавырыңа керү. |
| 1207. Лезть в чужой огород. | Кеше эшенә тыгылу. |
| 1208. Ленивому всегда праздник. | к. 1209. |
| 1209. Ленивому и в будни праздник. | Ялкауга көн дә бәйрәм.<br>Ялкауга көн дә бәйрәм көн дә ял. |
| 1210. Леность наводит на бедность. | Ярлылыкның башы — ялкаулык.<br>Ялкаулык— ярлылыкның ачкычы. |
| 1211. Лес видит, а поле слышит. | Урман—колак, кыр — күз. |
| 1212. Лес рубят — щепки летят. | Балта чапканда йомычка чәчрәми булмый. |
| 1213. Лесом шел, а дров не видал. | Күңел күзе булмаса, маңгай күзе — ботак тишеге. |
| 1214. Летала пташка высоко, а села недалёко. | Югары очып, түбән төште. |
| 1215. Лечь в могилу. | Кабергә керү. Гүргә керү. |
| 1216. Лечь камнем на сердце (на душу). | Йөрәккә таш булып утыру. |
| 1217. Лечь тяжёлым бременем. | Авыр йөк булып төшү. |
| 1218. Лживые вести не лежат на месте. | к. 642. |
| 1219. Либо в стремя, либо в пень головой. | к. 1221. |
| 1220. Либо в сук, либо в тетерю. | Тисә — тиенгә, тимәсә — ботакка. |

1221. Либо пан, либо пропал. — Я уңам, я туңам (тәвәккәллек турында).
Я үләсең, я каласың.

1222. Либо полковник, либо покойник. — к. 1221.

1223. Либо полон двор, либо корень вон. — к. 1221.

1224. Либо рыбу съесть, лио на мель сесть. — к. 1221.

1225. Либо сена клок, либо вилы в бок. — к. 1221.

1226. Либо чужую шкуру добыть, либо свою отдать. — к. 1221.

1227. Листом стелется, да укусить целится. — Саплы ягын биреп сабы белән төртә.

1228. Лить воду на (*чьюнибудь*) мельницу. — Тегермәненә су кою (берәр кешенең файдасына эш итү мәгънәсендә).

1229. Лить горькие слёзы. — Ачы күз яшьләре түгү (к. 520).

1230. Лить горючие слёзы. — Кайнар күз яшьләре түгү (к. 521).
Кан елау.

1231. Лить масло в огонь. — Ут өстенә май сибү.
Утка керосин сибү.

1232. Лить пули. — Борчак ату (алдау, ялганлау мәгънәсендә).

1233. Лиха беда начало! — (Һәр эшне) башлап җибәрү генә кыен!

1234. Лихо долго помнится, а хорошее скоро забудется. — к. 645.

1235. Лица нет (*на ком-нибудь*). — Чырае качкан (киткән).
Чырайдан төшкән.

1236. Лицом в грязь не ударить. — Йөзгә кызыллык китермәү.
Йөзне кызартмау.

1237. Лицом к лицу (встретиться). — Йөзгә-йөз (очрашу).
Кара-каршы (килү).

1238. Лицом повернуться (*к чему*). — Игътибарны юнәлдерү (берәр нәрсәгә).

| | |
|---|---|
| 1239. Лишние брёвна в стене (в избе) есть. | Башы тишек кешеләр бар. Артык кешеләр бар. |
| 1240. Ложкой кормит, стеблем глаза колет. | к. 1227. |
| 1241. Ломаного гроша не стоит. | Сукыр бер тиенгә тормый. |
| 1242. Ломаным языком говорить. | Ватып-сындырып сөйләү. |
| 1243. Ломать голову. | Баш вату. |
| 1244. Ломать комедию. | Икейөзлеләнү. |
| 1245. Ломи дерево, пока молодо. | к. 477. |
| 1246. Ломиться в открытую дверь. | Ачык ишекне җимереп (бәреп) керү. |
| 1247. Лопни глаза (мои). | Күзем чәчрәп чыксын (каргану сүзе). |
| 1248. Лошадь — человеку крылья. | Ир канаты — ат. |
| 1249. Лучше быть вдовой героя, чем женой труса. | Куркакның колы булганчы, батырның толы бул. |
| 1250. Лучше горькая правда, чем сладкая ложь. | Ачы булса да хакыйкать яхшы. |
| 1251. Лучше воду пить в радости, чем мёд в кручине. | Җаның тыныч, ярты икмәгең булсын. Ач тамагым — тыныч колагым. |
| 1252. Лучше быть в деревне первым, чем в городе последним. | ≅ Кеше илендә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул. |
| 1253. Лучше меньше да лучше. | Бер булсын, берәгәйле булсын. Бер булсын, бәрәкәтле булсын. |
| 1254. Лучше не досказать, чем пересказать. | ≅ Күп сүзнең азы яхшы, аз сүзнең үзе яхшы. |
| 1255. Лучше поздно, чем никогда. | Һич булганчы, кич булсын. Соң булса да, уң булсын. |
| 1256. Лучше с умным потерять, чем с дураком найти. | Тиле белән тапма да, өләшмә дә. |

1257. Лучше синица в руке, чем журавль в небе.

Булыр булмаска ышанып, кулыңа төшкәннән аерылма (к. 768).

1258. Лучше умереть стоя, чем жить на коленях.

Куркак булып яшәүдән данлы үлем яхшырак.

Тез чүгеп яшәүдән басып үлү яхшырак.

1259. Лучше хлеб с водою, чем пирог с бедою (с лихвою).

к. 1251.

1260. Лыка не вяжет.

Теле әйләнми.

Теле көрмәкләнә (бик нык исерек дигән мәгънәдә).

1261. Любишь брать, люби и отдавать.

к. 659. 2620.

1262. Любишь гостить, люби и к себе звать.

Кунак ашы кара-каршы.

Бәйрәм ашы кара-каршы.

Кешегә барып аша(саң), үзеңә кайтып кос (к. 1883).

1263. Любишь кататься, люби и саночки возить.

Рәхәтен күргәнсен, михнәтенә дә түз.

1264. Любишь смородину, люби и оскомину.

к. 1263.

1265. Люблю, кума, как я у тебя; а как ты у меня, так и смерть на меня.

≅ Кешегә барса ал да гөл, үзенә килсәң, җил-давыл.

1266. Любовь зла: полюбишь и козла.

Бәхетеңә туры килсә, таз булса да сөярсең.

Мәхәббәткә маңка тыгызламый.

1267. Людей выручишь — себя выучишь.

Кеше хәтерен сакласаң, үз хәтереӊ калыр.

Кешене кызганма, кызганыч булырсың.

1268. Людей слушай, а по-своему делай.

Кешенекен тыңла, үзеңнекен тот.

Кешене тыңла, үзеңчә эш ит.

Кешегә киңәш ит, үз белдегең белән эшлә.

1269. Лясы точить. — Сафсата сату.
Лыгыр сату.
Лэчтит сату.

# М

1270. Мал да удал. — Кечкенэ булса да төш кенэ (к. 253).

1271. Мал золотник, да дорог. — ≅ Алтын зур булмый.

1272. Мал золотник, да дорог; велик пень, да дупласт. — к. 250.

1273. Мал золотник, да золото весят; велик верблюд, да воду возят. — к. 250.

1274. Мал сокол, да на руке носят; велик верблюд, да воду возят. — к. 250.

1275. Мал соловей, да голос велик. — к. 1271.

1276. Маленькие детки — маленькие бедки, а вырастут велики — будут большие (беды). — Бала-чага тездэ чакта сөйдерэ, тездэн төшкэч көйдерэ.

1277. Маленький, да удаленький. — к. 1270.

1278. Маленькая собачонка лает — от большой слышит. — Этеннэн куреп көчеге өрер.

1279. Маленькое дело лучше большого безделья. — ≅ Тик торганчы тиген эш булыр.

1280. Мало каши ел. — Баба (Лаеш) шулпасы эчмэгэн.

1281. Малого пожалеешь, большое потеряешь. — Азны кызганып, куптэн коры калырсың.
Кызганганны кызыл эт ашар.

1282. Манной небесной питаться. — Ачлы-туклы яшэү.
Һава белэн туенып тору.

1283. Март у коров рог сшибает. — Февральдэ сыер мөгезен сындырырлык бураннар була.

1284. Март свои шутки строит. — Мартта шартлата (суык турында).

1285. Мастер на все руки. — Кулыннан килмэгэн эше юк.

Агачтан сандугач кына ясамый.
Кулыннан гөл генә таммый.
Кулы белән төймә генә төйми.

1286. Масть к масти подбирается. — Иш ишен таба (к. 1159, 2266).

1287. Матери хотелось, чтобы у сына голова была чёрненька, а он родился и весь как головенька. — Мин сорыймын ходайдан капкара чәчлене, ходай мина китереп бирә яп-ялангач башлыны (теләккә ирешмәү мәгънәсендә).

1288. Матернее (материнское) сердце в детях, а детское — в камне. — Ата-ана күңеле балада, бала күңеле далада (тауда-ташта).

1289. Махнуть рукой. — Кул селтәү (өметне өзү мәгънәсендә).
Сулагай кулны селтәү.
Кулны ташлау.

1290. Медведь в лесу, а шкура продана. — Аюны үтермәс борын тиресен сата.
Үтермәгән аюның тиресен туный.
Тумаган тайга атлана.
Тавыгы йомырка салмаган әле, чебешләрен сата инде.

1291. Медвежья услуга. — ≅ Каш ясыйм дип күз чыгару.

1292. Медный лоб. — Кибәк баш (аңгыра кеше турында).

1293. Медовый месяц. — Ширбәт ае.

1294. Между двух огней (остаться). — Ике ут арасында (калу).
Ут белән су арасында (калу).

1295. Между нами будь сказано. — Әйткән әйткәндә (әйткән җирендә) калсын.

1296. Между небом и землёй (быть). — Җир белән күк арасында (булу).

1297. Между ними пробежала чёрная кошка. — Араларыннан кара мәче үткән.
Алар арасына кара күләгә яткан.

1298. Между прочим. — к. 214, 962.

1299. Мели Емеля, твоя неделя. — Әйтәсеңне әйтеп кал.
Сөйләп кал әле.

1300. Мелким бесом рассыпаться. — Бер алдына, биш артына төшү (ялагайлану мәгънәсендә).

1301. Мелко плавать. — Сай йөзү (берәр нәрсәне тирән белмәү мәгънәсендә).

1302. Менять кукушку на ястреба. — Балта биреп шөшле алу.

1303. Меняться в лице. — Чырай үзгәрү.
Төс китү.

1304. Мера всякому делу вера. — Санаулы мал югалмас (к. 303).

1305. Мерить на свой аршин. — Үз аршыныңа үлчәү.
Үз үлчәве (аршыны) белән үлчәү.

1306. Мёртвый без гроба, живой не без кельи. — Җан биргәнгә җүн бирер.
Илдә чыпчык үлми.

1307. Метать громы и молнии. — Авыздан утлар чәчү.

1308. Метаться в уме. — Акылдан язу.

1309. Метил в ворону, попал в корову. — Кыек атып, туры тидерә (китерә).
Бәрә тәртәгә, тия чәркәгә.

1310. Метил в лукошко, а попал в окошко. — к. 1309.

1311. Метил в цель, а попал в пень. — к. 1309.

1312. Мимо нашего двора дорога столбовая. — Килгәндә китә йөр.

1313. Мир по слюнке плюнет — так море. — Ил төкерсә, күл була.
Мир төкерсә, күл була.

1314. Мир твоему праху! — Кабереңдә (гүреңдә) тыныч йокла!

1315. Мирская шея толста (крепка). — Мир җилкәсе калын бит.

| | |
|---|---|
| 1316. Мне не дорог твой подарок, дорога твоя любовь. | Ашы бәя түгел, чисы (честь) бәя.<br>Жыры бәя түгел, көе бәя.<br>Кәзәсе (кәҗәсе) бәя түгел, мәзәге бәя. |
| 1317. Мнит себя пупом (солью) земли. | Үзен-үзе дөнья тоткасы (дөнья терәге) дип уйлый.<br>Дөнья кендегемени. |
| 1318. Много будешь знать, скоро состаришься. | Күпне белсәң, тиз картаерсың (үләрсең). |
| 1319. Много воды утекло. | Бик күп сулар акты. |
| 1320. Много желать — добра не видать. | Күпне көтеп, аздан коры калырсың. |
| 1321. Много искать станешь, ничего не достанешь. | Күпне көтеп (өмет итеп), аздан коры калырсың. |
| 1322. Много хочется, да не всё сможется. | Дәрт бар, дәрман юк. |
| 1323. Молодец против овец, а на молодца — сам овца. | Сарыклар янында (арасында) бүре, бүреләр янында (арасында) сарык.<br>Сарыклар янында алып, алыплар янында сарык. |
| 1324. Молодость — глупость. | Яшьлек — юләрлек.<br>Яшь чак — юләр чак. |
| 1325. Молоко на губах не обсохло. | Авызыннан (ирененнән) ана сөте кипмәгән.<br>Йомырка сарысы китмәгән (к. 934). |
| 1326. Молчан-собака исподтишка за икры хватает. | к. 1470 |
| 1327. Молчание — знак согласия. | Эндәшмәү — ризалык галәмәтедер. |
| 1328. Молчание — золото. | Сөйләвең — көмеш, тик торуың — алтын.<br>Тик торуың — саф алтын. |
| 1329. Море жизни. | Тормыш күге.<br>Тормыш диңгезе. |
| 1330. Море — ветром, народ слухом волнуется. | ≅ Дөньяны җил боза, адәмне сүз боза. |

1331. Мороз по коже пробежал.

Тәнем чымырдап китте.
Тәнем буенча салкын йөгерде.
Тәнемә салкын су койган кебек булды.

1332. Морочить голову.

Башны катыру.

1333. Москву видно.

к. 2531.

1334. Мочалку жевать.

Чүбек чәйнәү.

1335. Моя бабушка с его дедушкой вместе капусту садили.

к. 72.

1336. Моя хата с краю, ничего не знаю.

Өем эче сау булгач, тирәягым яу булсын.

1337. Мудрость в человеке, а не в бороде.

Акыл сакал чыкканны көтми.
Акыл яшьтә түгел, башта.

1338. Муж—голова, жена—душа: куда захочу, туда и заворочу.

Ир—баш, хатын—муен.

1339. Муж жену любит здоровую, а брат сестру—богатую.

Бай булсаң, илең сөяр, сау булсаң, ирең сөяр *(искер.)*
Ир сөяр сауны, хатын сөяр байны.

1340. Мужик богатый, что бык рогатый.

≌ Байлыгы сикертә (масайта мәгънәсендә).

1341. Мурашки по телу пробежали.

Тәнем каз (тавык, күркә) тәне кебек булды (к. 1331).

1342. Мухи не обидит.

Чебен үтермәс.

1343. Мы с тобою — как рыба с водою.

Арабыздан жил үтми.
Алма белән алма кебек яшибез.

1344. Мы сами с усами.

Безнең үзебезгә дә мыек чыккан хәзер (акыл кергән инде дигән мәгънәдә).

1345. Мышь сыта и мука горька.

Ашап туйгач, тозы юк (тәмсез).

1346. Мягко стелет, да жёстко спать.

Йомшак җәеп, катыга утырта.
Йомшак түшәп, каты яткыра.
Йомшак җәеп, катыда кабырга кабарта.

# Н

| | |
|---|---|
| 1347. На безптичье и дергач соловей. | к. 1348. |
| 1348. На безрыбье и рак рыба. | Ит булмаганда үпкә тансык. |
| 1349. На бога надейся, а сам не плошай. | Аллага тапшыр, дилбегәне үзең тот. |
| 1350. На большом пути и малая ноша тяжела. | Җәяүлегә янчык та авыр. |
| 1351. На брюхе — шёлк, а в брюхе—щёлк. | Тыштан ялтырый, эчтән калтырый (к. 1378). |
| 1352. На весь мир мягко не постелешь. | Бөтен кешенең күңелен күрә алмассың.<br>Бөтен кешенең дә җаена тора алмассың (к. 1357). |
| 1353. На вкус и на цвет товарища нет. | Сиңа яраган миңа ярамый, миңа уң булган күршегә кул түгел. |
| 1354. На воде вилами написано. | Бозга язган.<br>Суга сәнәк белән язган. |
| 1355. На воре шапка горит. | Каракның бүреге яна. |
| 1356. На все четыре стороны. | Дүрт ягың кыйбла.<br>Ишек ачык, юл такыр. |
| 1357. На всех не угодишь. | Бөтен кешегә ярый алмассың (к. 1352). |
| 1358. На всякий (чужой) роток не накинешь платок. | Ил авызына иләк капламассың.<br>Кеше авызын каплап (томалап) булмый. |
| 1359. На всякого горшка найдётся и покрышка. | Чиләгенә күрә капкачы табылыр. |
| 1360. На глазах навернулись слёзы. | Күзгә яшьләр килде (тулды). |
| 1361. На глупый вопрос не бывает ответа. | Ахмак сүзгә җавап юк.<br>Ахмакка тик тору җавап. |

1362. На добрый привет добрый и ответ.
Төчегә ачы булмас.
Яхшылыкка яхшылык.

1363. На душе мутит.
Кәеф кырылып тора.

1364. На живую нитку.
Эштер-өштер китереп эшләү. Миннән киткәнче, иясенә җиткәнче.

1365. На живую руку.
к. 1364.

1366. На закате дней.
Картаймыш көндә.

1367. На затылке глаз нету.
Артымда күзем юк.

1368. На здоровье!
Исәнлеккә-саулыкка!

1369. На зеркало неча (нечего) пенять, коли рожа крива.
Авызың кыек булса, көзгегә үпкәләмә.

1370. На иного взглянешь — картина, а разглядишь — скотина.
Тышы — ефәк, эче — кибәк.
Тышы — мамык, эче — кабык.
Тыштан ал да гөл, эчтән үзең бел.
Эчтән калтырый, тыштан ялтырый.

1371. На коня не кладут двух сбруй.
Бер атка ике камыт кидермиләр.

1372. На крепкий сук — острый топор.
Каты агачка каршы чөй.

1373. На лбу не написано.
Маңгаена язылмаган.

1374. На Маланьину свадьбу.
Тиле кызның туена (аш суны чамадан тыш күп итеп хәзерләү мәгънәсендә).

1375. На миру и смерть красна.
к. 2201.

1376. На наше трепало, что не попало, всё мнёт.
(Анын) морҗасы төтен кайтармый.

1377. На нет и суда нет.
Юкның аты юк.
Юкның башы авыртмый.

1378. На ногах сапоги скрипят, а в горшке мухи кипят.
Өе биек, өйрәсе сыек (к. 1351).

1379. На носу (быть).
Борын төбендә (булу).

1380. На ночь глядя.
Төнгә каршы.

1381. На одном плесу двоим рыбакам не житьё.
к. 577.

| | |
|---|---|
| 1382. На ошибках учатся. | Адәм ялгыша-ялгыша галим була (өйрәнә). |
| 1383. На покляпое дерево и козы скачут. | Йомшак агачны корт баса. |
| 1384. На правду нет слов. | Дөрес (туры) сүзгә җавап юк. |
| 1385. На произвол судьбы (бросать). | Язмыш кочагына (ташлау). |
| 1386. На работу — позади последних, на еду — наперёд первых. | Аш янында ат кебек, эш янында эт кебек. |
| 1387. На работу — так-сяк, а на еду мастак. | к. 1386. |
| 1388. На рать сена не накосишься. | Көтүгә солы салмыйлар. |
| 1389. На руку нечист. | Аның кулы кәкре (карак мәгънәсендә).<br>Кырын куллы.<br>Суык куллы.<br>Туры куллы түгел. |
| 1390. На свашенькиных речах хоть садись да катись. | Димче дингез кичерә.<br>Димче дингез кичерә, өтеп суга төшерә. |
| 1391. На свежую голову. | Саф баш беләп.<br>Саф баштан. |
| 1392. На своей улочке и курочка храбра. | Эт оясында көчле.<br>Эт үз оясында батыр. |
| 1393. На свой ум надейся, а за чужой не держись. | к. 1268. |
| 1394. На свою голову. | Үз башына.<br>Үзенең газиз башына. |
| 1395. На скорую руку (сделать). | Ашык-пошык эшләп ташлау. |
| 1396. На скорую ручку — комом да в кучку. | Әштер-өштер, кандаладан ботка пешер. |
| 1397. На словах — как на гуслях, а на деле — как на балалайке. | Теле сөйли, тик эше генә юк. |

1398. На словах медок, а на сердце ледок.
Тел очы баллы, тел төбе кортлы.
Тел төбе татлы, тамак төбе кортлы.

1398а. На смертном одре (быть).
Үлем түшәгендә (яту).

1399. На собаках шерсть бьёт.
Эт кыркып (көтеп) йөри (к. 13).

1400. На старости лет.
к. 1366.

1401. На стену лезть.
Күтәрелеп бәрелү.

1402. На тот свет (отправиться).
Теге дөньяга китү (к. 1780, 1826, 1863).

1403. На трезвую голову.
Аек баштан.
Аек баш белән.

1404. На трусливого много собак.
к. 2605.

1405. На улице не найдёшь.
Җирдә ятмый.
Бакчада үсми.
Төшереп калдырмаганнар.

1406. На ум наставить.
Акыл өйрәтү.

1407. На ухе́ ожёгся, так и на воду подуешь.
к. 1716.

1408. На хорошего глядеть хорошо, с умным жить хорошо.
к. 1123, 1129.

1409. На худой конец.
Һич тә булмаса.
Һич югында.

1410. На чердаке не всё в порядке.
к. 293.

1411. На чужой карман тороват.
Кешенеке белән юмартлана (юмартланырга ярата).

1412. На чужой каравай рот не разевай, а свой затевай.
Кешенекенә кызыкма.
Кешенекенә нәфесеңне сузма.

1413. На чужой обед надейся, а свой припасай.
⚠ Туйга (кунакка) барсаң туеп бар, куеныңа икмәк тыгып бар.

1414. На чужой рот пуговицу не нашьёшь.
к. 1358.

| | |
|---|---|
| 1415. На чужой спине беремя легко. | Кеше җилкәсе авыртмый. |
| 1416. На чужой сторонушке рад своей воронушке. | Чит җирдә үз иленнең (авылыңның, ягыңның) эте дә якын. |
| 1417. На чужую одёжу плоха надёжа. | Кеше аты тирчән, кеше киеме керчән. |
| 1418. На чьём возу сижу, того и песенку пою. | к. 239. |
| 1419. На этом ноже хоть верхом, хоть вскачь. | Үлгән кешене тергезерлек пычак (үтми мәгънәсендә). Кисә башласаң, мәет сикереп торырлык. |
| 1420. На языке вертится. | Тел очында гына тора (әйтә алмыйм, искә төшерә алмыйм дигән мәгънәдә). |
| 1421. На языке мёд, а в сердце лёд. | к. 1398. |
| 1422. На языке мёд, а под языком лёд. | к. 1398. |
| 1423. Набить оскомину. | Тешләрне камаштыру. |
| 1424. Набраться храбрости (смелости). | Батырлык (кыюлык) җитү. |
| 1425. Набросить тень (*на кого-нибудь*). | Йөзгә кара ягу. Тап төшерү. |
| 1426. Навести на путь истинный. | Туры юлга салу. |
| 1427. Навести (нагнать) страх. | Курку салу. |
| 1428. Навести тоску. | Эч пошыру. |
| 1429. Навести тень. | к. 1425. |
| 1430. Навоз поверху плывёт. | Чүп-чары өстә була. |
| 1431. Навострить уши. | Колакларны торгызу. Колаклар үрә тору. |
| 1432. Навязло в зубах. | Теш корты булды (бит). Теңкәгә тиде. |
| 1433. Нагонять (нагнать) тоску. | к. 1428. |
| 1434. Над другом посмеялся — над собой поплачешь. | Иртә көлсәң кешедән, кич көләрләр үзеңнән (к. 1468). |

| | |
|---|---|
| 1435. Над нами не каплет. | Түбәбезгә таммый бит. Түбәбезгә су үтми бит. |
| 1436. Надеть намордник. | Авызлык кидерү (авызлыклау, ягъни тыю, буйсындыру мәгънәсендә). |
| 1437. Надеяться как на каменную гору (стену). | Ташка (тауга) ышангандай ышану. |
| 1438. Надорвать живот со смеху. | Көлә-көлә кату чыгу (катуга сабышу). Көлә-көлә эч кату. |
| 1439. Наелся по горло. | Алкымымнан килгәнче ашадым. Гарык булганчы ашадым. |
| 1440. Назвался груздем, полезай в кузов. | Паңгы (гөмбә) булдыңмы, кызауга кер. |
| 1441. Называть белое чёрным. | Ап-акны кап-кара дип әйтү. |
| 1442. Называть вещи своими именами. | (Һәр нәрсәне) үз исеме белән атау. |
| 1443. Найти общий язык. | Уртак тел табу. |
| 1444. Найти отдушину. | Юаныч табу. |
| 1445. Нам грешным и ветер навстречный. | Хәерчегә (бәхетсезгә) җил каршы. |
| 1446. Нам с тобой каши не сварить. | Синең белән минем борчак пешмәс. |
| 1447. Намозолить глаза. | Күзгә кергән чүп булу. |
| 1448. Намотать себе на ус. | Мыекка чорнап кую. Колакка салып кую (истә тоту мәгънәсендә). |
| 1449. Нанести обиду. | Хәтер каллыру. |
| 1450. Нанести ущерб. | Зыян китерү. |
| 1451. Наотрез отказать(ся). | Кырт кисеп баш тарту. |
| 1452. Напал страх. | Курку басты. |
| 1453. Напекло голову. | Башка эссе капты (сукты). Башка жар капты. |
| 1454. Наряди пень в вешний день, и тот будет красив. | Агач күрке — яфрак, адәм күрке — чүпрәк. |
| 1455. Наряди свинью в серьги, а она всё в навоз. | Этнең (ишәкнең) башын табакка салсаң да, тәгәрәп төшәр. Ишәк түшәк кадерен |

| | |
|---|---|
| | белмәс. Сыер сыйпаганны белмәс. Юньсезне табакка төртсәң, тагаракка тартыр. |
| 1456. Насилу ноги волочить. | Аякны көчкә өстерәп йөрү. |
| 1457. Насильно мил не будешь. | Янмаган чыраның яктысына туймассың (мәҗбүр итеп яраттыра алмассың мәгънәсендә). |
| 1458. Наскоро делать — переделывать. | Ашык-пошык эшләгәннән рәте булмас. |
| 1459. Наступить на любимую мозоль. | Авырткан җиргә кагылу. Чуанына басу (кагылу). |
| 1460. Наступить на хвост (на пятки). | Үкчәсенә басу. |
| 1461. Находиться между жизнью и смертью. | Үлем белән тартышу. Җир җимеше булып яту. |
| 1462. Находиться на грани жизни и смерти. | к. 1461. |
| 1463. Начать разговор. | Сүз ачып җибәрү. Сүз башлап җибәрү. Сүз кузгату. |
| 1464. Начинать с азов. | А, Б-дан башлау. Әлиф, би-дән (әлифтән) башлау. |
| 1465. Наша Марина вашей Катерине двоюродная Прасковья. | Ботак очы кардәш (к. 72). |
| 1466. Наша невестка всё трескает. | к. 1376. |
| 1467. Нашему слесарю — двоюродный кузнец. | к. 72. |
| 1468. Не бей в чужие ворота плетью, не ударили бы в твои дубиной. | Какма кеше капкасын, үз капкаңны кагарлар (к. 1434). |
| 1469. Не богат, да тороват. | Ярлы булса да, күңеле киң. |
| 1470. Не бойся собаки брехливой, а бойся молчаливой. | Өргән эттән курыкма, астыртын эттән саклан (к. 1471). |

| | |
|---|---|
| 1471. Не бойся собаки, которая лает. | Искәрмәс (астыртын) түмгәк чана аудара. |
| 1472. Не бойся умного врага, бойся глупого друга. | Белексез дустан белекле дошман артык. |
| 1473. Не в бороде честь, она и у козла есть. | Сакалың белән мактанма: сакал кәҗәдә дә бар, мыек мәчедә дә бар. |
| 1474. Не в бровь, а прямо в глаз. | Күзенә (йөзенә) бәреп әйтү. |
| 1475. Не в духе. | Кәефе юк. |
| 1476. Не в коня корм. | Эт эченә (корсагына) сары май ярамый. |
| 1477. Не в обиду будь сказано. | Гаепләштән (үпкәләштән) булмасын. |
| 1478. Не в свои сани не садись. | Көчеңнән (кулыңнан, хәлеңнән) килмәгән эшкә ябышма. Эшең түгелгә тыгылма. |
| 1479. Не в службу, а в дружбу. | Дуслык хакына. |
| 1480. Не верить своим ушам (глазам). | Үз колакларыңа (күзләреңә) үзең ышанмау. |
| 1481. Не верь брату родному, верь своему глазу кривому. | Ышанма сүзенә, ышан күзенә. Үзеңнән үзгәне әүлия дип белмә. |
| 1482. Не верь своим очам, а верь моим речам. | Ышанма күзеңә, ышан сүземә. |
| 1483. Не верь чужим речам, а верь своим очам. | к. 1481. |
| 1484. Не взирая на лица. | Кемнең кем булуына карамастан. |
| 1485. Не видит под носом, а видит за лесом. | к. 236. |
| 1486. Не возьмёшь голыми руками. | Коры кул белән генә ала алмассың. |
| 1487. Не возьму в толк. | Башыма җитми. Аңлый алмыйм. |
| 1488. Не время волос белит, а кручина. | Егет үзе картаймаса, дөнья картайта икән (*искер.*). |
| 1489. Не все дома. | к. 293. |

1490. Не всё коту масленица, будет и великий пост.

Аткан саен үрдәккә тими.
Капкан саен калҗа булмый, бәрәңгесе дә эләгә.
Көн дә-көн дә бәйрәм булмый.
Салган саен кармакка балык эләкми.
Ялан-ялан майлы ботка булмый.

1491. Не всё ненастье — будет и вёдро.

к. 121.

1492. Не всё ненастье, проглянет и красное солнышко.

к. 121.

1493. Не всё ровно, есть и горы.

Кисәлтәсез (казылмасыз, сикәлтәсез) юл булмас, капкан саен бал булмас (к. 1490).

1494. Не всё слушай, иное и мимо ушей пропускай.

Барысын да ишетмә, кайсыберсен колак артыннан җибәр.

1495. Не всё таской, иное и лаской.

Кайсысына көй кирәк, кайсысына чөй кирәк.

1496. Не всё то волк, что серо.

Һәр кара нәрсә бүре түгел (булмый).

1497. Не всё то золото, что блестит.

Һәр ялтыраган алтын түгел.

1498. Не всё то правда, что люди говорят.

Һәр сөйләнгән сүз саф алтын түгел.
Һәр төкерек алтын түгел.

1499. Не всё то русалка, что в воду ныряет.

к. 1497.

1500. Не всегда говори, что знаешь, но всегда знай, что говоришь.

Белгәнеңне сөйләмә, ни сөйләгәнеңне бел.
Белеңеңне белеп из.

1501. Не всякому верь, запирай крепче дверь.

Үзеңнән үзгәне әүлия дип белмә.

1502. Не вымнем корова молоко даёт (доит), а рылом.

к. 1107.

1503. Не выноси сора из избы.

к. 925.

1504. Не высокого полёта птица.

Әллә кем түгел.

1505. Не гладь коня рукою, гладь мешком.

к. 1511.

1506. Не глиняный, от дождя не размокнешь.

Тоз түгел, эремәссең.

1507. Не говори: не могу, а говори: не хочу.

Булдыра алмыйм димә, (ә) теләмим диген.

1508. Не говоря худого слова.

Бер сүз дә әйтмичә.
Актан-карадан бер сүз әйтмичә.
Бер сүзсез.

1509. Не говорят трижды про одни дрожди.

Бер үк балык башын чәйнәмиләр.

1510. Не годы старят, а горе (жизнь).

к. 1488.

1511. Не гони коня кнутом, гони овсом.

Атны чыбыркы белән кума, солы белән ку.

1512. Не горит да не варит.

Ике ятып бер төшемә керми.

1513. Не греши на него.

Аңа юкка гөнаһлы булма.

1514. Не давай голодному хлеба резать.

Ачка казан астырма, туңганга утын яктырма.

1515. Не дай бог с дураком найти.

Тиле белән тапма да, өләшмә дә.

1516. Не дал бог свинье рогов, а бодуща была бы.

к. 89.

1517. Не дать рта раскрыть.

Авыз ачарга да ирек бирмәү.

1518. Не деньги нас наживали, а мы деньги нажили.

Малны баш таба, башны мал тапмый.

1519. Не держи сто рублей, держи сто друзей.

к. 1530.

1520. Не до поросят свинье, коли самое палят на огне.

≌ Яңгыр яуганда бала жәл, таш яуганда баш жәл.

1521. Не довернёшься — бьют, и повернёшься — бьют.

Тегеләй дә ярамый, болай да ярамый.

1522. Не достаёт (нет) только птичьего молока.

Аю башы гына юк.
Елан мөгезе генә юк.
Күгәрчен сөте генә юк.

АХМЕТ БАЙТҰРСЫНҰЛЫ ... ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

1523. Не думано — не ведано, не чаяно — не гадано.

Уйламаганда-көтмәгәндә.
Истә-коста булмаганда.
Уйга килмәгәндә, төшкә кермәгәндә.
к. 1281.

1524. Не жалей алтына, отдашь полтину.

1525. Не жилец на свете.

Гомере (яшисе) күп калмаган.

1526. Не за горами.

Әллә кая (еракта) түгел.
Ерак барасы юк.
к. 747.

1527. Не заламывай рябину невызревшу, не бери девку не вызнавши.

1528. Не знать, куда глаза деть от стыда.

Оялудан күзне күтәреп карый алмау.

1529. Не из той оперы.

Дуга белән печән чабасың (бөтенләй башка нәрсә турында сөйлисең дигән мәгънәдә).

1530. Не имей сто рублей, имей сто друзей.

Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын.

1531. Не испортив дела, мастером не будешь.

Адәм ялгыша-ялгыша галим булыр диләр (к. 1559).

1532. Не к добру.

Хәерлегә түгел.
Яхшыга түгел.

1533. Не к роже румяна, не к рукам пироги.

Эт корсагына сары май ярамый.

1534. Не к спеху.

Ашыгыч түгел.

1535. Не казать глаз (носу).

Койрыгын да күрсәтмәү.

1536. Не кивай на соседа, а погляди на себя.

Кешене тикшермә, үзеңне бел.
≅Бездә булмас гаеп, үзегездән чыкмасын таеп.

1537. Не купи двора, купи соседа.

Әүвәл күршеңне кара, аннан йорт ал.

1538. Не купив коровы, да завёл подойник.

Тумаган балага бишек кора.
Яумаган янгырга балаган кора (к. 1290).

1539. Не лезь наперёд: не стать бы позади.

Югары күтәрелеп, түбән төшмә.

1540. Не лыком шиты. — Төшеп калганнардан түгел.

1541. Не место человека красит, а человек место. — Кеше урыны белән күркәм түгел, ә урын кеше белән күрекле.
Кешене урын аруландырмый, кеше урынны аруландыра.

1542. Не мешало бы. — Зарар итмәс иде.

1543. Не мочь глаз оторвать. — Күзне ала алмау.
Күреп туя алмау.

1544. Не мочь поручиться (за достоверность *чего-либо*). — Йөгенә керә алмау (бирәр нәрсәнен).

1545. Не моргнуть глазом. — Күз дә йоммау (ис китмәү мәгънәсендә).

1546. Не мочь заснуть. — Йокы алмау.
Күзне йокы алмау.

1547. Не на зеркало пеняй, что рожа крива. — к. 1369.

1548. Не надо хвалить утро, пока не наступит вечер. — Кичсез көнең мактама.
Айсыз атың мактама, елсыз хатының мактама.

1549. Не надобен и клад, коли у мужа с женой лад. — к. 2667.

1550. Не нам с ним (с ней) жить, а тебе. — Без торасы түгел, үзең торасы.

1551. Не нашему носу рябину клевать. — Безнен көч житәрлек түгел.
Безнең кулдан килерлек түгел.

1552. Не о двух головах. — Башы ике түгел.

1553. Не обманешь — не продашь (*устар.*). — Сату-алу эшенә алдау кермичә булмый ди (*искер.*).
Алдаусыз (хәйләсез) дөнья файдасыз (*искер.*).

1554. Не обмолвиться ни словом. — Авыз ачып сүз әйтмәү.

1555. Не одной тобой свет стоит. — Дөнья сиңа гына терәлмәгән.
Дөнья синең белән миннән генә тормый бит.

1556. Не от мира сего. — Ике дөньядан буш калган.
Дөнья кешесе түгел.

1557. Не отведав горького, не узнаешь и сладкого.

Ачыны күрми, төчене белмисең.

Ачысыз төче булмас.

Корт чакмыйча, бал булмый.

Көл булмый, гөл булмассың.

1558. Не откладывай до завтра (назавтра), что можешь сделать сегодня.

Бүгенге эшне иртәгә калдырма.

Калган эшкә кар ява.

1559. Не ошибается тот, кто ничего не делает.

Эшләмәгән кеше генә ялгышмый.

Бозмыйча өйрәнмисең: ялгыша-ялгыша беләсең (к. 1531).

1560. Не плюй в колодец — пригодится напиться (воду пить).

Төкермә иске коеңа, кайтып суын эчәрсең.

Төкермә коега, суын эчәрсең.

1561. Не по дням, а по часам.

Көнләп түгел, сәгатьләп.

1562. Не по зубам эти орешки.

Теш үтми.

Теше батмый.

1563. Не по красивому любим, а по любимому красив.

Чибәр чибәр күренмәс, сөйгән чибәр күренер.

Сылу сылу күренмәс, сөйгән сылу күренер.

1564. Не по хорошему мил, а по милому хорош.

Мәхәббәт күркәм күрсәтә.

Яхшы яхшы түгел, җан сөйгән яхшы.

1565. Не повернуть колесо истории вспять.

Дөнья (тарих) тәгәрмәчен кирегә борып булмый.

1566. Не подставляй ноги, на самого спотычка нападёт.

к. 1582.

1567. Не подымай носу: споткнёшься.

Борыныңны бик күтәрмә, түбән төшмәсең.

Борыныңны бик күтәрмә, эләкмәсең агачка.

Борыныңны күккә чөймә, бидрә (чиләк) элеп куярлар.

| | |
|---|---|
| 1568. Не пойман — не вор. | Тотылмаган карак — карак түгел. |
| 1569. Не поминай лихом! | Начарлык белән искә алма! |
| 1570. Не помутясь и море не уставится. | Бер болганмый су да тонмый. |
| 1571. Не посмотришь — не увидишь, не расспросишь — не найдёшь. | Ачмый күренми, әйтми беленми. |
| 1572. Не прав медведь, что корову съел, не права и корова, что в лес зашла. | Атта да бар гаеп, тәртәдә дә бар гаеп. |
| 1573. Не принять горького, не видать сладкого. | к. 1557, 1709. |
| 1574. (Не) пришей кобыле хвост. | Кирәкле кишер яфрагы. |
| 1575. Не пугай сокола вороной. | Кабык сугып, чыпчык (чәүкә) куркытма. |
| 1576. Не пытай старого, а пытай бывалого. | Күп торганнан сорама, күп күргәннән сора.<br>Күп яшәгән ни белгән, күпне күргән шул белгән. |
| 1577. Не разгибая спины (работать). | Баш күтәрми (эшләү). |
| 1578. Не робкого десятка. | Төшеп калганнардан түгел. |
| 1579. Не родись красивым, а родись счастливым. | Булма күрекле, бул бәхетле. |
| 1580. Не родись ни хорош, ни пригож, родись счастлив. | к. 1579. |
| 1581. Не родись ни умён, ни красив, а родись счастлив. | к. 1579. |
| 1582. Не рой другому яму, сам в неё попадёшь. | Кешегә баз казыма, үзең төшәрсең. |
| 1583. Не с богатством жить, а с человеком. | ≅ Идәне җир булсын, егете ир булсын. |
| 1584. Ни с места! | Урыныннан да кузгалма! |
| 1585. Не сводя глаз (смотреть). | Күз дә алмый карау (карап тору). |
| 1586. Не связывайся с дураком. | Тилегә эшең төшмәсен.<br>Тиле белән бәйләнмә (к. 1515). |

| | |
|---|---|
| 1587. Не семи пядей во лбу. | Алланың кашка тәкәсе түгел.<br>Кашкалы түгел.<br>Мөгезле түгел. |
| 1588. Не сказать ни добра, ни худа. | Актан-карадан бер сүз әйтмәү. |
| 1589. Не смейся, братец, чужой сестрице: своя в девицах. | Көлмә кешедән, көлмәсеннәр үзеңнән.<br>Кешедән көлмәк — үзеңә килмәк (к. 1431, 1468). |
| 1590. Не смейся, горох, не лучше бобов. | Көлмә кешедән, авызың өшегән. |
| 1591. Не смейся над старым: и сам будешь стар. | Карт кешедән көлмә, үзең дә картаерсың. |
| 1592. Не смейся чужой беде, своя на гряде (чреде). | к. 1589. |
| 1593. Не смотри на кличку, а смотри на птичку. | Исеменә карама, җисеменә кара. |
| 1594. Не соврёшь и зобу не набьёшь *(устар.)*. | Хәйләсез дөнья файдасыз *(искер.)*. |
| 1595 Не солнышко: всех не обогреешь. | Кояш түгел — бөтен дөньяны җылыта (якгырта) алмассың. |
| 1596. Не спрашивай старого, а спрашивай бывалого. | к. 1576, 1597. |
| 1597. Не спрашивай у того, кто много ходил, спрашивай у того, кто много видел. | Күп йөргәннән сорама, күп күргәннән сора.<br>Күп яшәгән ни белгән, күп йөргән шул белгән (к. 1576). |
| 1598. Не спускать (*кого-либо*) с глаз. | (Берәр кешедән) күз язмау.<br>Күздән ычкындырмау. |
| 1599. Не стой надо мною, как чёрт над душою. | Газраил шикелле өстемдә торма.<br>Атлы казак кебек торма каршымда. |
| 1600. Не стоит выеденного яйца. | к. 1241. |
| 1601. Не стыдно не знать, а стыдно не учиться. | Белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп. |
| 1602. Не суйся вперёд, когда есть место у дверей. | Ишек янында урын барда, түргә узма. |

1603. Не сули журавля в небе, дай синицу в руки. — к. 768.

1604. Не считай утят, пока не вылупились. — к. 2702.

1605. Не так норовим, чтобы в рот, как чтобы в карман *(устар.)* — Тамак кайгысы түгел, кесә кайгысы. (*искер.*).

1606. Не топтать слова. — Сүзне җиргә салмау.

1607. Не тот опытен, кому много лет, а тот, кто много видел. — к. 1576, 1597.

1608. Не тронь меня! — Чебен тимәс чер итәр.

1609. Не убив медведя, шкуры не продают. — к. 1290.

1610. Не ударить лицом в грязь. — Йөзгә кызыллык китермәү.

1611. Не узнав горя, не узнаёшь и радости. — к. 1557, 1709.

1612. Не указывай на чужой двор пальцем, не указали бы на твой двор вилами. — к. 1468.

1613. Не укусывала тебя своя блоха (своя вошь). — Аягыңа кара сыер басмаган әле.

1614. Не успел и глазом моргнуть. — Күз ачып йомганчы.

1615. Не успеть оглянуться. — Борылып карарга да өлгермәү.

1616. Не хвали в очи, не брани за глаза. — Алып мактама, салып таптама.

1617. Не хвались замужеством третьего дня, а хвались третьего года. — ⚖ Айсыз атың мактама, елсыз хатының мактама.

1618. Не хвались сам, пусть другие тебя похвалят. — Үзеңне үзең мактама, кеше сине мактасын.

1619. Не чёрт копал, сам попал. — к. 329.

1620. Не чёрт толкал, своей головой попал. — к. 329.

1621. Не чувствовать (не слышать) под собой ног. — Шатлыктан кая басканны (да) белмәү.

Җире-күге белән шатлану (к. 156).

1622. Не шути (не играй) с огнём, обожжёшься. — Ут белән уйнама, пешәрсең. Куян белән уйнама — чарчарсың, ут белән уйнама — көярсең.

1623. Не шутка. — Уен түгел.

1624. Не шутя. — Чын-чыннан.

1625. Не я первый, не я последний. — Миннән генә калган эш түгел.

1626. Небо с овчинку (показалось). — Котым очты. Котым ботыма төште.

1627. Небу жарко станет. — Кая барырга урын тапмассың. Кая керер(гә) тишек тапмассың.

1628. Невооружённым глазом. — Гади күз белән.

1629. Негде голову преклонить. — Кунар агачы, сайрар куагы юк. Сыеныр урыны юк.

1630. Недалеко идти за примером. — Мисал эзләп ерак барасы юк (түгел).

1631. Недосуг носа утереть. — Баш кашырга да вакыт юк. Кашынырга да вакыт юк.

1632. Незнайка дома сидит, а знайку в суд ведут. — Белмимнең башы авыртмый. Белмәгәннең беләге авыртмый.

1633. Незнайка на печи лежит, а знайку на верёвочке ведут. — к. 1632.

1634. Некогда даже за ухом почесать(ся). — к. 1631.

1635. Некуда из тучи капле дождя капнуть. — к. 909.

1636. Нельзя откладывать в долгий ящик. — Озакка калдырырга ярамый. Калган эшкә кар ява диләр.

АХМЕТ БАЙТҰРСЫНҰЛЫ атындағы ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

| | |
|---|---|
| 1637. Нем, как рыба (как могила). | Сер сыя торган кеше. |
| 1638. Немазаное (не подмазанное) колесо скрипит. | Майламаган арба кычкыра (шыгырдый).<br>Майламыйча арба йөрми.<br>Майламасаң куласа (тәгәрмәч) әйләнми.<br>Майламыйча арбасы, җайламыйча чанасы йөрми. |
| 1639. Неосторожно говорить — без всяких болезней умереть. | Уйламый сөйләсәң, авырмый үләрсең. |
| 1640. Неприкрытая ложь. | Чеп-чи ялган.<br>Ап-ачык ялган. |
| 1641. Непродажному коню и цены нет. | Сатылмас малга бәя юк.<br>Сатмас товар — мең алтын. |
| 1642. Неразумного учить — в бездонную кадку воду лить. | Ахмакны өйрәтү — үлгәнне терелтү. |
| 1643. Несварение желудка. | Ашказаны эшләмәү. |
| 1644. Нет дыма без огня. | к. 436. |
| 1645. Нет за кожей, так не пришьёшь к коже. | Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс. |
| 1646. Нет и тени сомнения. | Аз гына да шикләнми(м).<br>Шикләнүнең әсәре дә юк. |
| 1647. Нет-нет, да перепадёт. | Акмаса да тама. |
| 1647а. Нет худа без добра. | Хәерсезнең хәере була.<br>Искесез яңа булмас, ямансыз яхшы булмас. |
| 1648. Нечего греха таить. | Яшерен-батырын түгел. |
| 1649. Нечему удивляться. | Гаҗәпләнер урын юк. |
| 1650. Ни аза не знать. | к. 5. |
| 1651. Ни бэ, ни мэ не знает. | к. 5. |
| 1652. Ни бельмеса не знает. | к. 5. |
| 1653. Ни богу свечка, ни чёрту кочерга. | Ни аллага, ни муллага (патшага, бәндәгә).<br>Тере дисәң санда юк, үле дисәң гүрдә юк. |

1654. Ни в грош не ставить. — Санга санамау (сукмау).
Бер тиенгә дә куймау.
Сукыр бер тиенгә дә куймау.

1655. Ни в сказке сказать, ни пером написать. — Әйтеп-сөйләп бетерә торган гына түгел.

1656. Ни гу-гу! — Май кап!
Тының чыгарма!
Ләм-мим!

1657. Ни два, ни полтора. — Ни ултара (ылтара) ни пылтара.

1658. Ни дерева без порока, ни коня без подтычки. — к. 891, 894, 895, 1099.

1659. Ни думал, ни гадал, как в беду попал. — Уйламаганда-көтмәгәндә бәлагә төштем.

1660. Ни дыма без огня, ни следствия без причины. — к. 436.

1661. Ни жарко, ни холодно. — Ни эссе түгел, ни салкын түгел — аның өчен барыбер.
Өшеми дә, пешми дә — аның өчен барыбер.

1662. Ни жив, ни мёртв. — Агарып каткан.
Яртылаш үлгән.
Җаны уч төбендә генә калган.

1663. Ни за какие сокровища (не дам). — Үзе кадәр алтын бирсәләр дә (бирмим).

1664. Ни к чему не приступиться. — Якын бара торган түгел (кыйммәт мәгънәсендә).

1665. Ни кола, ни двора. — Каккан казыгы да юк.

1666. Ни коня, ни возу, ни что на воз п ложить. — Ат юк, арба юк, аннан калган бар да юк.

1667. Ни ломаного гроша. — к. 539.

1668. Ни на волос (не отличается). — Тырнак очы кадәр дә (аерылмый).
Инә очы кадәр дә (аерылмый).

1669. Ни на йоту. — Аз гына да.
Һич тә.

1670. Ни пава, ни ворона.

Адәм дисәң — коны юк, хайван дисәң - йоны юк,
Адәм дисәң — сыны юк, хайван дисәң — йоны юк.
Хайван дисәң — йоны юк, адәм дисәң—юне юк.
Эт дисәң — койрыгы юк, сыер дисәң — мөгезе юк.

1671. Ни рыба, ни мясо.

Ни он, ни йон.
Ни он түгел, ни камыр түгел (к. 1670).

1672. Ни рыба, ни мясо, ни кафтан, ни ряса.

к. 1670, 1671.

1673. Ни с того, ни с сего.

Бер дә юктан.
Тик (кенә) торганда.
Һичбер сәбәпсез.

1674. Ни свет, ни заря.

Таң тишегеннән.
Ачы таңнан.

1675. Ни себе, ни людям.

Ни үзенә, ни кешегә.

1676. Ни седельца, ни уздицы, ни той вещицы, на что надеть уздицу.

к. 1666.

1677. Ни сиво, ни буро.

Ала да түгел, кола да түгел.

1678. Ни складу, ни ладу.

Рәте чираты юк.

1679. Ни слуху, ни духу.

Исе-косы юк.
Эзе дә юк, исе дә юк.

1680. Ни слуху, ни духу, ни вестей, ни костей.

к. 1679.

1681. Ни сна, ни покоя не видать.

Йокы йөзе күрмәү.
Җаны ястык күрмәү.

1682. Ни стыда, ни совести нет.

Ояты да юк, хәясы да юк

1683. Ни сучка, ни задоринки.

Шоп-шома гына.

1684. Ни сыт, ни голоден.

Ачлы-туклы (яшәү).

1684а. Ни то, ни сё.

Ни ары, ни бире.

1685. Ни хижи, ни крыши.

к. 1665.

1686. Ни хлеба в суме, ни гроша в котоме.

к. 1666.

| | |
|---|---|
| 1687. Никто дважды молод не бывает. | Яшьлек ике килми. |
| 1688. Никто того не ведает, как бедный обедает *(устар.)*. | к. 2524. |
| 1689. Ничего-то у нас и дома много. | Юкка без үзебез дә тук. |
| 1690. Новая метла чисто метёт. | Яңа себерке яхшы себерә. |
| 1691. Нового друга желай, а старого не забывай. | к. 2479. |
| 1692. Ноги моей не будет. | Эземне дә күрсәтмәм.<br>Аяк та басмам.<br>Ике аягымның берен басмам. |
| 1693. Ноги подкашиваются. | Тез буыннары калтырый. |
| 1694. Ноги протянуть. | Аяк сузу (үлү мәгънәсендә). |
| 1695. Ногтя (его) не стоит. | (Аның) кисеп ташлаган тырнагына да тормый.<br>Баскан эзенә дә алмаштырырлык түгел (к. 201). |
| 1696. Нос вздёрнуть. | Борын күтәрү (чөю).<br>Борынны күккә чөю.<br>Борыны белән күкне сукалау. |
| 1697. Нос воротить. | Борын чөерү.<br>Йөз чөерү. |
| 1698. Нос вытащит — хвост увязнет, хвост вытащит — нос увязнет. | Башын алса — койрыгыябыша, койрыгын алса — башыябыша. |
| 1699. Нос задирать. | к. 1696. |
| 1700. Носи на здоровье. | Эссе (җылы) тәнендә тузсын!<br>Өстендә тузсын!<br>Өстәүле кием булсын! |
| 1701. Носить на руках. | Кулында гына йөртү.<br>Уч төбендә генә йөртү.<br>Өрмәгән җиргә дә утыртмау.<br>Җил-яңгыр тидермәү. |

1702. Нужда беду родит.

Нужа бәла тудыра.
Нужа бәлагә төшерә.

1703. Нужда в закройщики ставит.

Башыңа төшкәч (төшсә), башмакчы булырсың.

1704. Нужда научит богу молиться.

к. 1703.

1705. Нужда научит горшки обжигать.

к. 1703.

1706. Нужда научит кузнеца сапоги тачать.

к. 1703,

1707. Нужда научит как калачи есть.

к. 655.

1708. Нужда пьёт и из поганой лужи.

к. 655.

1709. Нужды не увидишь, и в добре не походишь.

Авырлык күрми, яхшының кадерен белеп булмый.
Начарны күрми, яхшыны танымыйсың (к. 1557).

## О

1710. О двух головах.

Башы икедер моның.

1711. Обвести (обвертеть) вокруг пальца.

Агач атка атландыру.
Бозга атландыру.
Казык башына утырту.
Карама көленә утырту.
Коры елгага батыру.
Кәкре каенга терәтеп калдыру.
Сабын суына утырту.
Саламга сөяү.
Тавык кетәгенә кертү.
Төп башына утырту.
Төпсез коега төшерү.
Төпсез көймәгә утырту.
Төпсез чанага утырту.
Төпсез чуманга утырту.
Чабатага утырту.
Юкә агачка атландыру`

1712. Обдать презрением. — Нәфрәтле караш ташлау.

1713. Обед брюха не ищет. — к. 2650.

1714. Обеими руками подписаться. — Дүрт куллап риза булу.

1715. Обещанное три года ждут. — Куянга койрык вәгъдә иткәннәр дә, ул әле дә койрыксыз ди.

1716. Обжёгшись на молоке, и на воду дуешь. — Бер авызы пешкән салкын суны да өреп эчкән.

Бер авызың пешкәч, өреп кабарсың.

1717. Обивать пороги. — Бусагасын төшерү (күп йөреп борчу мәгънәсендә).

1718. Облечь славой. — Данга күмү.

1719. Облечь тайной. — Сер итү.

1720. Облизывать губы. — Авыз сулары килү.

1721. Облить грязью. — к. 791.

1722. Оборотная сторона медали. — Медальнең икенче ягы.

1723. Обратить своих сторонников. — Үз ягына аудару.

1724. Обратить в шутку. — Уен-көлкегә әйләндерү.

1725. Обратиться в слух. — Йотылып (онытылып) тыңлау.

1726. Обуть (переобуть) молодца из сапогов в лапти. — Аттан индереп, җәяүлегә калдыру.

Аттан төшереп, ишәккә мендерү.

Аттан төшереп тайга, тайдан — таякка атландыру.

1727. Обуть Филю в чёртовы лапти. — Кыл чабата киендерү (к. 1711).

1728. Овладела радость. — Шатлык басты.

1729. Овладеть собою. — Үз-үзен кулга алу.

1730. Овчинка выделки не стоит. — к. 912.

1731. Огня взаймы не выпросишь. — Аннан әйбер алганчы, тавыктан сөт саварсың.

Җан биргәндә авызыңа

бер кашык су салмас (к. 847, 2461).

1732. Огонь без дыму, человек без ошибки (без греха) не бывает. — Төтенсез ут булмас, ялгышмый кеше тормас.

1733. Огонь маслом заливать. — к. 1231.

1734. Одет с иголочки. — Киемнәре инәдән-җептән генә чыккан.

1735. Одежда лучше новая, а друг — старый. — Киемнең яңасы, дусның иске яхшы.

1736. Один в поле не воин. — Калын юан булса да, ялгыз агач өй булмас, күпме изге булса да, ялгыз егет би булмас.

Бер тарыдан ботка булмас.

Бер тиредән тун булмас.

Бер кылдан аркан ишеп булмый.

Ялгыз кулдан тау чыкмас.

1737. Один глаз на нас, другой на Арзамас. — Бер күзе якшәмбегә, берсе — чәршәмбегә караган.

1738. Один год десять лет заел. — Бер елда ун еллык картайдым.

1739. Один год век заел. — к. 1738.

1740. Один день год кормит. — Бер көн ел ашата (к. 267).

1741. Один конец. — Барыбер бер үләсе.

1742. Один на один (разговаривать). — Икәүдән-икәү (сөйләшү) (к. 2183).

1743. Один раз обожжёшься, два раза подуешь. — к. 1716.

1744. Один с мёдом и лапоть съел. — Бал (май) белән иске чабата да үтә.

Бал балчык ашатыр.

1745. Один только нос вытянулся. — Борыны гына утырып калган (бик ябыккан мәгънәсендә).

1746. Одна голова не бедна, а и бедна так одна. — Торсам — ашыйм, ятсам — башым.

Унса да — үзе, тунса да — үзе.

1747. Одна головня и в печи гаснет, две и в поле курятся (горят). — Ялгыз башым — җан тынычым. Ялгыз агач янмас.

Ялгыз утын мичтә янмый.

Ялгыз утын янмас, ялгыз куен җылынмас.

Ялгыз агач өй булмас, ялгыз егет би булмас.

1748. Одна головня ни горит, ни гаснет. — к. 1747.

1749. Одна ласточка весны не делает — Бер карлыгач яз ясамый.

Бер карга кыш ясамас.

Бер тамчыдан диңгез булмый.

1750. Одна паршивая овца все стадо портит. — Бер начар сыер бөтен көтүне буйый (пычрата).

1751. Одна рука в меду, другая — в сахаре (в патоке). — Бер кулы майда, бер кулы балда.

1752. Однажды отрежь, а семь раз проверь, чтобы меньше было потерь. — к. 2286.

1753. Одним выстрелом убить двух зайцев. — Бер атуда ике куян.

1754. Одним камнем двух собак разогнал. — к. 1753.

1755. Одним миром мазаны. — к. 353, 355.

1756. Одним словом. — Озын сүзнең кыскасы.

1757. Одним ударом двух мух убить. — к. 1753.

1758. Одним ухом спит, другим слышит. — Йоклаганда да күзе ачык (йокыга сак мәгънәсендә).

1759. Одно „нынче" лучше двух „завтра". — Иртәнге тавыктан бүгенге чеби (йомырка) артык.

1760. Одного поля ягода. — к. 353, 355.

1761. Одного сукна япанча. — к. 353, 355

1762. Одной ногой в могиле (стоит). — Бер аягы җирдә (түрдә), икенчесе — гүрдә.

Бүген өем, иртәгә гүрем (к. 154).

1763. Одной рукой жни, другой сей. — Арышны бер кулың белән җый (ур), икенчесе белән чәч.

| | |
|---|---|
| 1764. Одной шапкой двух накрыл. | к. 1753. |
| 1765. Око видит, да зуб неймёт. | Күз күрә, кул җитми. |
| 1766. Око за око, зуб за зуб. | Ашка — аш, ташка — таш. |
| 1767. Около печи нельзя не греться. | Бал тоткан бармак ялый, май (каймак) тоткан кашык ялый. |
| 1768. Он волоса его не стоит. | к. 201, 1695. |
| 1769. Он звёзд с неба не хватает. | Акылга таман. |
| 1770. Он на этом деле зубы съел. | Азу теш чыккан (ярган) инде.<br>Аның бу эштә теше коелган инде. |
| 1771. Он семь лет всё на одной дудке играет. | Гомер буе бер балык башын чәйни. |
| 1772. Он сказывает на вербе грушу. | Бүрәнә аша бүре куа. |
| 1773. Он человек с головой. | Башлы кеше. |
| 1774. Опустил крылья. | Канаты төшкән.<br>Канатын салган. |
| 1775. Орлы бьются, а молодцам перья достаются. | к. 1117. |
| 1776. Осадок на душе (сердце). | Күңелдә төен (калды). |
| 1777. Осердясь на вшей, да шубу в печь. | Беткә ачу итеп, тунны утка ягу. |
| 1778. Осердясь на блохи, одеяло в печь. | к. 1777. |
| 1779. Оставить с носом. | Коры (буш) калдыру. |
| 1780. Оставить сей мир. | Дөнья кую (к. 1402, 1826, 1863). |
| 1781. Оставить след (на душе). | Күңелдә эз калдыру. |
| 1782. Остаться в дураках. | Юләр (дурак) калу. |
| 1783. Остаться на бобах. | Буш калу. |
| 1784. Острый глаз (у него). | Без күз.<br>Очлы күзле.<br>Үткен күзле. |
| 1785. Острый на язык. | Ачы телле.<br>Шук телле.<br>Үткен телле. |

1786. От бобра — бобрёнок, от свиньи — поросёнок.

Аргамактан ат туа(р), кандаладан бет туа(р).
Каргадан карга туар.

1787. От волка бежал, да на медведя напал.

Төтеннән качып, утка кергән.
Уттан котылып, суга төшкән (к. 930).

1788. От всего (чистого) сердца.

Чын күңелдән (йөрәктән).

1789. От греха подальше.

Бәла-казадан баш-аяк.

1790. От домашнего вора не убережёшься.

Йортындагы карактан саклана алмассың.

1791. От жиру и собака бесится.

Эт симерсә, иясенә ябыша.

1792. От жребия не уйдёшь.

Язмыштан узмыш юк.
Күрәсене күрми, гүргә кереп булмый.

1793. От зари до зари.

Бер караңгыдан икенче караңгыга (хәтле).
Бер таңнан икенче таңга.

1794. От корки до корки (прочитать).

Башыннан ахырына кадәр (укып чыгу).

1795. От мала до велика.

Яше-карты.
Олысы-кечесе.
Аягына басканы, төбенә шуганы — барысы да.

1796. От наших ворот живёт и поворот.

к. 1312.

1797. От него, как от козла, ни шерсти, ни молока.

Аңардан сөт тә юк, йон да юк.
Аңардан ни он, ни йон.

1798. От нечего делать.

Эш юктан эш табып (булсын дип).
Тик торганчы тун итәген уа тор (дигәндәй).

1799. От одного порченого яблока целый воз загнивает.

к. 1750.

1800. От одной матки, да не од и ребятки.

к. 196.

1801. От свиньи не родятся бобрёнки, а всё поросёнки.

к. 1023, 1040.

| | |
|---|---|
| 1802. От смерти нет зелья. | Әҗәлгә дәва (дару) юк. |
| 1803. От страха глаза на лоб полезли. | Куркудан күзләр дүрт (шар) булды. |
| 1804. От того, кто не мил, и подарок постыл. | Сөймәснеке сыймас. |
| 1805. От хлеба-соли не отказываются. | Аштан зур түгелсең. |
| 1806. От хорошего братца ума набраться, от худого братца рад отвязаться. | ≅ Боланга ияргән чәчәктә аунар, дуңгызга ияргән пычракта аунар.<br>Яхшыга ияргән ялпайган,<br>яманга ияргән картайган.<br>к. 478. |
| 1807. От худой птицы и худые вести. | |
| 1808. От яблони — яблочко, от сосны (ели) — шишки. | Алып анадан туар, аргамак биядән туар.<br>Алмагачта алма үсә, тигәнәктә — тигәнәк (к. 1023, 1036, 1040). |
| 1809. Отбиваться (*от чего-нибудь*) и руками и ногами. | Теше-тырнагы белән каршы тору.<br>Кулы-аягы белән каршы тору. |
| 1810. Отбиться от рук. | Кулдан ычкыну.<br>Юлдан язу. |
| 1811. Отвести глаза (*кому-нибудь*). | Күз буяу. |
| 1812. Отвести душу. | Эчне бушату. |
| 1813. Отдай руками, а не выходишь и ногами. | Кулың белән биргәнне аягың белән йөреп тә ала алмассың. |
| 1814. Отдать богу душу. | Җан бирү (үлү мәгънәсендә). |
| 1815. Отдать должное. | Тиешле бәясен бирү.<br>Тиярен бирү. |
| 1816. Отдаться с головой. | Башы-аягы белән кереп чуму. |
| 1817. Отдашь деньги руками, а ходишь за ними ногами. | Кулың белән биргәнне аягың белән йөреп алырсың. |
| 1818. Отдашь руками, ходи ногами. | к. 1817. |
| 1819. Открыть глаза. | Күзен ачу (дөреслекне күрсәтү мәгънәсендә). |

| | |
|---|---|
| 1820. Откуда ни возмись. | Уйламаганда-көтмәгәндә. |
| 1821. Отлегло от сердца (от души). | Күңел бераз тынычланды.<br>Күңел тынычланып калды. |
| 1822. Отлить пулю. | к. 1232. |
| 1823. Отодрать за уши. | Колагын бору. |
| 1824. Отольются кошке мышкины слёзы. | Күз яшьләре тотар эле (каргышы төшәр). |
| 1825. Отплатить той же монетой. | Бермә-бер кайтару (к. 1766). |
| 1826. Отправиться на тот свет. | Теге дөньяга киту (к. 952, 1402, 1780, 1863). |
| 1827. Отпустить вожжи. | Дилбегәне бушату (ычкындыру). |
| 1828. Отрезанный ломоть к хлебу не приставишь. | Бер кискән икмәк кире ябышмый. |
| 1829. Отрезанную краюху не прилепишь. | к. 1828. |
| 1830. Отсеки собаке хвост— не будет овца. | Этнең койрыгын киссәң дә куй булмас.<br>Койрыгын кисеп, эттән куян ясап булмый. |
| 1831. Отсохни язык! | Телем корысын! |
| 1832. Отсутствие всякого присутствия. | Акыл өләшкәндә йоклап калган.<br>Акыл өләшкәндә идән астында калган.<br>Акыл үзенә кереп тә чыкмаган. |
| 1833. Оттрепать за уши. | к. 1823. |
| 1834. Охота пуще неволи. | Җаны теләгән елан ите ашаган. |
| 1835. Очей не сводить. | к. 451. |
| 1836. Очертя голову. | Баш ватып, күз чыгарып.<br>Уңны-сулны карамый. |

## П

| | |
|---|---|
| 1837. Палец о палец не ударять. | Аркылы ятканны буйга алып куймау (салмау) (к. 1845). |

1838. Палка в колесе. — Аякка тагылган таш.

1839. Палка о двух концах. — Таяк ике башлы була.

1840. Палка о двух концах: и туда, и сюда. — к. 1839.

1841. Палки — в колёса, полено — под ноги. — к. 367.

1842. Пальчики оближешь. — к. 2815.

1843. Пальцем не ворохнуть. — к. 1837, 1845.

1844. Пальцем не дотронуться (не тронуть). — Бармак белән дә чиертмәү (к. 326).

1845. Пальцем не шевельнуть. — Бармак башы да кыймылдатмау.

Кыл да кыймылдатмау.

Кыл башы кыймылдатмау.

1846. Пан или пропал. — к. 1221.

1847. Пар костей не ломит. — Җылы сөяк сындырмый.

Җылы сөяк сындырмый,
суык җанны тындырмый.

1848. Пеняй на себя! — Үзеңә үпкәлә!

1849. Первая ласточка. — Беренче карлыгач (беренче хәбәр мәгънәсендә).

1850. Первому гостю первое место и красная ложка. — ≅ Алдан килгән урын өчен, соңыннан килгән тамак өчен.

1851. Первый блин комом. — Беренче коймак төерле була.

1852. Перевернётся в гробу. — Кабереңдә әйләнер.

1853. Перевернуть вверх дном. — Астын өскә китерү.

1854. Перед сильным — зайцы, перед слабым — слоны. — к. 1323.

1855. Перед смертью все равны. — Үлем каршында һәркем дә тигез.

Үлем байдан алу алмый,
ярлының күнелен күрми.
Үлем начардан җирәнми,
яхшыны җәлләми (к. 2378).

1856. Перед смертью не надышишься. — Ашап туймаганны, ялап туймассың.

1857. Перекидываться словами. — Сүз алышу.

| | |
|---|---|
| 1858. Переливать из пустого в порожнее. | Юкны бушка аудару.<br>Юкны бушка төяү.<br>Юкны бушка тутыру.<br>Унны тугызга әйләндереп йөрү. |
| 1859. Перемелется — будет мука. | Тарта торгач он булыр. |
| 1860. Переминаться с ноги на ногу. | Аяк өстендә таптану (таптанып тору). |
| 1861. Перемывать косточки. | Гайбәтен сату. |
| 1862. Переполнить чашу терпения. | Түземлек төкәнү. |
| 1863. Переселиться в вечность. | Фани дөньядан китү (к. 1402, 1780, 1826). |
| 1864. Перехватить дыхание. | Тын кысылу. |
| 1865. Пироги да блины, а там сиди да гляди. | к. 1070. |
| 1866. Писаная красавица. | Коеп куйган картинка. |
| 1867. Пить вино вместе, а хлеб-соль пополам. | Бары бергә, югы уртак. |
| 1868. Платить той же монетой. | к. 1766, 1825. |
| 1869. Плачем горю не пособить. | Елап эш чыкмый.<br>Елап ни файда! |
| 1870. Плачем горю не пособить, оханьем поля не переедешь. | к. 1869. |
| 1871. Плевать в потолок. | Түшәмгә төкереп яту. |
| 1872. Плестись в хвосте. | Койрыкта сөйрәлү. |
| 1873. Плетёт кошели с лаптями. | Бүрәнә аша бүре куа (күрә).<br>Артыннан тере саескан очыра. |
| 1874. Плетью обуха не перешибёшь. | Чыбыркы белән балта түтәсен сындыра алмассын.<br>Күсәккә чыбыркы белән каршы торып булмый. |
| 1875. Плохо — у одной овечки, да семь пастухов. | к. 2602. |
| 1876. Плохое дерево в сук идёт. | Начар агач ботакка үсәр. |



Ахмет Байтұрсынұлы атындағы ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

| | |
|---|---|
| 1877. Плясать под чужую дудку. | Кеше кубызына бию. |
| 1878. По барину — говядина, по харчевне — едок. | Ашына күрә катыгы, кешесенә күрә кашыгы. |
| 1879. По боярыне и баранина. | к. 1878. |
| 1880. По головке не погладят. | Башыңнан сыйпамаслар.<br>Арканнан сыйпамаслар. |
| 1881. По горшку и покрышка. | Чиләгенә күрә капкачы. |
| 1882. По горячим (свежим) следам. | Эзе суынганчы. |
| 1883. По гостям гуляй, да и сам ворота открывай. | Кеше үрдәген ашаганда үз казыңның ботын тот (к. 1262). |
| 1884. По губам намазать. | Ымсындырып калдыру. |
| 1885. По зёрнышку — ворох, по капельке — море. | к. 928. |
| 1886. По Ивашке и рубашка. | к. 1881. |
| 1887. По капельке — море, по былинке — стог, по зёрнышку — ворох. | к. 928. |
| 1888. По карману бить. | Кесәгә сугу. |
| 1889. По коже — шило, по жизни — рыло. | к. 1878. |
| 1890. По косточкам разобрать. | Җиде бабасына җитеп тикшерү (к. 1897). |
| 1891. По которой реке плыть, той и песенки петь. | к. 239. |
| 1892. По которой речке плыть, ту и воду пить. | к. 239. |
| 1893. По которой речке плыть, той славушку творить. | к. 239. |
| 1894. По мере сил. | Кулдан килгәнчә.<br>Хәлдән килгәнчә. |
| 1895. По мне хоть трава не расти. | к. 3. |
| 1896. По нитке дойдёшь до клубка. | Җепнең очы барыбер табыла.<br>Бара-тора җепнең очы табыла. |

1897. По нитке разобрать. — Энәсеннән җебенә чаклы тикшерү (к. 1890).

1898. По нужде поп ест и боб. — к. 655, 1703.

1899. По одёжке протягивай ножки. — Түшәгенә карап аягың суз.
Юрганына карап аягың суз.
Күләгәнә карап күчергеч ал.
Күленә карап чүмарсын.

1900. По пальцам перечесть. — Бармак белән санарлык.

1901. По платью (одежде) встречают, по уму провожают. — Киеменә карап каршы алалар, акылына карап озаталар.

1902. По правде сказать. — Дөресен (генә) әйткәндә.

1903. По работе и мастера знать. — к. 378.

1904. По работе и плата. — Эшенә күрә ашы (әҗере).

1905. По разговорам—всюду, а по делам — никуда. — к. 1397.

1906. По рукам хлопать. — Кул сугышу (килешү мәгънәсендә).

1907. По себе знаю. — Үземә күрә беләм.

1908. По Сеньке и шапка. — Кешесенә күрә киеме (к. 1881).

1909. По Сеньке — шапка, по Ерёмке — кафтан. — к. 1881.

1910. По сердцу (быть). — Күңелгә ошау.

1911. По силе возможности. — Көч житкән кадәрле.
Мөмкин (булган) чаклы (к. 1894).

1912. По усам текло, в рот не попало. — Күз күрде, кулга тимәде.

1913. По уши в долгах. — Муеннан бурычта.
Муеннан бурычка баты(м).

1914. По чужой шкуре не больно. — Кеше колагын борганда үзеңеке авыртмый.
Кеше колагы — киез,
кисеп алырга бик тиз;

үз колагың — яфрак,
кисеп алырга катырак.

1915. По чьей воде плыть, того и волю творить. — к. 239.

1916. По шерсти собачке и кличка дана. — Исеме җисеменә туры килгән.

1917. Повадился кувшин по воду ходить, там ему и голову сломить. — Май чүлмәге майда ватыла.

1918. Повар и духом сыт бывает. — Пешерүче ашның исе белән дә туя.

1919. Повернуть оглобли. — Тәртәләрне бору (китәргә җыену мәгънәсендә).

1920. Повинную голову меч не сечёт. — Иелгән башны кылыч кисми.
Баш орган башны кылыч чапмас.

1921. Поводья затянуть. — Дилбегәне тарта төшү.

1921а. Погибнуть ни за что. — к. 2088.

1922. Погнался за краюхой, да без ломтя остался. — Күпне өмет итеп, аздан коры калган.

1923. Погоди, ты у меня попляшешь! — Мин сине биетермен әле!

1924. Погоняй лошадь не кнутом, а овсом. — Атны чыбыркы белән кума, солы белән ку.

1925. Погрузиться в вечный сон. — Мәңгелек йокыга талу (үлү мәгънәсендә).

1926. Погубить ни за что. — Бер дә юкка әрәм итү (һәлак итү).

1927. Под глазами фонари. — Күз төпләренә зәңгәр күләгә эленгән.
Күз төпләре кара көйгән.

1928. Под гору итти (*перен.*) — Тау астына таба тәгәрәү (эшләрнең кире китүе турында).
Тауга түбән тәгәрәү.

1929. Под лежачий камень и вода не течёт. — Яткан таш мүкләнә, йөргән таш шомара (к. 1200).

1930. Под лесом видит, а под носом нет. — к. 236.

1931. Под ногами вертеться. — Аяк астында буталып йөрү.
Аяк арасында чуалу.

| | |
|---|---|
| 1932. Под носом только. | Борын төбендә генә (бик якын дигән мәгънәдә). |
| 1933. Под счастливой звездой родился. | Хәерле (бәхетле) сәгатьтә туган. |
| 1934. Под силу (быть). | Көч житәрлек (булу). |
| 1935. Под утро. | Таң алдыннан. |
| 1936. Под чужую дудку плясать. | Кеше кубызына бию. |
| 1937. Под шумок. | Шау-шу арасында (сиздермичә генә). |
| 1938. Подать руку помощи. | Ярдәм кулын сузу. |
| 1939. Поддаться соблазну. | Котырыгына бирелү (ияру). |
| 1940. Поджать *(кому)* хвост. | Койрыгын бору.<br>Койрыгын кысу. |
| 1941. Подкладывать дров на огонь. | к. 1231. |
| 1942. Подле пчёлки — в медок, подле жука — в навоз. | к. 1806. |
| 1943. Подлить масла в огонь. | к. 1231. |
| 1944. Поднесли — так пей, дали — так ешь. | Биргәндә аша, куганда кит. |
| 1945. Поднявший меч от меча и погибнет. | Кылыч белән кергән кылычтан үләр (*М. Җәлил*). |
| 1946. Поднять дух. | Рухны күтәрү (к. 1949). |
| 1947. Поднять на зубок. | к. 1948. |
| 1948. Поднять насмех. | Көлкегә калдыру. |
| 1949. Поднять настроение. | Күңелне күтәреп җибәрү.<br>Күңелне очындыру.<br>Күңелне җилкендерү.<br>Күңелне канатландыру. |
| 1950. Поднять голос. | Тавышны күтәрү. |
| 1951. Поднять шум. | Тавыш (гауга) күтәрү.<br>Тавыш чыгару. |
| 1952. Подобру-поздорову. | Исән-сау чакта!<br>Яхшы чакта. |
| 1953. Подпрыгнуть до потолка (от радости). | Түбәсе күккә (түшәмгә) тию, |
| 1954. Подрезать сук, на котором сидишь. | к. 2155. |
| 1955. Подставить ногу. | Аяк чалу. |

| | |
|---|---|
| 1956. Подстрелянного сокола и ворона носом долбит. | Егылганны тукмаклыйлар (тукмыйлар). |
| 1957. Поезжай хоть куда: везде доля худа (*старин.*). | Кара сакалың кая барсаң да артыңнан калмас (*искер*). |
| 1958. Пожалеешь лычка, не увяжешь и ремешком. | к. 1281. |
| 1959. Пожалеешь лычка, отдашь ремешок. | к. 1281. |
| 1960. Поздно беречь вино, когда бочка пуста. | Атны урлаткач, абзарны бикләмиләр. |
| 1961. Поймать (поддеть) на удочку. | Кармакка каптыру (алдау мәгънәсендә). |
| 1962. Пока след не простыл. | к. 1882. |
| 1963. Пока суд, да дело. | Ул-бу булганчы. |
| 1964. Покажу, где раки зимуют. | Күрмәгәнен күрсәтермен! Арт сабагыңны укытырмын! Утлы табага бастырырмын! |
| 1965. Покажу Кузькину мать. | к. 1964. |
| 1966. Показать пятки. | к. 569. |
| 1967. Показался как молодой месяц. | Ай күрде, кояш алды. |
| 1968. Покатиться со смеху. | Эч катып көлү. |
| 1969. Покой пьёт воду, а беспокойство — мёд. | Тик тормасаң, тук булырсың. |
| 1970. Покорить сердце. | Күңелне баглау. Үзенә карату. |
| 1971. Покорное слово гнев укрощает. | Яхшы сүзгә җан эри. |
| 1972. Покраснеть до ушей. | Колакларына хәтле кызару. |
| 1973. Поленья под ноги бросать. | Аркылы төшү. Аяк чалу. |
| 1974. Положи далёко, возьмёшь близко. | к. 563. |
| 1975. Положить конец. | Чик кую. |
| 1976. Полымя не без дыма. | к. 436. |
| 1977. Поменьше говори, побольше услышишь. | Азрак сөйләсәң, күбрәк ишетерсең. |

| | |
|---|---|
| 1978. Поминай, как звали! | Җилләр искән! |
| 1979. Поминать добром. | Яхшылык белән искә алу. |
| 1980. Понапрасну жгут масло и даром теряют время. | Юкка чабата туздырып, гомер уздырып йөриләр. |
| 1981. Понюхать не дать. | Күзгә кырып салырга да бирмәү.<br>Тешкә эретеп салырга да бирмәү. |
| 1982. Поп ждёт покойника богатого, а судья тягуна тороватого. | ≅ Хайван үлсә, карга шат; адәм үлсә, мулла шат. |
| 1983. Поп со всего возьмёт, а с попа ничего не возьмёшь. | ≅ Мулланың ашын, еланның аягын күрмәссең. |
| 1984. Попа и в рогожке узнаёшь. | Май чүлмәге тышыннан билгеле. |
| 1985. Попал в стаю — лай не лай, а хвостом виляй. | к. 2180. |
| 1986. Попасть в *(чью-нибудь)* лапу. | Тырнагына эләгү. |
| 1987. Попасть в *(чьи-нибудь)* ловушку. | Хәйлә тозагына эләгү (к. 1988). |
| 1988. Попасть в *(чьи-нибудь)* сети. | Тозакка эләгү. |
| 1989. Попасть впросак. | Ике такта арасында калу.<br>Уңайсыз хәлдә калу. |
| 1990. Попасть на зубок. | Телгә-тешкә керү. |
| 1991. Попасть пальцем в небо. | Дуга белән печән чабу. |
| 1992. Попасть (про) меж двух огней. | к. 1294. |
| 1993. Попасться на глаза. | Күзгә чалыну.<br>Күзгә юлыгу. |
| 1994. Попасться на удочку. | Кармакка эләгү (алдану мәгънәсендә). |
| 1995. Поперёк горла стать. | Бугазына аркылы килү. |
| 1996. Поперёк горла стоять. | Бугазда аркылы тору.<br>Бугазда төен булып тору. |
| 1997. Поплатиться головою. | Баш белән түләү. |
| 1998. Поповские руки загребущие, глаза завидущие, | ≅ Мулла бир дигәнне яратмый, мә дигәнне генә ярата, |

1999. Поповское брюхо из семи овчин сшито. ≅ Мулла корсагы тугыз бозау тиресеннән тегелгән.

2000. Поправляться из кулька в рогожку. Каш төзәтәм (ясыйм) дип күз чыгару.

2001. Попытка — не пытка. Ятып калганчы, атып кал.

2002. Пороги обивать. Бусагасын төшерү (күп йөреп).

2003. Портной без порток, сапожник без сапог. к. 2231.

2004. Посади свинью за стол, она и ноги на стол. ≅ Ишәк түшәк кадерен белмәс.

2005. Посадить в галоши. Галошка утырту (к. 1711).

2006. Посла ни секут, ни рубят, только милуют. Илчегә үлем юк.

2007. После дождичка в четверг. к. 1072.

2008. После дела за советом не ходят. к. 1960, 2009, 2013.

2009. После драки кулаками не машут. Пожардан (янгыннан) соң насос (су) кирәкми (к. 1960, 2013).

2010. После нас хоть потоп. Дөньясын ник су басмый!
Ник шунда дөньясы астыөскә килми (к. 3, 1895).
Дөньяны су басса үрдәккә ни кайгы?!

2011. После пожара да за водой. Пожардан соң насос.

2012. После поры не точат топоры. к. 1960, 2009, 2011.

2013. После смерти нет покаяния. Үлгәннән соң тәүбә юк.

2014. После ужина горчица. к. 2011.

2015. Последний человек (о плохом человеке). Адәм актыгы.

2016. Последними словами срамить (ругать). Дөньядагы белән хурлау (әшәке сүзләр белән хурлау мәгънәсендә).

| | |
|---|---|
| 2017. Последняя (пятая) спица в колеснице. | Арбаның бишенче көпчәге (берәр төрле эштә бик кечкенә роль уйнаган кеше турында). |
| 2018. Посмотрим, — сказал слепой, услышим, — сказал глухой. | ≌ Сукыр күп күрер, аксак күп йөрер.<br>Чукрак күп ишетер, аксак күп йөгер.<br>Сакау күп сөйләр. |
| 2019. Пособить горю. | Бәладән коткару. |
| 2020. Поспешишь — людей насмешишь. | Ашыккан ашка баткан. |
| 2021. Поспешность потребна только блох ловить. | Ашыгу борча тотканда гына ярый. |
| 2022. Поставить на голосование. | Тавышка кую. |
| 2023. Поставить на одну доску. | Бер тактага кую.<br>Бер рәткә кую. |
| 2024. Поступить по совести. | Вөждан кушканча эш итү. |
| 2025. Пот льётся градом. | Шабыр тиргә батты(м).<br>Борчак-борчак тир ага. |
| 2026. Потемнеть в глазах. | Күз аллары караңгыланып китү. |
| 2027. Потерпеть неудачу. | Уңышсызлыкка очрау (дучар булу). |
| 2028. Потерять (подорвать) авторитет. | Авторитеты төшү.<br>Абруе түгелү.<br>Базары төшү.<br>Күздән төшү. |
| 2029. Потерять интерес *(к чему-либо)*. | Күңел суыну.<br>Кызыгы бетү.<br>Кызыгы китү. |
| 2030. Потерять надежду. | Өметне өзү.<br>Өмет өзелү. |
| 2031. Потерять сознание. | Аңны югалту.<br>Истән аву.<br>Һуштан язу. |
| 2032. Потом лица. | Маңгай тирен түгеп, |

АХМЕТ БАЙТҰРСЫНҰЛЫ
ТІЛ БІЛІМІ
ИНСТИТУТЫ

Маңгай тирен чыгарып
Маңгай тире белән.

2033. Почву подготовить. — Җирлек хәзерләү.

2034. Почём купил, потом и продаю. — Кеше сүзен генә әйтәм.
Күргәнне түгел, ишеткәнне әйтәм.
Минем сүзем түгел, кеше сүзе.

2035. Почём (по чём) купили, по тому и продали: барыша не берём. — к. 2034.

2036. Пошёл на обед, неси словцо на ответ. — к. 1262, 1883.

2037. Пошёл по шерсть, а воротился стриженый. — Йолкырга дип барды, йолкынып кайтты.
Өтәргә дип барды, өтелеп кайтты.

2038. Пошла изба по горнице, сени по полатям. — (Өйнең) асты-өскә килде.

2039. Пошла по масло, а в печи погасло. — Йомышка барган җирендә куньп кайткан.

2040. Появился метеором, метеором и пропал. — к. 1967.

2041. Правая рука. — Уң кулы (таянычы, ярдәмчесе мәгънәсендә).

2042. Правда в воде не тонет, в огне не горит. — Дөреслек утта янмый, суда батмый.

2043. Правда всегда берёт верх. — Дөреслек һәрвакыт өстенлек ала (җинә).
Дөреслек (хаклык) җирдә ятмый.

2044. Правда глаза колет. — Тугрылык күзне төртә.
Тугры (хак) сүз ачы булыр.

2045. Правда из воды да из огня спасает. — Дөреслек уттан-судан коткара.

2046. Правду говорить — никому не угодить. — к. 483.

2047. Правду говорить — себе досадить. — к. 483.

| | |
|---|---|
| 2048. Правота — что лихота: всегда наружу выйдет. | Дөреслек һәрвакыт өстен чыга. |
| 2049. Прежде отца в петлю не суйся. | Атаннан элек капкынга төшмә (тыйнаклык турында). |
| 2050. Прежде смерти не умрёшь. | Тәкъдирсез үлмиләр.<br>Әҗәл җитмичә үлмиләр. |
| 2051. При пиве, при бражке много братьев. | к. 299. |
| 2052. При сытости помни голод, а при богатстве — убожество. | Ачта булган калҗаңны тукта булгач онытма. |
| 2053. При царе Горохе. | к. 300 |
| 2054. При этом. | Өстәвенә тагын.<br>Шуның белән бергә. |
| 2055. Привычка не отопок: с ноги не скинешь. | Гадәт китмәс, чир китәр. |
| 2056. Привычка — не рукавичка, не повесишь на спичку. | к. 2055. |
| 2057. Пригонит нужда к поганой луже. | к. 655. |
| 2058. Приелось толокно, в горле першит. | к. 1345. |
| 2059. Прижать (припереть) к стене. | Стенага терәү. |
| 2060. Прижать хвост. | Койрыгына басу.<br>Койрыгын бору (кысу). |
| 2061. Призывать в свидетели небо и землю. | Җире-күге белән каргану (ант иту). |
| 2062. Прийти в себя. | Аңга килү.<br>Искә килү.<br>Һушка килү. |
| 2063. Прийти в сознание. | к. 2062 |
| 2064. Прийти в ярость. | Җен ачуы чыгу. |
| 2065. Прийтись не ко двору. | Төс бирмәү.<br>Төс булмау. |
| 2066. Прикусить язык. | Телне тешләү (сөйләмәү, сөйләвеннән туктау мәгънәсендә). |
| 2067. Примириться с судьбой. | Язмышка баш ию. |
| 2068. Принимать за чистую монету. | Чынга алу.<br>Чынга тарту. |

ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

| | |
|---|---|
| 2069. Пристал как банный лист к телу. | Сагыз булды.<br>Теш корты булды.<br>Нарат чәере булды. |
| 2070. Пристать с ножом к горлу. | Бугазга (пычак белән) ябышу.<br>Бугаздан алу. |
| 2071. Притянуть за волосы (об объяснениях, доказательствах). | Колагыннан тартып китерү (аңлатмалар, дәлилләр турында). |
| 2072. Пришёл незван, поди же негнан. | Чакырмый килгән кунакка рөхсәтсез китәргә ярый. |
| 2073. Приятного аппетита! | Ашың (чәең) тәмле булсын! |
| 2074. Про мир пирога не испечёшь, на мир вина не напасёшься. | к. 1388. |
| 2075. Проглотить горькую пилюлю. | Авыр (ачы) сүз күтәрү. |
| 2076. Продажная душа. | Сатлык җан.<br>Күзгә карап җан сатучы. |
| 2077. Продаю за что купил. | к. 2034. |
| 2078. Прожитое, что пролитое,— не воротишь. | Үткән (узган) гомер—аккан су: кире кайтмый.<br>Узган болытны тотып булмый. |
| 2079. Пройти молчанием. | Эндәшми калу (игътибарсыз калдыру). |
| 2080. Пролениться — и хлеба лишиться. | Эшләргә иренгән, ашарга көрсенгән (тилмергән). |
| 2081. Пролитое полно не живёт. | Түгелгән тулы булмас. |
| 2082. Променял синицу в руках на журавля в небесах. | Күктәге торнага ышанып (алданып) кулындагы кошын очырган. |
| 2083. Пролить кровь. | Кан кою. |
| 2084. Променять кукушку на ястреба. | Каеш биреп юкә алу. |
| 2085. Промокнуть до (последней) нитки. | Җеп бөртеге дә калмый чылану.<br>Җеп бөртегө калмау. |
| 2086. Промокнуть на сквозь. | Манма су булу (к. 2085). |
| 2087. Промочить горло. | Тамак чылату (җебетү). |
| 2088. Пропасть ни за грош. | Юкка әрәм булу. |

Юк кына нәрсә өчен башны югалту.

2089. Пропустить мимо ушей. — Колак янынннан гына уздыру. Ишеткәннәрне ияк кагу белән уздыру. (Сүзләрне) колак арттан җибәрү.

2090. Простота хуже воровства. — ≅Йомшак агачны корт баса. Җылыга елан иялəшә.

2091. Против воды тяжело плыть. — Агымга каршы йөзүе читен.

2092. Против шерсти не гладят. — Йон ыспаена сыпыралар.

2093. Протянуть ноги. — Аяк сузу (үлү мәгънәсендә).

2094. Протянуть руку дружбы (помощи). — Дуслык (ярдәм) кулын сузу.

2095. Процедить сквозь зубы. — Теш арасыннан гына әйтү.

2096. Прошёл огни и воды. — Утны-суны кичкән кеше.

2097. Прошёл огни и воды и медные трубы. — к. 285, 2096.

2098. Прямо говорить (сказать). — Күзгә бәреп әйтү. Күзгә карап әйтү.

2099. Пуганая ворона куста боится. — к. 2605.

2100. Пускать мыльные пузыри. — Сабын күбеге очыру. Куык очырту. Буш куыклану.

2101. Пустая бочка пуще гремит. — Кысыр тавык озак кытаклый. Күкәй салмас тавык көн элгәре кытаклый.

2102. Пустить корни. — Тамыр җәю.

2103. Пустить красного петуха. — Кызыл әтәч җибәрү.

2104. Пустить по миру. — Хәерчелеккә калдыру.

2105. Пустить пыль в глаза. — Күзгә көл сибү. Күз буяу. Күзгә төтен җибәрү (к. 2100).

| | |
|---|---|
| 2106. Пуститься на хитрость. | Хәйләгә керешү. |
| 2107. Пустой колос выше стоит. | Буш башак иелмәс.<br>Буш башакның башы иелми (югары). |
| 2108. Пустой колос голову держит высоко. | к. 2107. |
| 2109. (Пусть) одна нога там, другая — здесь. | Бер аягың анда, бер аягың монда булсын.<br>Аягың җиргә дә тимәсен. |
| 2110. Пусть это останется между нами. | к. 1295. |
| 2111. Пьяному море по колено, а лужа по уши. | Исереккә диңгез тубыктан. |
| 2112. Пьяный, что малый: что на уме, то и на языке. | к. 2600. |
| 2113. Пятки (только) засверкали. | Табаннары гына ялтырады. |
| 2114. Пять перстов, а все одна рука. | к. 1114. |
| 2115. Работа — не волк, в лес не убежит. | Эш бүре түгел, урманга качмас. |
| 2116. Работа спорится. | Эш алга бара.<br>Эш гөрли. |
| 2117. Работа до поту, так поешь в охоту. | Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.<br>Аша туйганчы, эшлә тирләгәнче. |
| 2118. Рад бы сердцем, да живот что лыко. | Дәрт бар, дәрман юк. |
| 2119. Рад гостям за чужим столом. | Кешенеке белән юмартлану.<br>Үзем тапкан мал түгел, этинеке жәл түгел. |
| 2120. Рад не рад. | Теләсәң-теләмәсәң дә. |
| 2121. Радость бушует. | Шатлык ташый. |
| 2122. Раз на раз не приходится. | Чама чамага туры килми. |
| 2123. Раз солгал — навек лгуном стал. | Бер ялганласаң, гомер буе ышанмаслар. |
| 2124. Разбить на голову. | Тар-мар итү. |
| 2125. Разбиться вдребезги. | Челпәрәмә килеп ватылу. |

| | |
|---|---|
| 2126. Развести пустые разговоры. | Сүз боткасы куерту. |
| 2127. Развязать язык. | Тел чишелү.<br>Тел ачылу. |
| 2128. Разговаривать свысока. | Үзен түбә җирдәрәк тотып сөйләшү. |
| 2129. Разлететься в пух и в прах. | Көле күккә очу.<br>Пыр килү.<br>Пыр тузу. |
| 2130. Разнести в пух и прах. | Көлен күккә очыру.<br>Пыр китерү.<br>Пыр туздыру.<br>Тар-мар итү.<br>Тетмәсен тетү. |
| 2131. Разорваться нельзя (невозможно). | Кырыкка ярылып булмый. |
| 2132. Разыгрывать комедию. | к. 1244. |
| 2133. Раненный мечом вылечится, раненный словом — никогда. | Кул ярасы китсә дә, тел ярасы китми. |
| 2134. Ранние ласточки к счастливому году. | ≅ Тургайлар иртә килсә, туклык (бай ел) була. |
| 2135. Ранняя птичка носок прочищает, а поздняя — глаз протирает. | Иртә торсаң — ит пешә, соңга калсаң — бит пешә.<br>Иртә торган (карга) тешен казый, соң торган күзен казый. |
| 2136. Рано вставши, много наработаешь: рано женившись, скорее помощь будет. | ≅ Иртә өйләнгән улыннан-кызыннан кинәнгән. |
| 2137. Рано пташечка запела, как бы кошечка не съела. | Иртә кычкырган күкенең (әтәчнең) башы ярыла (авырта, таз була). |
| 2138. Раскидываться умом. | Акыл сату. |
| 2139. Расшибиться в лепёшку (готов). | Үлсәм үләрмен, аның теләген үтәрмен. |
| 2140. Рвёт на себе волосы. | Чәчләрен йолка. |
| 2141. Редкое свидание—приятный гость. | Сирәк килсәң (барсаң), сөйкемле булырсың. |

2142. Ремесло за плечами не виснет.
к. 2144.

2143. Ремесло—золотой кормилец.
Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс.

2144. Ремесло — не коромысло, плеч не оттянет.
Һөнәр тамагына сорамый, кулга ябышып йөрми.

2145. Речист, да на руку нечист.
к. 1389.

2146. Речь красна слушанием.
Сүз тыңлаучысы белән.

2147. Риск — благо р о д н о е дело.
к. 1162.

2148. Ровно ветром сдуло!
Юып алгандай (булды)!

2149. Родится роток, родится и кусок.
Бала (бәндә) үз ризыгы белән туа.

2150. Родиться в сорочке.
Бәхет йөзлеге белән туу.

2151. Рожь говорит: сей меня в золу да в пору, а овёс говорит: топчи меня в грязь— я буду князь.
к. 2279.

2152. Рот до ушей.
Авызы колагына җиткән (шатланган мәгънәсендә).

2153. Рот не огород, не затворишь ворот.
к. 1358.

2154. Руби дерево по себе.
≅ Күләгәңә карап күчергеч ал (үз ишеңне тап дигән мәгънәдә).

2155. Рубить сук, на котором сидишь.
Үзең утырган ботакка балта чабу.
Үзең утырган ботакны кисү.
Үзең утырган каенны кисү.

2156. Рубль есть и ум есть; нет рубля — нет и ума.
Акчам бетсә, акылым бетә.
Акчам да юк, акылым да юк.

2157. Ругаться на чём свет стоит.
Дөньядагы белән сүгенү.

2158. Рука играет.
Кулы уйный.
Бармагы уйный (астыртын эш йөртә дигән мәгънәдә).

| | |
|---|---|
| 2159. Рука не поднимается. | Кул күтәрелми (бармый). |
| 2160. Рука об руку идти. | Кулга кул тотынышып бару. |
| 2161. Рука руку моет. | Кул кулны юа. |
| 2162. Рука руку моет, а обе вместе моют лицо. | Кул кулны юа, ике кул битне юа. |
| 2163. Рука руку моет, вор вора кроет. | к. 2162. |
| 2164. Рука руку моет, и обе белы живут. | к. 2162. |
| 2165. Рукам воли не давай. | Кулыңа ирек бирмә.<br>Кулыңны озайтма. |
| 2166. Руками и ногами упираться. | Теше-тырнагы белән каршы тору. |
| 2167. Руки за ложкой не протянешь, так не придёт сама. | к. 2650. |
| 2168. Руки марать. | Кул буяу (пычрату). |
| 2169. Руки на себя наложить. | Үз-үзенә кул салу. |
| 2170. Рукой подать. | Кул гына сузарга (бик якын мәгънәсендә). |
| 2171. Руку на отсеченье даю. | Кулымны кисәргә бирәм. |
| 2172. Ручаюсь головой. | к. 497. |
| 2173. Рыба гниёт с головы. | Балык баштан чери. |
| 2174. Рыба ищет, где глубже, человек — где лучше. | Балык тирән җирне, кеше (адәм) яхшы җирне эзләр. |
| 2175. Рыбак рыбака видит издалека. | Сунарчы сунарчыны ерактан таный (к. 2266). |
| 2176. Рыло (одёжа) черно, да совесть бела. | ≅ Тышлары керле, ләкин юк аларда эч кере. (*М. Гафури.*) |

## С

| | |
|---|---|
| 2177. С больной головы на здоровую. | Ак эт бәласе кара эткә. |
| 2178. С бору да с сосенки. | Аннан-моннан.<br>Аннан бер, моннан бер. |
| 2179. С ветра пришло, на ветер и пошло. | Җилдән килгән җилгә китәр (дә). |

| | |
|---|---|
| 2180. С волками жить — по-волчьи выть. | Бүреләр белән яшәсәң, бүре кебек уларсың (к. 239). |
| 2181. С глаз долой! | Югал күз алдымнан! |
| 2182. С глаз долой—из сердца вон. | Күздән киткән күңелдән китә. |
| 2183. С глазу на глаз (разговаривать). | Күзгә-күз сөйләшү (к. 1742). |
| 2184. С головой уйти (в дело). | (Эшкә) башы (баш-аягы) белән чуму. |
| 2185. С головы до ног. | Баштанаяк. |
| 2186. С грехом пополам. | Көч-хәл белән.<br>Ничек житте, алай. |
| 2187. С жиру бесится. | Мае сикертә.<br>Маена чыдый алмый.<br>Маена чыгыш итә алмый.<br>Бете котыра. |
| 2188. С иголочки. | Энәдән-җептән генә чыккан. |
| 2189. С кем живёшь, тем и слывёшь. | к. 2318. |
| 2190. С кем поведёшься, с (от) того и наберёшься. | к. 239, 2180. |
| 2191. С кем хлеб-соль водишь, на того походишь! | к. 239. |
| 2192. С курами ложиться, с петухами вставать. | Тавыклар белән ятып, әтәч белән тору. |
| 2193. С левой ноги встал. | к. 1197. |
| 2194. С лёгкой руки. | Җиңел кулдан. |
| 2195. С лихого пса хоть шерсти клок. | к. 2208. |
| 2196. С лица не воду пить. | Төсне табакка куймыйлар.<br>Төс-битне табакка салып йөртмиләр. |
| 2197. С луны свалился что ли? | Айдан төштеңме әллә? |
| 2198. С людьми советуйся, а своего ума не теряй. | к. 1268. |
| 2199. С мёдом и долото проглотишь. | к. 1744. |

| | |
|---|---|
| 2200. С мёдом и ошмёток съешь. | к. 1744. |
| 2201. С миром и беда не убыток. | Ил белән килгән бәла авыр булмый.<br>Ил белән килгән кайгы кайгы түгел, ялгыз башка килмәсен. |
| 2202. С миру по нитке — голому рубашка. | Ил төкерсә, күл була. |
| 2203. С неба свалился что ли? | Күктән төштеңме әллә? |
| 2204. С него взятки гладки. | Алыш-бирешкә бик кысмыр (к. 1731, 2461). |
| 2205. С ним каши не сваришь. | Аның белән борчак пешми. |
| 2206. С одного вола двух шкур не дерут. | Бер үгездән ике тире тунамыйлар. |
| 2207. С открытым (чистым) сердцем. | Ачыктан-ачык.<br>Чын күңелдән.<br>Саф күңелдән. |
| 2208. С (от) паршивой овцы хоть шерсти клок. | Дуңгыздан бер кыл. |
| 2209. С пеной у рта. | Төкерекләрен чәчрәтеп. |
| 2210. С плеч долой. | Җилкәдән (өстән) төште (төшсен). |
| 2211. С ремеслом и увечный хлеба добудет. | Һөнәре бар хур булмас.<br>Һөнәрле кеше үргә йөзәр (к. 2143). |
| 2212. С ремеслом не пропадёшь. | к. 2143. |
| 2213. С родной стороны и ворона мила. | к. 1416. |
| 2214. С сильным не борись, а с богатым не судись (не тягайся). | Көчле белән сугышма, бай белән ярышма. |
| 2215. С собаками не найти (не сыщешь). | Эт белән эзләсәң дә таба алмассың. |
| 2216. С сыном бранись, да на печку лезь; а с зятем бранись, да за скобу держись. | Киявең әйтсә, ишек бавын тотарсың, малаең әйтсә, бишек бавын тотарсың. |

Киявең сүксә (куса), ишек бавын тот, малаең сүксә (куса), түргә менеп утыр.

2217. С удовольствием. — Бик рәхәтләнеп.
Бик шатланып.
Дүрт куллап.

2218. С умным разговориться — что мёду напиться. — Яхшы белән сөйләшсәң, балга шикәр каткандай.

2219. С чужого голоса петь. — Кеше җырын җырлау.

2220. С чужого похмелья голова не болит. — к. 1914.

2221. С цепи сорваться. — Бәйдән ычкыну.

2222. С языка сорвалось. — Телдән ычкынды.

2223. Сам по себе. — Үзеннән-үзе.

2224. Сам стар, да душа молода. — Үзе карт булса да, күңеле (йөрәге) яшь.
Үзем алтмыш яшьтә булсам да, күңелем алты яшьтә.

2225. Сам сыт, только глаза голодны. — к. 120.

2226. Сама испекла пирожок, сама и кушай. — Теләп алган картаң.

2227. Само собою разумеется. — Үзеннән-үзе билгеле.

2228. Сапог с сапогом, лапоть с лаптем. — Иш ише белән, иш кошы белән.
Ике чабата бер кием (к. 1159 2266).

2229. Сапог-то скрипит, да в горшке не кипит. — к. 159, 1351.

2230. Сапоги всмятку. — Буш сүз.
Мәгънәсез сүз.

2231. Сапожник без сапог бывает. — Итекченең итеге юк (булмый), читекченең читеге.
Күмерченең күмере юк.
Тимерченең балтасы китек була.
Тимерченең балтасы юк.
Түтәл иясе түтәлгә туймас.

2232. Сахар-медович. — Төче телле (кеше).

2233. Сбивать (сбить) с толку. — Юлдан яздыру.

2234. Сбиваться с ноги. — Аякны ялгыштыру.

2235. Сбиться с пути истинного. — Хак юлдан язу.
Кырын юлга керү.
Ялгыш юлга китү.

2236. С бухты барахты. — Уйламый-нитми.

2237. Свались только с ног, а за тычками дела не станет. — к. 1956.

2238. Свалиться на голову. — Башка бәла булу.
Башка бәла булып төшү.

2239. Свалиться с облаков. — Күктән төшкәндәй булу.

2240. Сваха лукавая — змея семиглавая. — к. 1390.

2241. Сварить бы кашу, да куры крупу расклевали. — Май булса, ботка пешерер идек, ярма юк.

2242. Свекровь кошку бранит, невестке наветки (намётки) даёт. — к. 245.

2243. Сверху покрыто, да не подволочено. — к. 1145.

2244. Сверху — ясно, снизу — грязно. — Тыштан ялтырый, эчтән калтырый.

2245. Свести в могилу. — Кабергә (гүргә) кертү.

2246. Свести счеты (*с кем, чем*). — Исәп-хисапны өзү.
Үч алу.
Ачу алу.

2247. Свет моих очей. — Күзем карасы.
Күз нурым.

2248. Свет не без добрых людей. — Дөньяда яхшы кешеләр бетмәгән.
Дөньяда яхшы кешеләр дә бар.

2249. Свет сошёлся не клином. — Анар карап кояш та тотылмас, җир дә селкенмәс (к. 49).

2250. Свет не баня, для всех место будет. — Дөнья иркен, һәркемгә дә урын бар.

2251. Свинья — борову, а боров — всему городу. — к. 2282.



ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

2252. Свить себе гнездо.
Үзенә тормыш кору.
Үзенә оя кору (ясау).

2253. Сводить концы с концами.
Көннекен-көнгә аудару.
Очын-очка ялгау.

2254. Сводить на нет.
Юкка чыгару.

2255. Своего не дам, чужого не надо.
Үземнекен бирмим, кешенеке кирәкми.
Үземнекен бирмим, кешенекен алмыйм.

2256. Свои люди — сочтёмся.
Үз кешеләр — килешербез әле.

2257. Свои собаки грызутся, чужая не приставай.
Авыл эше ала булыр, бүре керсә, берегер.
Эт белән эт талашыр, авызын-борынын ялашыр.
Туган-туган белән талашыр, ятка бәла ябышыр.

2258. Своим горбом добывать.
Маңгай тирен түгеп табу.
Хәләл күкрәк көче белән табу.
Үз кул көчең белән табу.

2259. Своих друзей наживай, а отцовских не утрачивай.
Үз дусларың үлсә дә, атаңныкы үлмәсен.
Үз дусларың югалтсаң да, атаңныкын югалтма.

2260. Свой глаз — алмаз, чужой — стекло.
Үз күзең (кулың) үле тергезә.

2261. Свой глаз — смотрок.
к. 2260.

2262. Свой глаз зорок, не надо и сорок.
к. 2260.

2263. Свой глаз — миленький дружочек, а чужой — вор.
к. 2260.

2264. Свой господин побьёт и помилует.
Үз үтерми, ят ярлыкамый.

2265. Свой дурак дороже чужого умника.
Башка авылның яхшысы — үз авылыңның шакшысы.
Башка авылның егете — үз авылыңның эте.
Күрше авылның карчыгасы — үз авылыңның каргасы.

2266. Свой свояка видит издалека. — Иш ишен таба.

Иш ишен таба, тычкан тишеген таба.

Иш ише белән, дуңгыз тушы белән.

Иш ише белән, иш кошы белән.

Иш ише белән, хуҗа ишәге белән.

Тиле тиңе белән, итәге җиңе белән (к. 337).

2267. Своя воля, своя и доля. — Теләп алган картаң.

2268. Своя ноша не тянет. — Үз сөягең үзеңә авыр түгел.

2269. Своя рубашка ближе к телу. — Үз күлмәгең үзеңә якын.

Үзеңнеке үзәктә, кешенеке кештәктә.

Кеше капчыгы артыңда, үзеңнеке алдыңда.

2270. Своя рука — владыка. — к. 2587.

2271. Своя своих не познаша. — Ата улны, ана кызны белми.

2272. Связать по рукам и ногам. — Аяк-кулны бәйләү (бәйле итү мәгънәсендә).

Кул-аякка богау салу.

Ике аякны бер куныччка тыгу.

2273. Сгореть со стыда. — Оятыңнан җиргә (җир тишегенә) керерлек булу.

2274. Сделать из белого чёрное. — Ап-акны кап-кара дип әйтү.

2275. Сдержать слово. — Әйткән сүздә тору.

2276. Сегодня густо, завтра пусто. — к. 1070.

2277. Сегодня съедим, так завтра поглядим. — Иртәгене ишәк кайгыртсын.

Бүген булгач җиткән, иртәгесен ишәк кайгырткан.

Иртәге көн өчен ишәк кайгырган.

2278. Седьмая вода на киселе. — к. 625.

АХМЕТ БАЙТҰРСЫНҰЛЫ ТІЛ БІЛІМІ ИНСТИТУТЫ

| | |
|---|---|
| 2279. Сей рожь в золу, а пшеницу — в пору. | Арыш чәчсәң — көлгә чәч сабан чәчсәң — суга чәч, к. 2279. |
| 2280. Сей рожь, хоть в золу, да в пору, а овёс сей в грязь, и будешь князь. | |
| 2281. Сей хлеб — не спи, будешь жать — не станешь дремать. | Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың. |
| 2282. Секрет — на весь свет. | Чыш-пышны бөтен шәһәр белгән. к. 212. |
| 2283. Семейный горшок веселей кипит. | |
| 2284. Семь бед — один ответ. | Мең бәлагә бер җавап. |
| 2285. Семь пятниц на неделе. | Аның атнасына биш җомга. |
| 2286. Семь раз примерь, один раз отрежь. | Җиде кат үлчә, бер кат кис. |
| 2287. Семья не без урода. | Аттан ала да туа, кола да туа. Икмәк эчендә кибәк булмыйча булмас. |
| 2288. Сену с огнём не улежаться. | Ефәкне утка якын куярга ярамый. |
| 2289. Сердца нет у него. | Каты күңелле кеше ул. |
| 2290. Сердце заныло. | Йөрәк сыкрап китте. |
| 2291. Сердце ( у него) каменное. | Таш йөрәкле (кеше). Каты күңелле (кеше). |
| 2292. Сердце не лежит. | Күңел ятмый (бармый). |
| 2293. Сердце (душа) не на месте. | Күңел (йөрәк) үз урынында түгел (борчылу мәгънәсендә). |
| 2294. Сердце обливается кровью. | Йөрәккә (кара) кан савыла. |
| 2295. Сердце (у него) отходчивое. | Тиз кайтучан (кеше). Кайтып төшүчән (кеше). |
| 2296. Сердце раздирается на части. | Йөрәк телгәләнә. Йөрәк парә-парә килә. |

| | |
|---|---|
| 2297. Сердце рвётся пополам. | к. 2296. |
| 2298. Сердце упало. | Котым очты. |
| 2299. Серёдка на половинку. | Ярым-йорты.<br>Ни ары, ни бире. |
| 2300. Сесть в галоши. | Галошка утырып калу (алдану мәгънәсендә). |
| 2301. Сесть на голову. | Башына менеп утыру (к. 2303). |
| 2302. Сесть на мель. | Көймәсе комга терәлү. |
| 2303. Сесть на шею. | Җилкәсенә менеп атлану (тулысынча үзенә буйсындыру мәгънәсендә). |
| 2304. Сжить со света. | к. 2245. |
| 2305. Сиамские близнецы. | Аерылмас дуслар.<br>Ахирәт дуслары.<br>Агылый белән тагылый.<br>Әмәк белән Сәмәк.<br>Әсәк белән Көсәк. |
| 2306. Сидеть как на иголках (на угольях). | Инә өстендә утыргандай утыру.<br>Кабызган шырпы кебек тору. |
| 2307. Сидеть как рак на мели. | к. 1008. |
